ФӘРИТ ЯХИН
# СӨЙКЕМЛЕ СӨЯК
*Хикәяләр*

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ

2004

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2Рос=Тат)-4
Я 89

**Яхин Фәрит**

Сөйкемле сөяк: Хикәяләр.— Казан: Татар.кит.нәшр., 2004.— 191 б.

Әлеге җыентыкка тупланган хикәяләрендә автор тормышның уңай якларын гына түгел, тискәре якларын да тәфсилләп сурәтли. Геройларның характерларын, рухи дөньяларын, уй-кичерешләрен һәркем дулкынланырлык итеп тасвирлый.

ISBN 5–298–01425–9
© Татарстан китап нәшрияты, 2004

## «ЗИС-5»

### 1

Миңа бер дә машина җене кагылырлык түгел иде. Язмыштан узмыш юк икән ул. «Чаткы» кинотеатры янында торучы Галәви дус беркөнне ярты күтәреп кергән. Сыйлады. Мин дә буш итмәдем. Кибеттән әйләнеп кайттым...

Утырулар яхшыдан иде. Күз-баш буталган. Йөрәктә — гайрәт, беләктә — көч. Киттек чыгып. Шунда өйдә генә калган булсам иде. Юк шул, мин күрәсен кеше күрмәс, ияргәнмен Галәвигә.

Икенче көнне баш бераз томаланган хәлдә уянып киттем. Кичә ниләр булды икән, дип уйлап ятам. Гадәтләнелгән иде, Галәви белән һаман да бер-бер маҗарага очрый идек. Һич исемә төшми. Ни уйларга да белгән юк.

Галәвине көтеп алып, каршысына чыктым. Борыны да ишелмәгән, күз төбендә дә ул-бу күренми.

— Сиңа ни булды? — дип сорыйм.

— Ә нәрсә? — ди, көзге каршысына килеп.— Барысы да урынында!

— Әйе шул! — дим.

Ул да миңа аптырап карый.

— Нәрсә булган? — дим.

— Син туасыңмы-юкмы? — ди.

— Ә нигә? — мин әйтәм.

— Киттек, соңга калабыз,— ди бу ашыктырып.

— Мин әле чәй дә эчмәгән!

Галәвинең ишетәсе дә килми, үз сүзе сүз:

— Кичә шоферлар курсларына язылып кайттыкмы? Кайттык! Бүген — беренче дәрес, соңга калырга ярамый,— ди.

— Ничек булды әле алай? — дим.

— Юлда сөйләрмен,— ди бу.

Киттек инде чыгып, кая барыйм? Соңга калырга ярамый, ди бит.

«Галәви юкны сөйләргә ярата анысы»,— дип уйлап, тагын киреләндем. Ул арада барып та җиттек. Кыңгырау да бирделәр. Парта артына кереп тә утырдык, дәрес тә башланды. Шулай курсларда укып киттек.

### 2

Машина дигәнебез дә әллә нәрсә түгел икән ул. Нәкъ ат арбасы кебек, майлап торганда гына җиңел йөри, майламасаң, таралып төшә дә ватыла, имеш.

Безнең какча йөзле укытучыбыз, урыс кешесе, сөйли-сөйли дә туктап кала, сөйли-сөйли дә төртелеп тора. «Бу әйбер шушы була инде, әнә тегесе бу инде»,— дип, төтен чыккычны самавыр торбасы белән чагыштыра, эчке ягулы двигательне чыра телеп салган күмерлегенә тиңли дә:

— Самавыр кайный башлаганда ничек чыжлый, машина да эшли башлаганда шулай итә,— дип өстәп куя.

Галәви дә минем кебек беркатлы булырга кирәк, ышанып утыра. Башын селки. «Әйе!» — дип тә куя. Мин дә аңа кушылам. Малай чаклар искә төшә. Мич авызы янындагы самавырга ничә тапкыр күмер салганым бар, идәнгә утырып, чыжлый башлаганын азмы көтелмәгән. Көлисәсенә утлы күмерләрдән калган вак-вак кызыл, сүнеп бетмәгән көл коела... Әмма, аңа карап, самавыр бер генә булса да ни йөреп, ни очып китми.

Саша дәдәй дигән бу укытучыбыз кайвакытта, шулай сөйләнә-сөйләнә, бик мавыгып ала. Мин дә хыял белән аңа ияләм, һәм өстәлдә чыжлап-гөжләп утырган самавыр янына гаиләбез белән җыелганыбыз күз алдына килә. Крендельне сындырып-сындырып кына чәй эчәбез. Кайнар. Шуңа да өреп кенә кабабыз. Әмма дә иреннәрне, хәтта авызны да пешерә. Әни ачуланып куя:

— Өреп кап, улым, пешәсең!..

Тагын да өреп-өреп кабам, әмма борыным белән үк тәлинкәгә кереп китәм.

— Үрдәк булдың инде, йөзеп кенә китәсең калды. Түгепләр бетердең!

Монысы — апамның миңа тәрбия дәресләрен бирүе. Тик сүз тыңлый торганнардан түгел шул үзем. Киреләнәсем, үртисем килә.

— Җиз самавыр ничек җырлап утырса, көйле машина да шулай!

Укытучыбыз Саша абзыйның бу кадәр дә үтемле итеп әйтүе мине бик тә сөендерә, аңа карата хөрмәтем арта, күңелгә ихтирам вә игътибар белән береккән изге хисләр тула. Шулай итеп, мин мескен дә шофер булуны үземә максат итеп куям. Галәвинең җилкәсенә калын беләгемне салып:

— Рәхмәт, дустым! — дип, баш чүмечемә кагып куям.

Ул утырган җирендә сеңә һәм коймак калынлыгы гына кала. Бераздан гына:

— Кулың авыр,— дип зарланып ала.

## 3

Руль артына да утырып карыйсы килә бит ул. Кул сузыла. Шофер булырга җыен да, күпме укып, бер тапкыр машина йөртеп карама, нәрсә була ул? Хәер, кул гына түгел, җан үрелә, җан!

Инде ничә тапкыр машина янына барып карадым. Утыртмыйлар. Күз уйнаганын күрмиләрме, әллә үземне кешегә санамыйлар? Галәви — хәйләкәр, инде биш тапкыр утырып карады. Минем батырлык та җитә, әмма тәртипне бозу килешми. Ярамый икән, ярамый инде, берни дә эшләп булмый. Галәви, барыбызның да йөрәгенә ут салып, күзләрен майландыра-майландыра сөйләп, туйганчы мактанды:

— Беренче мәртәбә атай атка атландырган чагында, егылып төшмәмме дип куркып елаган идем. Кузгалып китте, малай, мин сиңа әйтим... кот — ботта, бот ат билен буган. Егылмадым... Ә машина — шәп икән, утыргычына кадәр йомшак. Һи, дилбегә дә, тезген дә тоту түгел инде. Тәгәрмәче — тәгәри. Рулен боргалыйсың, сыптыра гына. Казан булып Казанны бер сәгать дигәндә әйләнеп чыгып була...

Әйе, Галәви — уңган егет! Чәчен дә кыска итеп муен-колак тирәсеннән кырдыра, баш түбәсендә әтәч кикреге кебек итеп калдырылган җирләре дә чибәр һәм ни кире кызларның да һушын ала торган сыйфатта. Ул ислемай сөртеп-сөртенеп йөрүләрен искә дә төшереп торасы юк инде. Без тәмәке төреп пыскытканда, ул папирос көйрәтә, төтенен, әллә ниләр кыландырып, борын тишекләреннән чыгара. Дөрес, аны гына без дә булдырабыз. Әмма Галәвинеке — башкача. Аның бер тәңкәсе янында безнең хәтта кызыл унлыкка да урын юк. Егет булуның хикмәте байлыкта да, акчада да, шәп киемдә дә, төс-кыяфәттә генә дә түгел икән ул. Егет булсаң, Галәвидән ким калырга ярамый. Егетлек ул, билләһи, яхшы һөнәр кебек, үзе байлык!

Без дә аныңчалатып маташтырып караган булабыз да анысы, барып кына чыкмый. Кайсыдыр төше килепме, китерелепме җиткерелми.

Галәви кызлар озатырга да маһир. Ярты Казан белән йөреп чыкты инде. Менә генә ябышты берсенә, капты егет, дисең, ә ул арада суынып та өлгерә. Чөнки, беләм мин аны, бер кызны озатып кайтышлый икенчесе белән танышырга өлгерә. Яхшыдан-яхшысы инде, әлбәттә, бер кашык су белән йотарлыгы. Галәвинең килеш-килбәт өстенә теле дә үткер, кулы да әрсез булырга кирәк. Йөреп китәләр. Кичәге кызы сөйләшенгән урыннарында бер көтә, ике, өч... Хәтта айдан елга чыга. Ә Галәвинең җиле дә исми. Нишләсен бичара кыз, хәтерләштерә, белештерә. Ишетеп ала: сандугачлар булып сайраган егете бүтән тирәккә кунган икән. Дөрес, алай ярамый да инде ул. Әмма бу чибәркәй дә коры калмый, аны бүтән егет күреп ала, озата башлый. Нәкъ шул вакытта Галәви тагын мәйданга килеп чыга. Кичә оныткан кызына бүген кабат бер-ике генә күз сирпи дә, җанын кузгатып, җитмәсә, йомры-түгәрәк сүз дә ката, беләгеннән дә йомшак

кына сыпырып тоткандай итә. Кызны озата килүче егеткә җир тишегенә олагу гына кала. Әмма сынатасы килми. Ә кыз аны тәмам оныткан. Галәвигә ябышкан, Галәвигә ышана башлаган. Никләр өчен шулай ялгыша? Галәвигә таяну — язгы бозга басу белән бер инде ул...

Кайтып барабыз. Кичкә калынды. Галәвигә юл өйрәтәм:

— Әйдә, моннан, турыдан гына чыгабыз. Ярты сәгатьтән өйдә булабыз! — мин әйтәм.

— Юк,— ди Галәви,— аннан урамы караңгы, әллә кем очравы бар.

— Ә нигә?

— Сиңа — ярый, миңа — юк,— ди бу,— синең бүрегең дә маймылныкы түгел, киемең дә ямаулы бишмәт кенә. Мин юньле кешеләр йөри торган урамнан кайтам. Ерак булса да, тыныч!

Киттек инде, дусны үпкәләтергә ярамый шул!

**4**

«Маймыл бүрек» дигәне бик килешле инде анысы. Бәхәс юк. Күзне кызыктырырлык. Әмма ул вакытларда без аның су күсесе, ягъни нутрия тиресеннән тегелгән икәнлеген белми идек, шунлыктан «маймыл бүрек» дип йөртә идек. Казанда андыйлар берничә кешедә генә. Шулардан берсе —Галәвинең башында. Кичен кызлар күзләргә, йөрәкләренә кадалып калырга чыкканда гына киешле. Затка дип бик тә саклый, батырып та кими. Маңгае тирли башладымы, хәзер бүреген салып, култык астына кыстыра. Киемнең кадерен белә Галәви, бик белә. Һич кенә дә туздырасы-нитәсе түгел, мәңге саклыйсы.

Дәрес бара. Карбюратор. Ягулык белән һаваны бергә кушып өрдерүче җайланма.

— Бу,— дип башлый сүзен Саша абзый,— машинаның тамагы. Мәңге туясы юк. Тыгылганчы уткәрә. Кашыклап түгел, чиләкләп чүмерә. Аңа барыбер, бармы ашарына, юкмы, һаман сорап кына тора.

— Тончыкмый да икән, менә сиңа тамак, малай,— дип куя Галәви кытыкланып.

Аның сүзен шунда ук эләктереп алган Саша абзый тезеп кенә китә:

— Тончыга, әле ничек кенә тончыга! Никадәр комсызрак булса, шулкадәр күбрәк тончыга... Инде аны ничек тончыктырмаска, ничек тыгылдырмаска һәм күп тыгынмый торган итәргә, шуны өйрәнеп китик.

Безнең колаклар үрә тора, күзләр, күрми калмыйм дигән кебек, аның һәрбер кул хәрәкәтен, күрсәткән детален барлап бара.

Саша абзыйның әшнәсе Габбас абый бар. Ул — инструктор. Икесе дә телгә һәм хәйләгә осталар. Һәр сүзләреннән мәгънә табабыз. Көлешәбез. Өйрәткәннәрен белми калмаска тырышабыз. Шулай уен-көлке белән алар дәрес бирә, ә без йотылып-йотылып тыңлыйбыз, черем итеп алучыларыбыз да юк түгел.

Хәер, искәртми ярамас, укытучыларыбыз арасында бүтәннәр дә бар... Корыган агач кебеге — Кукло. Бу аның фамилиясе булырга кирәк, исемен белмибез. Ул үзе белән шулай атап таныштырды, артыгы белән кызыксынып тормадык. Бу гына да түгел, хәтта нәрсә укытуын һәм ни белергә тиеш икәнлегебезне дә күз алдыбызга китерә алмадык. Коры агачның җимеше булмый, диләр, хак сүз икән. Ул үзенең бердәнбер таләпчәнлеге белән генә «көздә» мул уңыш җыярга ният итүе бик сәер иде.

Ара-тирә безнең белемнәребезне дә тикшереп алалар. Галәвине бастыралар.

— Нәрсә ул эчке ягулы двигатель? — дип сорый Саша абзый.

— Ашказаны,— дип җавап бирә Галәви, күзен дә йоммыйча.

Безгә ни көләргә, ни еларга урын калмый. «Булмады бу!»— дип, урындыкларыбызга сеңәбез. Хәзер аның урынына кайсыбыз булса да җавап бирергә тиеш. Төне буе кызлар озатып йөреп, тамагы да, йокысы да туймый килгән инде аның, мокыт.

Әмма Саша абзый ашыкмый, тыныч кына утыра бирә, сөйләвен көтә. Бераздан соң гына:

— Дәвам итегез,— ди.

Галәви башын җүләргә сала, тагын кабатлый:

— Ашказаны... Ашказаны...

— Әйе, ашказаны,— ди соравына җавап көткән Саша абзый.

— Ашказаны ул,— дип дәвам итә Галәви, колак артын кашып,— корсак урынына урнашкан. Тамак ачкан саен кысылып, бүре кебек улап куя, әйе...

— Шуннан?

Безнең урыннар урындык төбендә инде. Ни еларга, ни көләргә белмибез.

— Шуннан шул, без ашаганны кайната...— дип дәвам итә Галәви, күзен дә йоммыйча.

— Казан кебекме? — дип, һаман җитди рәвештә сорый бирә Саша абзый.

Үзен гүяки дөрес сөйлим булса кирәк дигән фикердә канатландырып, Галәви сүзен дәвам итә:

— Әйе, казан кебек. Шуңа күрә татарлар аны ашказаны, ягъни дә мәсәлән, аш кайнатучы казан дип атаганнар.

— Әйе-әйе, кыюрак... Дәвам итегез,— ди, һаман да җитди кыяфәтендә калган Саша абзый. Сизенәбез, аңа да кызык. Авыз кырыйлары вакыт-вакыт күтәрелеп-күтәрелеп ала. Әмма һаман да егетебезнең тәмам көлкегә калуын белмәмешкә сабыша: — Татарларның бар нәрсәләре дә казан, казан яны, казан тирәсе белән бәйләнгән инде. Анысын беләбез. Шуннан?

— Шуннан — шул,— дип сөйли бирә Галәви, күзен дә йоммыйча, түшәм ярыкларыннан күзе белән ары-бире күчenә-күченә,— ашказаныннан алга таба кайнатылганы эчәкләргә керә, аннан, ни, әйе, юан эчәккә...

— Бик дөрес,— дип сүзен җөпли Саша абзый,— ахырына кадәр барып җитсәк, бишлелек була... Әйе... Дәвам итик!

— Шуннан шул инде,— ди Галәви, бераз аптырабрак,— бәдрәфкә китеп бушатасыбыз гына кала.

Без инде тыела алмыйбыз. Көлүебездән сыйныфның диварлары калтырана, түшәм-идән такталары биешә башлый. «Ни булды?» дип, күршедәге укытучылар ишекне ачып карыйлар, җитди караш ташлыйлар. Тынычланып өлгерәбез.

Ә Саша абзый бик канәгать. Сугышны башыннан ахырына кадәр машина белән ерып чыккан. Мондый хәлләрне генә күп күргән. Сер бирми. Тагын да сорап куя:

— Шуннан-шуннан? Дәвам итик... Кыюрак-кыюрак!

Галәви тәмам коелып төшә. Инде дә нәрсә дияргә белми. «Бетте бит инде!»— димәкче.

Шунда алгы рәттәге ташбаш егетләрдән берәү:

— Комганны әйт, комганны,— дип пышылдый.

Галәвигә шул җитә кала, акылына илһам орлыгы төшеп, шунда ук чәчәк ата һәм:

— Комган белән юып, тәһарәт яңартабыз! — дип, җимеш тә бирә.

Без егылабыз. Диварлар ишелеп киткәндәй була, идән сайгаклары кабат урыннарыннан күчә, түшәм такталары биешә. Тагын күршеләр керәләр. Аптырап карап торалар. Ә без — шым булабыз, ләм-мим. Сер бирү юк. Саша абзый һаман да тыныч һәм җитди кыяфәтендә утыруын дәвам итә, җитмәсә, әйтеп тә куя:

— Булдырдыгыз, Галәви!

Бераздан тагын да өсти:

— Бик дөрес эшлисез. Татарлар үзләрен шулай чиста йөртергә яраталар. Бик яхшы, бик яхшы!

Һәм тагын да сорамасынмы:

— Дәвам итик!

Инде бер мәртәбә илһам орлыгын чәчәк аттырып җимешләндерергә өлгергән Галәви:

— Ашказаны ул — эчке ягулы двигатель, ягулыкны хәрәкәтләндерүче көчкә әверелдерү өчен хезмәт итә, хезмәт итүче җайланма,— дип чатнатып әйтеп куя.

Инде безне тагын тыеп тору мөмкин түгел, кабат тәгәрәшеп көләбез. Безнең бу кадәр хахылдау һәм хихылдауга диварлар күчenә, идән такталары түшәмгә күтәрелә, түшәмнеке идәннекенә алышына. Тагын күршеләр өелешеп кереп җитәләр. Безнең көлгәнне күреп, үзләре дә авызларын ералар. Әмма берни аңламый чыгып китәләр. Тик Саша абзый гына үтә дә җитди:

— Бик дөрес, бик дөрес! — дип, Галәвине җөпли.

Без һаман да тынычлана алмый көләбез. Күзләрдән яшьләр сыгыла, авызлар арып, йөткерә һәм төчкерә үк башлыйбыз. Бераз тынычланганыбыз соңында гына Саша абзый:

— Ашказаныннан башка гына әйткәч, ничек була инде? — дип, тагын да сорап куя.

Ташбаш егетләрнең берсе:

— Бүтәкә була! — дип әйтеп салмасынмы.

Бу юлысы беренче булып Саша абзый тыела алмыйча көлеп җибәрә, без чыгырдан ычкынабыз. Күршеләр тагын йөгерешеп керәләр. Селкенгән диварларны ишелмәсен дип тотып торалар, биегән сайгакларны басып торалар, башаяк киләләр. Ахырда, дәресләрне вакытыннан алда тәмамлап, өйләребезгә кайтарып җибәрәләр.

Шуннан бирле безнең Галәвиебез Бүтәкә кушаматын йөртә башлады.

## 5

Габбас абыйның инструктор икәнлеген искә алган идем инде. Руль артына утырта да: «Киттек!»— ди. Кайда басарга, нинди әйберне тартырга һәм боргаларга икәнлеген әйтеп тә тормый. Шофер булырга җыенгансың икән, син үзең белергә тиеш дип кенә карый. Шулайдыр инде. Чөнки, сөйләвенә караганда, ул үзе дә машина йөртүне шулай өйрәнгән. Кая барсын? Сугыш вакытында икән. Утырып барган машинасының шоферы адашкан ядрә тиеп үлгән икән дә, командиры аңа кушкан:

— Атта йөргәнең бармы, татарин? — дигән.— Әйдә, утыр рульгә.

«Юк!» дип тору кая инде ул, әмерне үтәми ярамый. Габбас абый руль артына утыруга, машина йөреп тә киткән. Бу «худ» белән турылап, Берлинга кадәр барып җиткәннәр, имеш.

Шул рәвешле безне дә өйрәтәчәк ул. Әйтеп куйды. Методикасы бик гади: йөреп китсәң, китәсең, ә юк икән, булмый инде, булмагач, суга төшкән мәче баласы кебек батасың да үләсең. Хәерлегә, шофер мәртәбәсенә ирешми каласың. Шулай да укып йөрүеңнең кирәге чыгачак, диләр, машина паркында шөреп боргалаучы итеп эшкә билгелиләр. Ни, элегрәк шулай киткән берәү инде мастерскойга хуҗа итеп куелган, ди. Габбас абзыйга рәхмәтләрен укып туймый икән, бичара.

Шулай итеп, Габбас абый үзенең шәкертләреннән берсен руль артына утырта да, машинаны урамнан урамга йөрттереп кенә калмыйча, иң тар капка яки күпер-арка янына китереп туктаттыра. Үзегез беләсездер, ул вакытларда бөтен Казан буйлап һәр ишек алды түбәле ырыс капкалар, күпер-аркалар белән эшләнелгән иде. Шунда арт белән машинаны кертергә куша. Бәрдерсәң, бетте, йә машина җимерелә, яки дөбердәп капка ава. Өченчесе — юк!

Бервакыт китте болар Галәви белән выжылдатып. Без кәртле суга калдык. Акча юк вакыт иде. Бәхетемә, һаман ота бардым. Уен кызганнан-кызды. Баштагы бүрекләрне салып бәрдек. Шактый вакыт узган.

— Егетләр, очкыч төшә! — дип кычкырышуларга күтәрелеп карасак, Галәвиләр кайтып төштеләр. Чыннан да, машинага канат куйганнар. Менә сиңа Бүтәкә!

Баксаң, капка икән. Габбас абый, гадәтенчә, бер тар тыкрык янына китереп туктаттырган да ишегалдына машинаны кертергә кушкан. Галәви төшеп караган. Күңелендә шик иңрәгән.

— Монда машина сыймый,— дигән.

— Сыя, сыймаска мөмкин түгел,— дип исе дә китми әмер иткән Габбас абый.— Керт!

— Әйдә бәхәс: сыймый,— дигән Галәви, ни шайтаны котыртыптыр.

— Әйдә бәхәс,— дип, руль артына утырган Габбас абый,— үзем кертеп биримме?

Һәм керткән дә.

— Менә, сыйдымы? — дип әйтә икән Галәвигә инструкторыбыз.— Ә син сыймый, дип лаф орасың!

Кире чыкканда карыйлар — капка юк, юллары иркенәеп киткән. Җирдә дә авып ятмый икән. Аны-моны карап тормаганнар, Галәви Казанны тагын бер әйләндергән дә, кибеткә кереп, бәхәснең ядәчен кайтару өчен, бер ярты алган. Башны күтәреп югары карау кая ул. Шул килеш чаптырып кайтып кергәннәр.

Артларыннан шундый ук «худ» белән милиция дә килеп җитте. Шактый юмалый торгач, беркетмә төзеп газапламадылар. Галәвинең дә, Габбас абыйның да сый-хөрмәтен күреп, җитмәгәч, көтәчәккә дип, әле генә откан акчаларымны алып, җәелеп бәйрәм иттеләр. Тиздән укуларыбыз бетәргә тиеш иде, кайгырасы юк.

Имтиханнарны уңышлы тапшырдым. Әмма дә җиде кат тиремне генә салдырмадылар инде. Ә Галәви бөтенләй коелып төште. Беренче булып керә, иң соңгы чыга. Тәмам җанын гына алмадылар. Машинага утырып киткән җирләреннән дә биш сәгатьсез әйләнеп кайтмадылар. Инде дә эзләргә чыгасы идек, ватылып озаклаганнар.

Кайтып керделәр, мин сиңа әйтим, авызлары — колакта, колаклары — маңгайда. Галәви — булдырган, Галәви — уңган егет шул!

Безгә шоферлык хокукына таныклык биргән көндә ярты Казан бәйрәм иткәндер. Һәрхәлдә, шулай кебек тоелды. Инде хәзер кем кая эшкә урнашырга тиеш иде. Алдан сөйләшенеп куючылар да булган, килеп, үзебезне берәм-берәм аулаучылар да табылды. Тагын Галәвине бәхет күмде. Шоферлыкка кодаларга бер-бер артлы килеп торучыларны көлеп кенә каршы ала һәм мыскыллап ук диярлек озата тордык. Менә бервакыт юантык шома татар кереп, кайдан икәнлеген дә аңлатып тормастан:

— Безгә кайсыгыз бара? — дип сорады.

Үзе кесәсеннән бер пачка «Себер» папиросы чыгарды һәм мулдан сыйларга кереште. Колак артына да тыгып, авызга да берәрне кабып, шунда ук көйрәтеп җибәрдек. Без хәзер әллә кемнәр идек. Шунлыктан шома татарга да көлеп кенә җавап бирдек. Ул соравын тагын да кабатлады һәм бераздан янымдагы затлы Галәвигә төртеп:

— Безгә киләсезме? — диде.

Галәви аптырап калды. Коелып ук төште. Имтиханнарда башы черегән, җаны өзгәләнгән егетнең тырышлыгы әйе, дип баш кагарга да җитмәде.

— Булды алайса, сөйләштек, эндәшмәү — ризалык билгесе! — дип, Галәвинең кемлеген, кайда яшәвен шома татар язып та алды. Һәм кая килергә икәнлеген әйтте дә чыгып китте. Шунда бик зур түрәгә эшкә алынуын белгәч, без үзебезнең терсәкләрне эзләдек. Әмма тешләрлек түгел иде инде.

Миңа «ЗИС-5» машинасына утырырга туры килде. Безнең вакытта алар Казан тулы иде. Агач кабиналы, акыртып-акыртып та әллә ни тизлек җыя алмаган бу машинаны таудан гына төшереп җибәрерлек булуга карамастан, миңа аны:

— Тагын ун ел шылт та итми йөриячәк әле бу,— дип, җилкәләремә суга-суга мактадылар.— Бер сүтеп җыйсаң, дөньяны җимертәчәк.

Аны тарттырып кабызганда, автопарк, шартлаган, дөбердәгән тавышлар белән, кара-зәңгәр-сары төтенгә тулды. Машиналары янында кайнашкан шоферлар, барлык эшләрен ташлап, колак-борыннарын тотып, кайсы кая йөгерде. Әле генә йөреп киттем дигән «ЗИС-5» бик каты төчкереп-ютәлләп-калтыранып бераз эшләгәндәй булды да шым калды. Бөтен җиреннән төтен чыга, кайсыдыр урыннары яна да башлаган иде. Качышып беткән шоферлар, көрәктер-чиләктер тотып, кайсы кайдан мизгел эчендә килеп тә җиттеләр, ком һәм су сибеп, яна башлаган җирләрен сүндерештеләр. Аннан соң, бераз тынычлангач, мине күреп алдылар һәм егылышып көлә башладылар. Бит-кулларым кара корым иделәр.

**7**

Ремонт минем ярты ай вакытымны алды. Шушы ике атна эчендә баштанаяк сүтеп җыйдым. Аның һәр деталенең картайган һәм тузганлыгы киләчәк көнемә дә ышаныч тудырмады. Бары тик яңа балдаклар гына утырттым. Бездә аны ул вакытларда «кәлсә» дип йөртә иделәр. Склад мөдиребез Камил абзый, олы борынлы, алтын тешле мишәр:

— Бүтән бер әйбер дә юк, энем, сорап аптыратма,— диде дә ишекләрен бияләй кадәр йозаклар белән бикләп куйды.

Анда карбюратор да булырга тиеш, кулымдагы боерыкка язылган иде. Анысын алар «нәрәт» дип йөртәләр икән. Шоферлар — халыкның әллә кеме, «йонлы куллары», диләрме, ягъни «блатной»лар. Һәр сүзгә урысча кушып сөйләшергә яраталар.

Иске карбюраторны яңадан көйләп маташканда, Камил абзый янымнан узып бара иде, сүз катып куйды:

— Болар салкында бер дә ышанычлы түгелләр, энем, боз булып каталар!

Мин аңа күтәрелеп карадым. Ә ул җилкәмә сугып куйды:

— Ярый-ярый, барысы да яхшы булыр әле, сүндермәсәң!

Аның киңәшен мин күңелдә тотарга тиеш идем. Әмма игътибар итеп торылмаган. Боерыкка язылганны да бирмәгәч, ачуым килгәне бетеп җитмәгәндер шул.

Машинаны көйләп чыктым. Бу юлы кара төтеннәр атмады, җиңел генә эшләп китте. Мине торф ташырга җибәрделәр. Ул елда кыш иртә килеп, юлларны боз ясап катырды. Вакыт-вакыт юеш буран да кузгалып, тәрәзәгә сылый, йөрүне дә кыенлаштыра.

Минем йөк ташырга беренче тапкыр килүемне күреп, экскаваторда эшләүчеләр шаяртырга булганнарын башыма да китермәдем.

«ЗИС-5» җиргә сеңеп төшкән, хикмәтле егетләрнең бүреге кебек, җитмәсә, әрҗәсе уңга салынган иде. Кузгалып киткәндә, машина белән бергә үземнең дә эчләрем суырылып чыга язды.

Ул торфны шәһәрнең бер башыннан икенчесенә кадәр илтергә тиеш идем. Казансу күперенә килеп җиткәндә, «ЗИС-5»ем телсез калды. Сәбәбен белми идем. Каршы искән җил тәрәзәгә юеш кар сылый, болай да авыр булган юлны тагын да кыенлаштыра. Инде туктап калган машинама җан кертү өчен тырышуларым уңышсыз тәмамланачак дип борчылган чагымда, Ходайның рәхмәте, Камил абыйның карбюратор хакында әйткәнен исемә төшердем. Ул, чыннан да, нигәдер боз булган иде. Ничек аны җылыту җаен табарга кирәклеген уйлап та бетермәдем, җиңел машина выжылдап килеп туктады. Аның эченнән кояштай балкыган Галәви килеп чыкты. Үзен күрмәгәнемә бишбылтыр булганлыктан, кул сугыштырып исәнләштек. Сөенече эченә сыймаган Галәви минем хәлне аңларлык дәрәҗәдә түгелдер дип уйлаган идем:

— Мин хәзер,— диде дә китеп барды.

Ул арада машинамда казынып, өшеп беткәндә килеп тә җитте.

— Ун тәңкә, дустым,— дип белдерде, һаман да авызын ерган килеш, миңа яңа карбюратор сузып.

Акчаны алды да, хушлашып:

— Эшем ашыгыч, болай да сиңа вакытымны югалттым,— дип китте дә барды. Артыннан җилләр генә исеп калды.

«Бәхетлеләр менә нинди машиналарда рәхәт чигә!» Бу фикерем белән мин хаклы идем. Галәвидән көнләшүемнән, хәлемнең авырлыгыннан җаным көйде. Әмма дә яңа карбюратор «ЗИС-5»кә җан кертте, аның сәгать кебек эшли башлавы кабаттан күңелгә дәртемне кайтарды.

Казанның яртысын җиңел генә узып, калганын да шулай җай гына барырмын, икенче юлы болай артыгын төятмәм дип акылыма киртләргә генә өлгермәдем, арткы көпчәк шартлады. Күтәргеч-домкратым юк

иде. Инде нәрсә эшләргә дигәндә, юл читендәге зур ташка күзем төште. Аны күтәреп-тәгәрәтеп китердем дә күчәр астына тыктым һәм, шиңгән тәгәрмәчнең астын казып, сүтеп алдым. Көпчәкләрне алыштырып, яңадан җыеп, урынына утырттым.

Ул арада караңгы да төшә башлады. Минем ашамаган, ач һәм аздан ачуым килер чак иде. «Бу йөкне илтеп аударсам, өйгә кайтып китәм»,— дип, үземне тынычландырып, машинамны үкертеп кузгалуым булды, нидер шырт итте. «ЗИС-5»не арттан кемдер тотып тора, җан-фәрман чинап алуына да карамастан, кузгалып китә алмый иде.

Ярымкүчәре сынган булып чыкты. Тәгәрмәчне урынына беркеткәч, күчәр астына күтәргеч-домкрат урынына куйган ташны чыгарырга онытканмын, көч килгән.

Утырып еларга гына тиеш идем.

**8**

Тагын да ун тәңкәгә буксир яллап, тарта алмыйм, дигәч, йөкнең яртысына якынын шунда урамга гына бушатып, тагылган хәлендә «ЗИС-5»не автопаркка кайтарып җиткергәндә, мине көтеп торучылар калмаган иде. «Йөкле килеш кертмибез!»— дип, каравылчы тавыш чыгарып маташса да, эшне аңлатып бирдем. Ризалашты тагын.

Икенче көнне яңадан ремонтка ябышып, бу юлы да ике атна вакытымны уздырдым. «ЗИС-5»не аякка бастыргач, эштән җибәрүләрен сорап гариза яздым да хуҗага кертеп бирдем. Ул көлеп кенә куйды һәм:

— Энем, ертып ат моны,— диде, алдыма командировка кәгазе китерде.— Менә, Горькийга барырсың. Акчаны кассадан кереп ал. Иртәгә юлга чыгасы.

Риза булмый хәлең юк. Яңа машинаның рәхәтлеген һәркем белә. Инде ике ай «ГАЗ»да йөрим. Урамдагы һәркемнең ике күзе миндә кебек. Ә «ЗИС-5»не тимер-томыр заводына үзем илттем, картлар әйтмешли, үз аягы белән, бичараны. Әмма анда яңа адрес бирделәр. Мәктәпкә соратканнар икән.

Вакыт дигәнең тиз үтүчән шул. Беренче машинамны мәктәп ишегалдында калдыруыма да бер елдан артык гомер узган иде. Ничектер шул ук мәктәпкә күмер китерергә туры килде. Беренче машина, никадәр гаҗизләсә дә, сагындыра икән ул. «ЗИС-5»нең хәлен белешергә гаражлары ягына барсам, ни күрим, иске танышым Галәви аның астында казынып маташа иде.

— Җиңелрәк эшкә күчтем әле,— диде бу, кул бирешеп күрешкәч,— юкса хуҗаны гына түгел, хатынын да, балаларын да, туганнарын да көне-төне әллә кайларга ташырга кирәк. Ә монда — дәрес бирәсең дә, вакытың буш.

Аны монда, болай очратырмын дип башыма да китермәвем сәбәпле, озак телсез тордым. Ә ул сөйләде дә сөйләде. Аңлый идем: күп сүз булган җирдә хакыйкатьне яшерер өчен мөмкинлек кала!

Гомерләр узгач кына ишетелде, безнең Галәви үз хуҗасының хатыны белән кети-мети уйнаштырырга маташкан булган, имешме, әллә инде ул хәл чыннан да барып чыкканмы, аларын ук һичбер сөйләп тормаска тиешмен, булырга мөмкин хәл, әмма хуҗабикәнең кызы белән дә кайнашуны гадәт итеп өлгергәнче, эшеннән озату җаен караганнары хактыр. Шул турыда кешеләрдән дә ишеткәләргә туры килде.

Галәви озатып калды.

Еллар үтте. Шулай да, әгәр Казан урамында бер-бер «ЗИС-5»не күрсәм, Галәви белән булган шул очрашуны искә төшерәм дә, әллә ничек ятсынып куям һәм шул вакытта үзем йөрткән «ГАЗ»ның кадере арта башлый.

«Машина алыштыру — хатын алыштыру белән бер» дип әйтәләр иде, әллә дөрес инде, Ходаем. Карт хатыннардан курыккан кебек өркәм шул «ЗИС-5»тән.

Ә Галәви уңган егет булып чыкты. Минем «ЗИС-5»не берничә елдан бөтенләй дә яңартып бетерде. Аннан соң музейга илтеп тапшырган, диделәр. Ышанмадым. Барып карадым. Исән иде әле. Шул килеш. Белмим, хәзер кайдадыр.

Ул заманнар үтте. Хәзер машинаның иге-чиге юк, яңадан-яңалары гына. Шуларга карыйм да: «Бар иде заманалар!»— дип куям.

Миннән дә борынгыраклар нәрсә уйлый икән? Ат җигеп йөргәннәрне әйтәм!

*Март—май, 1998*

# Тәүбә-тәүбә, әстәгъфируллаһ!

Агачларда һәм күңелләрдә бөреләрне уяткан март ае, яшәүнең дәвам иткәнлеге хәбәрен биреп, тау сыртларыннан вә үр очларыннан акрынлык белән генә авылга таба төшә башлады. Кәлүшле итек — сучин-

кә киеп, җилкәсенә аркан бәйләмен ташлап, Соры Гыймадый акрын һәм авыр адымнар белән кузгалып китте. Артыннан төтен бәйләме бөркелеп калды, паровоз үтте диярсең, бәракаллаһ!

Бар эшне һәм фигыльне күтәрергә көче җитте Гыймадый абзаңның, менә шул тәмәкесен генә ташлый алмады. Ничек егерме яшендә гомерендә беренче тапкыр авызына төреп капса, шуннан бирле төтәтә һәм төтенләтә башлады. Инде егерме алты еллар булыр, һаман авызыннан төшерми. Хатыны да мең әрләде, акыл биреп: «Калага бар, колагыңа энә кадат, гәҗиткә белми язмаслар!»— дип тә әйтеп карады, әмма дә җиңә алмады. Менә шушы тартуы өчен аны Соры дигән кушамат белән йөртә башлаганнар иде.

Югары очның Гарәфи тыкрыгыннан үргә күтәрелүче юлда кара тап булып алты-җиде кеше мәш килә, трактор үкертүләре авылга ишетелеп, яңгырап тора. Соры Гыймадый шул тарафка күз кабаклары ерыгыннан карап торды да, ялгыз саескан керткертләгән тупыл агачы ботакларына эленеп калган, җылысын күрсәтергә ашыкмаган томанлы кызыл сүрән кояшны чамалап, сәгатьне билгеләде: тугызлар булыр, артык түгелдер! Хәер, ансын да артка-алга күчергәләп, күңел тоемын тәмам бутап бетерделәр.

Соры Гыймадый сәясәттә беркем дә түгел иде. Бары үзенә генә тимәсеннәр, ни милке, ни акчасы юк. Бар казанганы алты почмаклы агач йортының тар чоланына, мал-туары такта абзар-курасына сыеп бетә. Аллаһыга тапшырган инде, ни теләсә, шул булыр!

Ул яңадан тау ягына күз салды.

Бу көнгә кадәр нишләп ул малай актыгы тракторын үргә мендерә алмый ята икән анда? Кеше баласы булса, ачуланыр-көләр идең. Үзеңнең Сафаң шул. Пешмәсә дә пешмәс икән. Энеләре үсеп килә. Инде алар бер-бер артлы өйләнешә башларлар. Ә монсыннан — булмас, ни тормыш кора алмас, ни кыз тапмас. Берәр усалы туры килеп, юньгә кертсә генә инде. Кече бала иркә үсә, диләр, ялган сүз, өлкәнен берсе дә арттыра алмас. Эһ, Сафа, Сафа, булырсыңмы икән инде башыма олуг җәфа?

Бу көнгә кадәр тау итәгендә ятсын инде! Караңгыда ук чыгып киткән иде бит. Имеш, урманнан агач тарттырырга барасы. Булган инде болай булгач, бик булган. Пешмәсә дә пешмәс икән. Әнисе гаепле, әнисе! Аның артыннан алып кайткан ике балалары да аллы-артлы үлгәч, шулай әллә ни кыланды, белмәде йорт тулы балалары буласын. Көтмәде.

Соры Гыймадый яныннан гына ике малай, буш чана тартып, тау ягына элдерттеләр. Кара әле, бүген ял көне түгелме соң? Юкса бу вакытта болар мәктәптә булыр иделәр. Шулайдыр! Үзенекеләр дә чәйгә тормады шикелле, кузгалып йөргәннәре дә күренмәде. Түр якта песи балалары төсле борыннарын җылы түшәккә төртеп йоклый торганнардыр әле. Әйдә, бала чакның рәхәтен күрсеннәр. Менә олыгайгач, кояш чыгып өлгергәнче, күз ачыла, йокы кача. Яшьлектә нинди татлы төшләр генә күрми вә нәрсә генә уйламый иде, хәзер баш бер дә хыялны үзенә сыйдыра алмый, эш җаен искә төшерү белән генә канәгатьлек кыла. Татар акылы — төштән соң, диләр. Элегрәк шулай иде шул, яшьлектә. Тегене-моны уйлап тору юк, хәл итәсең дә куясың, шуннан соң гына җаен исеңә төшерәсең. Менә хәзер, олыгаелган саен, башкачарак, төшкелегең авышкач, акылың да кулдан алда эшләп өлгерә икән ул!

Ат йөгертү дисең инде, ә? Ат йөгертү...

Моны Соры Гыймадый абзаңнан да артыграк җаен китереп кем эшли ала? Менә, Аллаһ боерса, бияне араннан куып чыгарыр, җаен китереп кенә станга бәйләр. Аннан соң айгырга юл бирер, муенына аркан салып, бия әйләнәсендә алты-җиде әйләнеш ясатып йөгертер, ягъни дә мәсәлән, үз сүзе белән әйткәндә, «круг» бирдерер. Җылыныр малкай, җылыныр. Биянең тәкате бозылыр, айгырның борын тишекләре кабарып чыгар... Һой-һой!..

Кышның салкынында кирәк иде ул. Элекләрне март аенда ярлы-ябагай гына бия йөгерттергәннәр. Имеш, кышның салкынында туган колынның име начар була, исән калуы икеле. Белмәгәннәр, яман мал озак яшәми ул. Март аенда бия йөгерттер инде...

Әстәгъфируллаһ! Ни булды әле бу?..

Соры Гыймадый абзый тигез җирдә таеп китте, егылмас өчен биленә, аягына көч бирде. Шайтан алгыры, тигез җирдә шул. Берәр киленнең судан кайтканда чиләге чайкалып, суы түгелгән, ахрысы, нәкъ юл уртасында ук. Катырып шугалак ясаган. Аяк астыңа карап йөрмәсәң, бәлале булуың бар.

— Гыймадый абзый, түктерәсең бит! — Хатын-кыз тавышы чәрелдәп куйды. Әллә сүгенде дә инде, әстәгъфируллаһ!

Ирдәүкә Гайния икән әле.

— Һе, килен, мунча ягасыңмы әллә? — Соры Гыймадый шаярткандай итте.— Аягым таеп киткән иде шул.

— Мунча ягам, мунча,— диде Гайния, бер дә яшереп тормыйча,— аркамны юарлыгың бармы әллә?

Моны ук көтмәгән иде Гыймадый. Ишетүгә, икенче кат чалкан китә язды. Сүзнең җайсызлыгыннан тәмам каушап:

— Ни бит, килен...— дия генә алды.

— Акланырлык кына калгач, нигә сорап торасың? — Гайния шушы сүзе белән Соры Гыймадыйның үтен сыта язды.

Аңа бирешүдән артыгы калмады:

— Әйе инде, анысы...

Шунда ук Гайнияне баш-аяк карап алды да уй зинданына чумды. Һе, Сафа улына шәп килен буласы да үзе. Әмма ирдәүкә шул. Бөкләп кенә ташлаячак, тәмуг газапларын күрсәтәчәк. Ай-һай! Итагать белсен иде, ичмасам. Ике дә уйламыйча килен итеп төшерү юлын карар иде. Әти-әнисе дә яхшы нәсел ияләре юкса. Каян килгән бу шушындый ирдәүкә зат. Буй-сын, килеш-килбәт тә шәп үзендә, әмма, әмма...

Җилкәсеннән ишелеп төшкән арканын Гыймадый ике куллап кочаклады, читкәрәк чыкты. Гайния олы чиләкләрен чайкалдырып узды. Кара инде, ә! Нәрсә ди шул, нәрсә ди! Мунча, имеш, арка юарга, имеш. Атасы яшенә җитеп баручы абзый кешене шулай мәсхәрә итмәсә, беткән ди яшь-җилкенчәк егетләр үзенә.

Шулай да Соры Гыймадыйга рәхәт булып китте. Ә нигә, бәлки, мунчасына барырга да мөмкиндер, арка юарга?.. Әстәгъфируллаһ! Карт көнендә әллә ир-ат шулай тилерә инде? Ахмак! Сөякләреңне җыеп, бияләеңә тутырып кайтарыр. Акылыңа кил!

Койма башына, Фатыйма абыстайның түшәк-юрганнары кебек чәчеп, култыкларыннан эленгән ат караучы Самат, бригадир Камалетдин һәм көнлеккә чыккан Сәгыйрь белән Бикчәнтәй, ары-бире сүз алышып, Гыймадыйны һәркайсы дүртәр күз белән көтә иделәр. Серне белеп, алдан сизенгәндәй, утарда салам утлап йөрүче атлар кешнәшә. Колын һәм тайларны аерып куйганнар.

— Боларның үз башларына, ялгыз булуларына берәр ай бармы соң әле? — дип, бияләр ягына төртеп күрсәтте Соры Гыймадый, килә-килешкә исәнләшергә өлгерми эшне белешә башлап. Ахырда шулай да өстәп тә куярга өлгерде: — Исәнлекме?

— Тиз тотмакчысың, ахры? — диде бригадир Камалетдин.— Саулык-сәламәтлекме?

— Иртән кереп, өй тәрәзәләрен селкетеп чыккан идең бит инде, түшәм тактасы да урыныннан күчкән булырга кирәк, туфрагы коелып калды.

— Ха-ха-ха! — Озын һәм калын гәүдәсен дерелдәтеп көлде Камалетдин.— Сүзләрен каян табып бетерәсең?

— Кесәдән түгел инде, юкса иң бай кеше булыр идем!

— Кесәңнән гел чыгарып торсаң, бай булмас идең, Гыймадый абзый, ярлы калыр идең. Әмма юмарт исемен алыр идең.

— Дөрес анысы. Укыган кеше — чукынган кеше инде, башы эшли. Сүзне кесәдә тотмыйбыз. Акчамыни ул! Комачау гына итәр иде.

— Ха-ха-ха! — Гүяки бүселеп киткәндәй булып тагын да хихылдады Камалетдин.

Койма башына элеккечә терсәктән һәм култыктан эленгән хәлләрендә калган көнлекче Сәгыйрь белән Бикчәнтәй берни аңламаган килеш карап торуларында булдылар. Икесе дә арык, пошмас һәм тыныч бу ир затлары, суфи-дәрвишләр төсле дөньялыктан бөтенләй ваз кичкән кыяфәтләрендә тәмам мөкиббән китеп, бригадир булып бригадир белән оста итеп әйтешер худы булган Соры Гыймадыйга, ни сокланырга, ни аптырарга белмичә, кырын күз салгалап куйдылар. Ат караучы Самат кына астыртын елмая торды. Аның: «Һа, боларның сүзе бер-бер хәл белән бетәчәк инде!»— дип уйлаганы һәм телләшүләренең ахырын көтәргә дә әзер икәнлеге йөзенә чыккан иде.

— Тыр-р-р!

Борылып карадылар. Чанасына тау итеп тирес өйгән, өстенә салам салып тезләнгән Гөлүс, ала-кола биясен тыярак төшеп, Соры Гыймадыйлар янына килеп тукталды. Бүрегенең бер колакчыны аска салынып, икенчесе, киресенчә, югары күтәрелгән, сакал төпләре каралып торган бу эшем иясе, сары тешләрен ыржайтып, бихисап олы һәм чөгендер төсле гарәби күркәм борынын тартып-тартып куйды.

— Бия чаптырыргамы әллә бүген?

Аның соравы «Эшегез беткән икән!» дигән кебек яңгырады.

— Дуңгыз булсалар, каплатыр идек, сыер икән — иярлер, каз-үрдәкне — бастырыр, ат шул, чаптырабыз, агай-эне,— диде арканын койма башына элеп Гыймадый.— Йә, бер төреп тартыйкмы әллә?

Сүзнең борылып киткәнен Гөлүс аңламый калмады:

— Бармы соң?

— Гыймадый тәмәкесез йөрми! — Әллә кайчан тәмәке тартырга угаланып торган, әмма үзенеке булмау сәбәпле сабыр итәргә, берәрсенең сыйлаганына өмет тоткан көнлекче Бикчәнтәйнең сүзләрен шул ук уйны башында кайнаткан куштаны Сәгыйрь эләктереп алды да өстәп куйды:

— Әйдә, көйрәтик!

Һәммәсе әзергә бәзер җитеште. Хәтта коймага асылынганнар да кул сузды:

— Синеке яхшы була, тамакны өтә торганы,— диде Самат, чиратын көтеп.

Гәзит телгәләделәр. Шунда гына бригадир Камалетдин үз кесәсеннән өр-яңа пачка «Себер» чыгарды:

— Кибеткә кайткан, атайлар заманында тарталар иде аны, хәтерлим әле!

— Яле-яле,— дип, Гыймадый белән Гөлүс, берәр папирос алып, колак артларына кыстырдылар. Коймага эленүчеләр бу юлысы да коры калмадылар.

— Башта төреп тартыйк! — Гыймадый белән Гөлүс, каз тәпие ясап, ирен читләренә элделәр, тергезеп җибәрделәр. Баллы һәм ачы ис авыздан тамак һәм борыннарына үтте, хәтта колакларыннан да чыкмадымы әле. Тәмәке чиккән ирләргә әллә ни игътибар бирми генә хатыннар-киленнәр, якындагы чишмәгә су алырга дип, төшә-менә йөренделәр, ирдәүкә Гайния дә икенче кат үтеп китте.

— Әмерекәннәр үз патшаларының башына җиткән икән,— дип куйды Сәгыйрь, күп белдекле кыяфәттә сәяси мәсьәләләрне кузгатып.

— Жорж Кеннедине әйтәсеңме, әллә Клинтанынмы? — диде Камалетдин дә аңа кушылып һәм авыр тәмәке төтенен тирән итеп суырып.— Алар эшенә катышып буламыни? Без — бу якта дөньяның, алар — теге ягында. Менә минем үкчә астыннан казый башласаң, нәкъ аларның каласына тишеп чыгасың инде!

Бикчәнтәйнең моңа кәефе китте:

— Булмас... Туң шул әле. Сөяк белән бер. Июнь-июльләрне көтәргә кирәк.

— Чыктың ди! — Сәгыйрь дә борчылуын яшерә алмады.— Анда җәһәннәм ич!

Болар үзләренең кайчан мәктәптә укыганнарын оныткан иделәрме, әллә укырга дип йөрүләре коридорларда гына калгангамы, җәгърафия фәнендә Колумбтан хәтәррәк иделәр.

— Җәһәннәм-тәмуг шул... Негр-зәнкиләргә бәхет күрсәтмиләр, ди, бәдбәхетләр, тәмуг чаяннары! — Мең белдекле Камалетдин белән бәхәс урынсыз иде.

— Аларның негрлары мондагы безнең кебек инде...— Сәгыйрьнең шушы рәвешле ара-тирә киртә сындыру гадәте бар иде. Аның сүзләреннән кайнап китәргә әзерләнгән бригадир калкына башлады.

Гыймадый тәмәке төпчегенә төкереп, аяк астында таптады һәм аны сүчинкәсе белән изде дә:

— Күп сүз — бозау имезә, эшкә керешик! — диде.

Көтмәгәндә Сәгыйрьнең артык дөресне әйтеп ташлавыннан сүзнең тәме, тәмәкенең рәхәте бетеп, Гөлүс тизрәк моннан таю ягын карады. Коймага эленгән җирләреннән төшкән ирләр ат аранына керде. Соры Гыймадый да, арканын кабат җилкәсенә йөкләп, капкадан эчкә узды.

Беренче бияне станга чыгарып бәйләделәр. Утардагы айгырның муенына аркан элеп, Соры Гыймадый аны җай гына тыя төште. Юкса ыргыласы иде. Муеныннан сыпырды. Әмма аның саен малкай башын боргалап, урынында тыпырчына, улакка ешрак тибә башлады. Нидер сизенәме соң үзе?

Соры Гыймадый белдекле кыланырга маташкан яшь айгырны җай белән генә сөйләштерергә уйладымы:

— Чү-чү!.. Ашыгып эш бармый ул. Хәлдән таеп бетәрсең әле. Әгузы билләһи... Чү-чү...— дип сыпыргалап та карады.

Айгыр, аның үгетен аңларга теләмәгәндәй, биеп-пошкырып куйды:

— Сөбхан Аллаһ! Бәрәкаллаһ!.. Сөбхан Аллаһ, бәрәкаллаһ!..— Бу айгырны Соры Гыймадый Аллаһ исеме белән җиңәсенә шикләнми иде.

— Әллә соң, Самат абзый, артыграк каптырган идеңме?— дип борчылып алды Гыймадый. Булыр да, чамасы юк. Каптырам, дигәч тә.

— Юк ла инде. Мин алай ук юләрмени, бер айгырга тулы бер яртыны эчереп бетерергә?

— Ни-и-и?..

Барсы да аптырашта калды.

— Шулай, билләһи! — Самат акланырга юл эзләде.

— Дөресен әйт, күпме бирдең? — Гыймадыйның болай үҗәтләнүе аны тәмам коелып төшәргә мәҗбүр итте.

— Күпме, дип, чүмәйтеп кенә алдым... Бер яртыны башладым... Калганы әнә фураж келәтендә!

Гыймадый аның бу җавабыннан канәгать иде. Ябылган утарыннан айгырны акрын гына, ашыктырмый чыгарып, арканны бушата-бушата, аны йөгертә башлады. Ирләр барысы да дивар буенарак сыендылар. Хайванның холкын белеп бетереп буламыни, Аллаһ сакласын, төртеп кенә китәр, сөякләреңне җыеп та ала алмаслар.

Айгырның адымнары кызуланды һәм дүртенче әйләнешендә кинәт кенә кешнәп җибәрде, станга бәйләнгән биянең нәкъ яныннан төшеп ышкынды, уңына-сулына чыкты. Дәрте килеп, иреннәрен җыерды.

— Тот, тот, рәтен белми бит әле ул! — Камалетдин шунда ук Гыймадыйның кулындагы арканга ябышты һәм тарта башлады.

— Ташла, ишек артына кач!.. Нигә арканны тарттың? Тегеңне болай...— Гыймадый сүгенеп җибәрде.

Айгыр инде Камалетдиннең өстенә килә иде. Үртәүне өнәмәде. Хәзер изеп китәчәк.

— Ишек артына, ишек артына! — дип җикерде Гыймадый, ни эшләргә дә белмичә. Камалетдин утлык янына егылды, айгыр, кешнәп, аның өстенә килә бирде. Сәгыйрь белән Бикчәнтәй икенче аранга үрмәләгән иделәр. Аркан башыннан эләктереп алырга өлгергән Гыймадый:

— Әйдүк-әйдүк,— дия-дия, бу әүварә килгән эшем ияләренә игътибар да бирмичә, айгырны бия янынарак тартып, төп эшенә котыртып куйды.

Комачауларга кирәкми иде. Белгән кебек кысылган булалар. Менә хәзер кабаттан җай-җай гына йөрттереп, бияне иснәтергә кирәк. Яшь әле, җаен белми!

— Егетләр-егетләр...

Гыймадыйның әмеренә буйсынып, ядәч башлы таяк тоткан Сәгыйрь белән Бикчәнтәй эшкә керешергә ашыктылар. Бия, эшне инде әллә кайчан сизенеп, фыр-фыр иткәләп баш болгады. Ат караучы Самат аның янына килергә өлгергән, башын сыйпап тора иде. Айгыр, аннан көнләшепме, башта биянең алгы ягыннан төшмәкче иде дә, Гыймадый аркан башыннан тартып куйды. Икенче әйләнешендә инде тәмам җитлеккән малкай теләк җимешенең буена туры килде. Әмма максатын камил китерә алмыйча, койрыктан читкә шудырды.

— Бозасыз, егетләр, бозасыз, җәһәтрәк! — дип җикерде бригадир Камалетдин.

Аның әмеренә буйсынмый кала алмыйча, Сәгыйрь уң яктан, Бикчәнтәй сулдан ядәч башлы таякларын айгырның түшенә таба сузылып-сузылып китерделәр.

— Йә-йә, ашыкмагыз, куркытасыз! — дип тыя төште аларны аркан башын тоту белән мәшгуль булган Гыймадый.

Бу вакытта чишмәдән күтәрелеп килүче Гайния шушы тамашага хәйран калып карап тора башлады. Аның юлы өстәнрәк уза, ат абзарлары, араны-утары аскы якта булганлыктан, бар нәрсә дә табадагы кебек күренә иде. Гайния көянтә-чиләген дә җилкәсеннән төшерергә онытты. Күзләре дә ирләр эшендә түгел, айгыр һәм бия хәленә мөкиббән халәттә калды. Хәер, аның ни-нәрсә тамаша кылуын белүче дә, сизүче дә, күрүче дә юк иде.

Айгыр, чыннан да, яшь, йөгертүнең рәтен белми иде. Биянең җаен таба алмыйча, арт аякларында килеш уңлы-суллы боргаланды. Тамаша кылып торучы Гайния дә биядән бер дә кимен куймый боргаланды, уңга сузылды, сулга тартылды. Дөньясын онытты. Чиләкләреннән хет бер тамчы суы тамсын!

— Җибәрә бит хәзер, җибәрә! — дип җикерде Камалетдин.— Ни карыйсыз инде? Җайлагыз, җайла!

Айгырның теләгән буена камил китерергә алынган Сәгыйрь, таягы белән булышырга теләп, биянең койрык янына этте, әмма артык тырышлык куеп, икенче яктан әзер торган Бикчәнтәйгә эшне арттырды. Тамаша кылучы ирдәүкә Гайния, бар дөньясын оныткан хәлендә, әле уңга, әле сулга сузылды, ә телендә һаман да бер кәлимә кабатланды: «Җә-җә, Ходаем! Җә-җә, Ходаем!» Сәгыйрь — уңнан, Бикчәнтәй сулдан булышу җаен карадылар, әмма әле дә булдыра алмыйча газапландылар.

— Бозасыз, әрәм итәсез, әле кайчан кирәгенчә җитлегә әле ул! Үзегез дә шулай хатын интектерәсезме, ну-ну! — Камалетдин җир ашый иде.

Тамаша кылучы Гайния, тәмам тәкатен югалткан хәлендә, уңга, сулга сузылып: «Җә-җә, Ходаем!»— дип дәрт бирә-бирә, койма буена таба магнитка тартылган кебек якыная барды.

Биянең теләге кузгалып, койрык чөйде. Әллә нинди эчке бер аңлашу һәм ис ярдәме беләнме белешеп, айгыр кешнәде һәм максат такыясына бөтен рәхәтлеге белән чумды. Сәгыйрьнең дә, Бикчәнтәйнең дә кирәге калмады. Бригадир Камалетдиннең җәелеп күтәрелгән куллары асылынып төште, Гыймадый, арканын тәмам җиргә ташлаган хәлендә, сары тешләрен күрсәтеп ыржайды. Ул арада булмады, айгыр һиһаһайлап куйды, бөтен сырты буйлап дулкын-дулкын калтырану йөгерде, биясе дә билдән бөгелеп-бөгелеп килде. Гайния шапылдап артына утырды.

Ирләр шул якка борылдылар һәм телсез калдылар. Аларның карашыннан айнып киткән Гайния торып басты, чиләкләрен күтәрде, шапылдап сулары агып төште. Урам юлы күл булды. Гайния онытылып артына утырганда, чиләкләре төпләреннән аерылган булып чыкты. Ирдәүкә, үз оятына сыеша алмыйча, көянтә-чиләкләрен шалтырата-болгый өйләренә очты.

Малкайлар, кеше җаны бар диярсең үзләрендә, яратышып өлгергән һәм бәхетләренә кинәнеп, сыйпашуга күчкән иде инде. Гайниягә игътибар иткәнлеген сиздермәскә тырышып, ир булырга күнеккән Гыймадый әйтә куйды:

— Булды бу, егетләр!

Арканын җыеп, иңенә алды.

— Бераз яратышсыннар, аннан япсак та ярый, шулай бит, Самат абзый? — дип, колак артына үрелде, Камалетдиннән тигән папиросы һаман да исән иде. Борын төбенә китереп, иснәп маташты.— Көйрәтеп алыйк.

Башкалар да аның янына җыелдылар.

— Шушы җитәр, дисеңме? — Бригадир Камалетдин бер эшне биш кат эшләтергә күнеккән иде, моны тәгаен белгән Соры Гыймадый җавап бирмәде. Бераз көйрәткәч, сорау кабатланды: — Аз йөгермәдеме?

— Бик җиткән, китапча! — дип кырт кисте Гыймадый, соры тәтенгә чумып. Һәрхәлдә, аның бу четерекле мәсьәлә хакында ике авыз сүз дә укып караганы юк иде.— Артыкка китсә, бозылыр. Яшьләр шул әле. Өйрәнеп алса, бу айгырдан эш чыгар төсле. Ихластан бушанды, файдаланырлык итеп...

Ат караучы Самат айгырга аталган яртының калдыгын алып килде. Һәммәсенә дә өлеш чыгып, Соры Гыймадый белән икесе йөзешәрдән күтәрделәр. Бераз авыз итүгә, үзләренә бүлгәнне азсынган Сәгыйрь белән Бикчәнтәй башкаларны кыса башладылар:

— Моның белән генә булмый... Капкач-капкач, әйдәгез, ике шешәлек итик,— дип, Камалетдингә зур өметләр белән тулган күзләрен текәделәр.

Уйга-сүзгә каты һәм коры булган бригадир көлеп кенә куйды:

— Монда йоклап калырга, ахры, исәбегез!

Соры Гыймадый кузгалырга җыенды. Әллә нигә шул «урыс малае»на күңеле тартмады бүген. Саубуллашырга дип күтәрелде, арканын иңенә салды.

— Ярый, китим. Апагыз мунча ягарга көтә торгандыр анда.

Сәгыйрь белән Бикчәнтәй аның болай кузгалуын яратмыйча аптырашып калдылар. Самат та, Камалетдин дә, бер авыздан диярлек:

— Әллә соң?..— дип, мәгънә белән әйтеп алдылар.— Әллә соң... ни... Җыештырабызмы? Берәр яртылык, ә?..

Соры Гыймадый атлаган юлыннан кире борылмады.

— Юк инде! — дип әйтеп куйды да китеп барды.

Капканы каерып кына чыкты, тимерчыбыгын элмәкләде. Онытылып булса кирәк, суга китереп басты. «И бичара ирдәүкә, чиләгенең төпләрен үк монда калдырган икән!»— үзалдына уйлана-уйлана ике түгәрәк калайны кулларына алды. Ниятенә керде: «Кайтышлый кертеп чыгармын үзләренә!»

Әле генә җылынып алгандай булган көн кабат туңдырып җибәргән иде. Соры Гыймадыйның ачык якасыннан суык үтеп, муен төбенә ябышты, сулышын авырайтты. Яз җиткән, җәйгә бик якын тоелса да, кыш үзенекен бирми иде әле. Тау сыртларындагы кызыл балчык һәм таш-кантарның күзен ачып, авылга таба төшә башлаган яз кире менеп шылган, коймак пешереп көтмәүләренә хәтере калган иде булса кирәк. Агач ботакларына ябышкан, өй кыекларына асылынган калын сөңге бозлар гына оялчан кызыл кояш белән уйныйлар. Ара-тирә ала каргалар, юл читендә сикергәләп, ат тизәкләрен чәчә-чүпли. Болайга китсә, язга тиз генә авышмас, мөгаен, апрель урталарын җиткерер, майга да чыкмагае бу!

— Гыймадый абзый!..

— Яхшы әле, кордаш, ә кем...

Кем, дигәне ирдәүкә икән. Исәнләштерде тагын, саташкан, дияр. Ничек буталып алды соң әле? Хатынкыздан ир-атны аерма инде. Нинди кордаш ди? Артык уйлану бер дә яхшыга түгел икән шул.

— Кая алып барасың, Гыймадый абзый, чиләк төпләрен?

— Сиңа китерүем, ни-кем, килен. Мунча ягам, дигән идең түгелме? Мә, тот, ташлап йөрмә. Төпсез булу килешмәс.

Ирдәүкә Гайния җәһәт кенә чиләк төпләрен Гыймадый абзасыннан алды да кереп йөгерде. Рәхмәтен ишеттермәде.

— Оялды, балакай!

Соры Гыймадый абзый, адымнарын җайлап, үз юлына чыкты. «Киләсе язга колынлар, Аллаһы боерса! — дип уйлап куйды.— Беренче үләнгә матураеп чыгар, көтүгә дә ияртеп йөрерлек булыр!»

Һай-һайлап, җырлашып-гәпләшеп, Камалетдин чанасында Самат абзый, Сәгыйрь һәм Бикчәнтәй ат куалап килеп җиттеләр.

— Әйдә, Гыймадый абзый, безнең белән!

— Юк, Камалетдин энем, үз «машинам» йөреп торганда, кеше чанасына утырып азапланмыйм инде. Барыгыз, бар!

— Ярый, үзеңә кара. Безнең әйтү хак булсын! Минем бит абыйның малае өйләнә, онытып куйганмын, әзерләнәсе бардыр,— дип, Камалетдин атын ашыктырып кузгатты, сыртына дилбегә башын томырды да китеп үк бардылар.

«Һе, өйләнә, диген, ә? — Соры Гыймадый юктан гына үртәлеп куйды.— Минем малайдан да яшь түгелме соң ул? Кайтырга да бераз пешекләргә кирәк үзен. Пешмәгән, тау итәгендә трактор кадәр тракторы белән ватылып ятсын инде!»

Күтәрелеп тау ягына карады. Анда иртәнге галәмәтләр күренми, актарылып ташланган балчык һәм юл гына Соры Гыймадыйдан ерык авыз кебек көлә төсле иде.

Өенә кереп чәй яңартты. Тәмләп эчә башлаган иде. Хатыны фермадан эшләре беткәч кенә кайтканлыктан һәм дә балалары өйдә юклык сәбәпле, ахырда чәенең тәме бетте. Әллә инде ачуы кабат кузгалды? Бал кабып караса да, күңеле ачылмады. Лапаска чыгып, мал-туарын бакты. Су эчерде. Ул арада караңгы да төшә башлады.

Эше бетеп, әллә ничек кенә уе-күңеле мунча тәрәзәсенә терәлде. Ишегалды ягына кара күз кебек мөлдерәтеп карап торгандай иде. «Ягылмады шул бу юлысы. Иртәгә булыр инде! — Соры Гыймадый шулай ният кылды, исенә төште:— Ни шул, ә!.. Арка юарга кил, диме?.. Әллә соң, һе... Әллә соң, мин әйтәм! Тфүтфү, әстәгъфируллаһ! Аллаһ сакласын!»

Соры Гыймадыйны шул рәвешле әллә нинди уйларга салып, мунча тәрәзәсе тәмам вәсвәсә кылып бетерде. Кыз кеше дәшсә, ак сакалың каралыр, сүнгән дәртең кабарыр!.. Тәүбә-тәүбә, әстәгъфируллаһ!

Өйдән атылып кече улы йөгереп чыкты да кабат кереп шылды. «Әтигә әйтәм!»— дигән тавышы гына ишетелеп калды. Мал караган арада кайтып, абыйсы белән сугыша-кыйнаша да башлаганнар. Йортыңны да астын өскә китерерләр бу малайлар. Булмады шул, кызы тумады. Хатыны салкын тидермәсә, кыз алып кайтырлык та хәлләре бар иде юкса. Язмыштыр...

Өй ишеген ачып җибәргәндә, йөзенә килеп бәрелгән мендәр Гыймадый абзыйны чак артка капландырмады, ярый әле тотынып калды.

— Аһ мур кыргырылар! Кай арада кайттыгыз да...— дип, бил каешына үрелүгә, бер малае карават астына качты, икенчесе мич арасына чумды, артыннан килеп җитешкәнче, урамга ук чыгып сызды.

Өйгә бераз тәртип керткән арада, олысы Сафа кайтты. Өсте-башы мазут иде. Аның артыннан ук диярлек, мыштым песи кебек кенә акрын басып, уртанчысы, урамга йөгергән малае да керде, кабат мич арасына чумды. Дөньялар тынып, Соры Гыймадыйның ханлыгы тантана итә башлаган иде.

— Бүген ат чаптырдыгызмы? — Сафа, сүз югыннан гына сорыйм дигәндәй, киемнәрен сала-салышка әйтеп куйды.

— Юк, йөгерттек кенә!

— Шулайдыр инде?

— Әнә, Камалетдиннәр туйга әзерләнә.

— Аның малае өйләнми бит әле.

— Беләм, абыйсыныкы! Синнән биш яшькә кече түгелме соң әле? — Соры Гыймадыйның шушы сүзләр белән бергә Сафаны да салып таптыйсы килде. Тик кодрәте шунда ук ишелеп төште. Улы тазарак күренә.

— Солдаттан кайтты гына әле...

— Ә син нәрсә көтәсең?

— Кемне, диген...

— Ярый, кемне булсын...

— Нигә Гайнияне кимсеттең?

— Ничек?

Сөйләшүнең ахыры болайга борылудан Соры Гыймадый аптырап китте. Сары сагыз тешләрен ыржайткан авызы ачылган килеш калды.

— Ничек?

Җавап ишетелмәде.

— Кимсетерсең, бар! — Соры Гыймадый үзалдына сөйләшүгә күчкән иде, улы җай гына өстәп куйды:

— Аркасын юам, имеш...

— Үзе үртәде бит, мин түгел.

— Ә син үртәлмә!

Монысын ук көтмәгән иде Соры Гыймадый, инде саруы кайнап чыкты:

— Кара әле, каян сиңа тел чыкты, ә?.. Бөтен тау ягын боламык ясап бетердең дә! Пешмәгән булсаң булырсың икән, тракторчы, имеш!

— Шулай шул!

Сафаның гомерендә беренче тапкырдыр бу рәвешле кирле-мырлы сөйләшүе, аяк терәп әтисенә каршы әйтүе иде. Соры Гыймадый тагын каешка үрелде. Әмма улының көрәктәй куллары аны ул арада тыеп куйдылар:

— Мин ат түгел, ишәк тә... Каешлама... Булды...

Атасы авып китәр хәлдә калды. Көтмәгән иде. Кара, нишли? Менә, пешмәгән, диген син аны!

— Гайниягә сүз әйтәсең булма!

Караватка барып утырган ата бу хәлгә хәтерен җыя алмыйчарак маташты. Балалар үссә, йөрергә дә урын кысанлана, диләр, хак икән...

Төне буена йокы күрмәгән Соры Гыймадый иртәнге якта хатыны белән киңәште, улы Сафаның да сүзен исәпкә алып, көн яктыруга, ак сүчинкә һәм кешелеккә кия торган кәчтүм һәм кара пәлтәдән Гайнияләр ягына юл алды.

«Арка юарга килдеңме әллә, дип каршы алмасалар ярар иде инде!..»

Бу уе хәтеренә борылды да кайтты, борылды да кайтты.

Киемнәре яхшыдан булса да, бүреге генә иске. Эшкә кия торганы. Бүтәне юк шул. Малайлары киеп туздыра бара. Нәрсә-нәрсә, кием-салым, бүрек белән итекне чыдатмыйлар да соң!

Килеп керә-керешкә күрде Соры Гыймадый: Гайниянең чиләкләре төпләнгән һәм мөлдерәмә су белән тулы хәлдә болдырда торалар.

Ишекне шакып маташты.

— Әстәгъфируллаһ, кеше йөри дип торабыз!

Аны шулай каршы алдылар.

Ә бераздан, серне белгәч, Гайния мунчага чыгып йөгерде һәм, киенеп-ясанып, оялчан балкышта кире керде. Сабанга чыкканчы туй ясарга, дип сөйләшенсәләр дә, Гыймадый абзый шул көннән үк улын ашыктыра башлады: «Чана юлы өзелә! Йә киленнең дә син пешмәгәннән җаны бизәр!»— дип, атна ярым үтмәс борын туйлап та куйдылар.

Үзгәрсә дә үзгәрә икән адәм баласы. Бу кадәр дә итагатьле киленнәр булыр икән!

Тик Соры Гыймадыйны һаман да мунча тәрәзәсе борчып торды. Аны күрүгә, аркасы кычытып, юл уртасында яткан чиләк төпләрен исенә төшерә дә, булган хәлләрне юкларын да кушып уйлап куя.

Тырышулары бушка киткән. Ни хикмәт, ул елны йөгерткән бия кысыр калып, Гыймадый абзыйга оят күтәрергә туры килде. Әмма шул вакытка киленнәре Гайния кыз бала алып кайтты. Берьюлы малайларына да акыл кереп калды. Сафасы да: «Башка чыгам, йорт күтәрәм!»— дип, үз җаена авышып китте. Нишләрсең инде алар китсә? Күңелен килен генә җылытып торган кебек иде, күзләрен сокландырып, җаннарына дәрт биреп. Тәүбә-тәүбә, әстәгъфируллаһ!

*1994*

# Империалист

Җәйнең корылыгын салкынча һава алыштырды. Төньяктан искән җилләр челләдән йончыган җан ияләренә ял бирде. Печәннән кайтып, әле караңгы төшәргә иртәрәк икәнлеген чамаладым да, кармакларны җайлап, су буена киттем.

Эштән арыган, ыгы-зыгыдан туйган авыл егетләре һәм тынмас ирләре дә инеш ярларына елышканнар, балык чирттерәләр. Кечкенә чагымда ишеткәнем бар, әткәй әйтә торган иде: «Хатын-кыз чыр-чуы булмаган җиргә барып, эһ, аяк селкеп бер утырырга».

Әнкәй алай ук усал түгел шикелле иде кебек, әмма ул да ирен авыр сулап офтанырлык итте микәнни?

Бу балыкчы ирләр өйләрендәге усал хатыннарыннан качып төшкәннәрдер инде, яр кырыенда аякларын балаларча селкеп утыралар. Дөньяның бик аз татыла торган рәхәтенә чумганнар.

Кармагыма чирәмнән тоткан чикерткәне корып, җайлырак бер култыкка ыргыттым. Улым Булат та янымнан урын алды. Калкавычына текәлде.

— Ни хәлләр анда, Казанда?

Авылдашларымның дөнья хәлләре белән кызыксынуына каршы нәрсә дип җавап бирергә дә белмичәрәк калдым. Калада яшәсәм дә, «югарыдагылар» хәленнән хәбәрләрне шул ук гәзитләрдән генә белештереп барам, алар да ул мәкаләләргә күз салалардыр, тәгаен.

— Мондагыча инде...— Бераз тынып торганнан соң, тагын да өстәп куйдым: — Хәзер тормыш бөтен җирдә дә бертөсле инде...

— Анысы шулаен шулай да, менә ни бит әле...

Авыл агайлары сүз җебенең башын эләктереп, хәзер акыртын-акыртын гына хәбәрләр йомгагын сүттерергә тотыначак иделәр. Алар белән ярышып булмый. Дөнья барышларын чамалап кына калмыйлар, бәлки күңелләре аша уздырып, кыйбласын да барлыйлар. Арадан иң сәер дигәне дә ни җитте сәясәтчеләрне орып кына уза.

— Былтыр, Шәймиев килә дип, кукуруз басуы уртасына өстәлләр, чатырлар кордырган иде безнең Залаков. Ничә көн рәттән ОМОН егетләре чәкәннәрне барлап-саклап чыктылар, автоматлар белән. Килмәде, чукынган. Сыздырып үтеп кенә киткән.

Монысын махсус минем өчен әйтәләр. Көлешәләр. Белеп калсын, дигәннәре инде.

— Әле тагын киләсе икән. Сарманда аның өчен атап Сабантуй ясамакчылар, ди. Идарәгә разнарядка төшергәннәр. Аек башларны гына илтәчәкләр икән.

— Хатын-кызларнымы?

— Алар да кимен тотмый хәзер...

Балыкчыларның көлешүе Минзәлә инешен уңга-сулга чайкалдырып куйды. Ул арада калкавычым төпкә чумды. Тартып чыгардым. Балыкның күз кызыктырырлыгы капкан иде. Бала-чага минем янгарак елышты. Күзләрендәге ут чиләктә урын табалмый бәргәләнгән кызылканатны табада кыздырырлык итте.

— Җимем беткән икән.

Чикерткә куа киттем. Кармагымны елгыр бер малай кулына алды. Урысчалатып кына:

— Можно, пока я ловлю? — диде, шунда тәртип өчен генә рөхсәт сорап.

Каршы килмәдем.

— Энем, кайчан татарчаны өйрәнәсең инде? Җәй башыннан әбиеңдә кунакта ятасың?

Авыл агайларының соравын аңларлык дәрәҗәдә белеме булмаган малай авызына су капты. Маңкортның хәле миңа кызганыч кебек тоелды.

— Аларныкылар гомергә шулай булдылар инде. Татарга бармак аша гына карадылар. Урыс — бөек, урыс — бөек, дип, бөтенләй урыслашып беттеләр. Ихаталары да урысныкы кебек буяусыз, каркау, яшәүләре дә. Әминнәре дә солдаттан әнкәсе телен онытып кайткан иде. Мин дә хезмәт иттем. Онытырсың сиңа, бар... Ә ул, мокыт: «Я татарский не знай, забыл»,— дигән булып йөрде. Исенә төшердек, авызы кыегайган икән, турайтып бирдек.

Басынкы гәүдәле, имән кебек тамырга-буынга ныклы Гарифның әйткәненнән бар да көлешеп куйды. Ә теге урыслашкан малай аның сөйләгәнен аңламый калды.

Ул арада, чикерткә тотып килергә өлгергәнемдә, кармагыма икенче балык эләккән. Маңкорт малай тартып та чыгарды. Бармак башы кадәрле чабагы миңгерәү хәлгә төшкән йөзенә җан кертте, ул, басып торган урынын онытып, уңга-сулга чайкалды. Әйе, малай вакытымда, беренче балыгымны каптыргач, минем дә йөрәгем, күкрәктән атылып, баш түбәмә килеп бәрелгән иде.

Кармагыма җим сапладым һәм балык тартып чыгарган Булат улым өчен дә чикерткә куа киттем. Ә теге малай кармагымны тагын суга ташлады. Чикерткә җыеп килгән арада, тагын бер балык эләктерде. Бераз гына тотыйм инде, диярәк, кармагымны бирмичә аптыратты. Рөхсәт итсәм, бөтенләй дә үзенеке итәсе иде. Кире алгач, үпкәләде дә әле, җитмәсә.

Ул көнне балык яхшы чиртте. Бер-бер артлы чүпләп кенә торабыз. Ничек кич иңә барганы да сизелмәде. Мавыгылган, онытылып ял ителгән. Сүз арты сүз дә күп кузгатылган.

— Җирне чит ил байларына сатуны бер дә кабул итеп булмый,— диләр, берсе сүзенә икенчесе кушылып киткән авыл агайлары, син ничек уйлыйсың дигән төсле, күз энәсе белән миңа төртеп-төртеп куйгалап,— ул империалистлар, хуҗа булып алып, безнекен үзләренеке итәчәкләр, каныбызны суырачаклар.

Бәхәс китә...

— Кем соң ул империалист? — дип сорый улым.

Үтемле итеп ничек кенә аңлатырга икән?

— Кеше хисабына яшәүче, дисәм дә, дөрес инде... Хуҗа булып ала да, һичбер көч түкмичә, бүтәннәрнең хезмәте аркасында җырлап кына ятучы, диимме...— Табып кына булмый бит кирәкле сүзләрне. Тарих сөйләүгә күчәм: — Элекке заманнарда татарлар империалист булганнар. Ягъни Алтын Урда дигән зур империя тотканнар. Хәзер менә урысларның шундый зур иле бар. Империя халкы үзенә буйсындырылган бүтәннәр хезмәте хисабына яшәүне гадәт итә. Ә менә инде империалист, димәк, бер кешенең хуҗа булып алуы инде ул. Һични җитештермәс, эшләмәс, коралы да булмас...

— Сорыкортмы?

— Нәкъ үзе.

Без инде кармакларыбызны җыйнарга әзерләндек. Авыл агайлары гына ашыкмадылар. Әле бераз чирттерергә исәпләре.

Шунда югалып торган теге маңкорт малай каяндыр пәйда булды һәм, кулын чиләккә таба сузып:

— Я возьму свои рыбы, они были самые большие,— диде, рөхсәт тә алмастан ике зур гына кызылканатны чыгарды, саңакларына бармакларын тыкты, борылды һәм кайтып китте.

— Әти, ул бит синең балыкларыңны алды. Андый зурларны тотмаган иде...— Улым Булат минем йомшаклыгыма аптырады да калды, нәрсә дияргә дә белмәдем.

— Империалист!..

— Кемне әйтәсең, улым?

— Әнә, һансны инде...

— Безгә балыкның калганнары да бик җиткән.

Берничә көннән тагын балыкка төштек. Теге маңкорт Һанс дигәннәре дә яр башына кунаклаган, берәрсенең кармагы бушамасмы дип көтеп торган булып чыкты. Безне күрүгә, авызы ерылды. Беренче балыкны каптыруыма ук килеп тә җитте, кармак сабына да үрелде.

— Давайте я подержу?..

Бүген җимем җитәрлек иде.

— Мохтаҗлыгым юк,— дип җавап бирдем,— үзем тотам әле.

Һанс беребездән икенчебезгә күчте. Аны кызганып, Булат улым үз кармагын тоттырды. Әмма, никадәр генә утырса да, аңа бер балык та капмады. Ул тагын минекен сорады. Биреп карадым, ул салды, аңа чиртмәде, үзем исә чүпләп кенә тордым. Бүтән малайлардан да үтенде, әмма һич кенә дә ачык йөз күрсәтмәделәр үзенә:

— Кит әле моннан, империалист,— дип кенә кудылар.

Миңа ул Һанс бик кызганыч булып тоелды. Татарча белмәвеннән файдаланып, барча малайлар аның белән юри урыс телендә сөйләшми башлаганнар, җитмәсә, империалист дип тә төрттергәләргә тотынганнар икән.

...Вакытлар узды. Дуслар белән сохбәт корып утырганымда шушы вакыйганы нигәдер сөйләргә булдым, үземчә авыл хәлләреннән хәбәр бирергә иде теләгем. Алар көлештеләр генә һәм:

— Бармак башы кадәр малай акылга утырттымы үзеңне,— диделәр.

Минем ул балык тоту вакыйгасында тойган хисләрем яңарган чак: Һанс кызганыч кебек тоела иде. Шунлыктан бу сүзләрен кабул итмәдем. Әмма ахырда, акылым истәлекләргә йомгак ясагач, аптырадым да калдым. Әйе, дусларым, чыннан да, хаклы икән.

*1997*

# Бар икән күрәселәр

Халисә җиңгинең өч малае да кеше алдында әллә кем иделәр. Бер-бер артлы үстеләр. Усалдан-усал, үҗәттән-үҗәт булдылар. Үзара кыйнашып, баш тишеп, кул-аякларын авырттырып бетерсәләр дә, кем дә кем берәрсенә тия күрмәсен, өчәүләп тиң өзеп кенә ташлый торган иделәр. Бары тик уртанчылары, иңгәбуйга бер чамада ясалып, Халисә җиңгинең нәкъ үзенә охшаганы гына, арада сабыр холыклы һәм акыллырак күренә иде. Олысы укудан әллә кем булмаса да, хезмәттә-эштә җир җимертте. Кечесе, ике абыйсының ни майтарганын карап-күреп кенә, иркә үсте. Егет булып җитүләренә, бөтен авылны бердәй тотар кебек иделәр. Тирә-күршеләре генә түгел, хәтта якындагы авылларныкылар да, боларның өчесеннән берсе күренүгә, җан калтыранып өрки, әгәр кара-каршы очраша-нитә калсалар, әйләнеп узу яки барган юлларын үзгәртү ягын карый торган иделәр. Алла сакласын, юләрнең акылында ни булмас!

Армия хезмәтенә әүвәле олысын алдылар. Ул китүгә, авыл халкы бераз хәл алгандай җиңел сулап куйды. Егетләр дә үз кызларын курыкмыйча озата башладылар. Клубта да шау-шулар бераз басылды. Икенчесе дә киткәч, бөтенләй дә дөньялары иркенәеп, күрше-тирә авылларныкылар да күзләре төшкән кызларны озатырга килгәли башладылар.

Ике ел күп вакыт икән ул. Кемнәр өйләнешеп, кайсылары кияүгә чыгып өлгерде. Теге-бу түгел, Халисә җиңгинең олы малае тагын да калынаеп, типсә, тимер өзеп, авызына сигарет капкан кыяфәттә кайтып төште. Бу елларда баш чыгарырга өлгергән яшь-җилкенчәк шым булды. Этләргә кадәр, куркышып, нигез асларына посты. Ни дә булса булырга тиеш иде. Әмма кече малайны хәрби комиссариатка чакырттылар.

— Абый,— диде ул, аулакка чакырып,— минем кыз кала... Кәримә... Кара чәчле, чибәр генә. Син аны беләсең. Югары оч Хатирә апаның кызы. Күз-колак булырсың, ярыймы?

Энесе ни үтенсә, олысы шуны кабул итте.

— Борчылма, бер кешенең дә кулын тидертмәм. Хәтерләп-нитеп торырмын. Синең өчен җан фида. Әмма дә афәрин икәнсең үзең. Инде кочаклашып-үбешеп йөрим, дисең, ә? Шулаймы?..

— Юк ла инде, абый... Әлегә сөйләшеп кенә йөрибез...

— Үбеп тә карамадыңмы?

— Кая ди ул!

— Ә яратканын каян белдең?

— Менә, кулъяулык чигеп бирде...— Егет кызарынып кына кесәсеннән яулык чыгарды, чигешләрен иркәләп сыпырып, «Сөйгәнемә бүләккә» дигән язуларын да күрсәтте.

— Кулга оста икән,— дип мактады, кызны хуплап абыйсы.

Кече малай җиңел күңел һәм олы ышаныч белән хезмәткә китеп барды. Аны озатып, инде сагына да башлауларына бер ел узды дигәндә, уртанчы уллары армиядән кайтуга, һәммәсен зур сөенеч көтеп тора иде: олы малайның туе!

Кәримәне килен төшергәннәр. Шунда ук уртанчыларына кисәтеп тә куйдылар:

— Энеңә аны-моны язасы түгел! Ишетсен колагың!

— Ә нәрсәгә?

Кияү мәртәбәсен алган абыйсы үзе аңлатып бирде:

— Энекәш миңа, ни, Кәримәгә күз-колак булырга кушкан иде. Сүземдә торырга туры килде. Кәримәне әйтәм, бер күзәтәм, ике, өч... Күзәтә торгач, сизелмәгән, йөреп кителгән. Менә шул. Бераз тотканрак чагым иде, әрсезләнелгән, саташылган. Аулак өйдә бергә йокладык та, хәзер чигенеп булмый, эш узган...

Уртанчы малаеның акыллы икәнлегенә Халисә җиңги ышана иде. Ул, чыннан да, энесен яклап, абыйсына бәйләнеп, тавыш чыгарып маташмады:

— Булган — беткән,— диде дә онытты.

Туйдан соң думбра инде ул. Өч көн баш төзәттеләр. Дүртенчесендә уртанчы малай юлга җыена башлады. Әйтми-нитми китәргә маташуын хәтерләп өлгергән Халисә җиңги ни тавышлар чыгарып карады. Әмма тотып кала алмады. Улы бөркет булып үсеп җиткән, канатларын ныгыткан, кайда тели, шунда очарга иреккле иде.

Халисә җиңгинең башын бүтән бер уй урын таба алмыйча гаҗизләргә тотынды. Әгәр дә кечеләре кайтып төшүгә, килен Кәримә бала тибрәтеп бишек янында утырса,  эшләр— харап! Башка чыгарырга иде үзләрен...

Олы малайның эшкә уңганлыгы сөендерсә дә, җае-көе юклыгы бераз читенрәк иде. Кешенең кыек-санак баласын да бәхет баса, ә моның, ни ару ирнең, һичбер тапкыр юлы гына булса да уңмады. Умырып эшләү белән генәмени ул!

Әмма, Ходайның рәхмәте, кече малайлары һәммәсен шаккатырды. Кайтып җитмәде, кечкенә чемодан тоткан бер кызны әйдәп кертте дә:

— Бу — минем хатын! — дип таныштырды.

Халисә җиңгинең өне качты. Бала тибрәтеп утырган Кәримә киленнең тәкате китте һәм:

— Сине, хайванны, бары тик мине генә яратасыңдыр, мине генә уйлыйсыңдыр, сагынасыңдыр, дип ут йотып монда ятам, ә син өйләнеп йөрисең икән!..

Бу сүзләрне ишеткән Халисә җиңгинең күзләре маңгаена менеп, бәгыре уелып төште. Олы киленен ничек дип тә аңларга белмәде. Ә кече улының авызы ерык, һичнигә исе китмичә алга узып, үзе артыннан хатынын да түргә әйди бирде. Кәримәгә исә:

— Хәзер кешене кеше көтә торган замана түгел, һәркем үз җаен карый. Үзең дә буш ятмагансың әле,— дип әйтеп ташлады.

Яшь килен дөньяның беренче чибәре иде. Аны күрүгә, бөтен авылның күзе ут булды. Кәримә килен исә, йортның тарлыгыннан зар кылып, баласын күтәргән хәлендә кайтып китте. Эштән килешли ире дә аның янына шылды. Хәлләрнең болай җиңел генә үз җайларын алуы Халисә җиңгине сөендерде исә дә, кече улына тавыш күтәреп бер сүз дә әйтә алмаслыгын аңлап саруы кайнады. Әгәр нидер кузгата башласа, шунда ук:

— Кәримәне абыйга белә торып алдырткансыз әле, анда ни карадыгыз! — дип, авыз-телләрне томалап куя торган булып китте. Ә хатыны белән чөкердәшеп яши бирде.

Халисә җиңгинең бер генә таянычы да калмады.

— Эһ, кызыбыз булмады... Бар икән күрәселәр!

Ул хаклы иде.

*Июнь, 1998*

# Сөйкемле сөяк

Гарифҗанның кемлеген белмәгәнбез генә. Хәрби уку йортын тәмамлавына, Казанның сөлек кебек кызына туй ясады. Ул вакытларда, үзегез дә аңлыйсыз, хәзерге кебек шаулатып, кунак-муйнак уйный торган чаклар түгел. Ашын пешертәсең, бәлешен әзерләтәсең дә, күңелне киң тотып, аркалыкларны бушатып бәйрәм итәсең.

Әкәмәт тә чибәр килен Бибимаһруй белән түрдә тыныч кына утыралар болар. Кайвакыт бер-берсенә йотылырдай булып карашып та алалар. Белә ул, бик белә, Гарифҗанны каптыруына сөенеп туймый. Ничә кызның башын әйләндергән, төн йокыларын алган егетнең болай җиңел генә өйләнүенең сәбәбе дә ачык: армия хезмәте башлана, инде арык-сурык йөри алмаячак. Әнә «Чаткы» кинотеатры янындагы Кәримә, ни чибәрлеге белән дан тотып та, әллә нәрсә майтара алмады. Артыннан йөргән Гарифҗанны, борыны олы дип сөймәде, инде терсәген тешли торгандыр. Ишетелгәннән генә дә шул билгеле: уты йөрәгеннән башы-

на кучеп, җанын харап иткән, урын өстендә авырып ята, ди. Бибимаһруй белән алышмакчы идеме? Белмәдеме егетнең берьюлы өч кыз белән йөри алырлык биш йөрәге барлыгын? Ә тегесе, чаттагы әптик өстендә генә яшәүче Әсманы әйт инде:

— Гарифҗанга чыгасың икән, ризалыгың да биргәнсең, алдаткансың,— дип сөйләгән була, хәсрәт капчыгы.— Минем белән дә йөрде әле ул,— диярәк мактанмаса да ярар иде.

Үзен әллә кемгә куюын сөйләмә дә инде. Чибәр дигәч тә, бер дә артык җире юк әле. Авыз төймәләндереп йөрүен күз алдына китерсәң дә, дуңгыз балалары искә төшә. Юк инде, юк! Бибимаһруйга җитәме соң?..

Туйны озынга сузып, яшьләрне ялыктырган ишле кунак төн уртасында гына тарала башлады. Йөкче Хафиз китергән бер чиләк сыра, ике чирекледән биш шешә аракы чөмерелде. Кәефләләр аз түгел иде. Кайсы яктандыр Бибимаһруйларга кардәше тиешле булганга чакырылган Хәмзә абыйларның дусты, Кәримәнең әткәсе Сафиулла белән әнкәсе Гөлбикә дә килделәр. Туйда тавыш-мазар чыкмасмы, дип шикләнүнең бер дә кирәге булмаган. Бик тыныч һәм канәгать утырдылар. Хәмзә абыйларына да Бибимаһруй рәхмәтле булды. Сафиулла урыннан кузгала, сүз тугылата башласа, тизрәк тынычландыра торды.

Туйдан соң көтелеп алынган татлы зөфаф кичәсеннән дә канәгатьлек табып, Бибимаһруй нинди затлы иргә тәтүенә чиксез сөенде. Өч көннән соң ирен ялгызы көенчә, саубуллашып килсен дип, авылдагы гомергә аралашып, кунак итешеп яшәгән кардәшләренә озатты. Юлга әзерләнәсе, кием-салым җайлыйсы барлыкны сәбәп итеп, башы әйләнүне һәм соңгы төннәрне җылы кочакта йокысыз уздырудан хәлсезләнүен яшереп, Бибимаһруй ире белән бергә барудан җиңел генә баш тартты. Аннары анысы да бар шул әле аның: аларны Гарифҗаны туена чакырмаган икән, шунлыктан бу вакыйганы әлегә әйтми калганда, дөрес булыр, диделәр. Кыскасы, сөекле ире бүген китеп, иртәгә кайтып җитәсе иде.

Көткәндә минуты да авыр шул аның. Әмма дә Гарифҗаны вәгъдәсез булып чыкты. Өченчесендә дә, дүртенчесендә дә кайтмады. Бибимаһруйның кәефе китте. «Әллә юлда бер-бер хәл булдымы?»— дип, әтисе дә күңеленә коткы салды. Туйда кәефләнгән Сафиулла абзыйның шул якларга эш белән кузгалачагын ишеткәч: «Авылларына кереп, белешеп кенә чыксана!»— дип үтенделәр. Рәхмәт төшкере, ризалашты, һичшиксез кагыласын ышандырды.

Кем белгән Гарифҗанның анда да йөргән кызы барлыгын? Сафиулла абзый килеп керсә, болар да туйлар үткәреп яталар икән.

— Син, егет, Казанда әле генә өйләнгән идең түгелме? — дигән кэрә-керешкә Сафиулла абзый, туйны өзеп.

Өстәл башында утырган каената ишетеп тә алган, кияүен якалаган да.

— Булдымы андый хәл? — ди икән.

Кияү дә яшереп тормаган:

— Булды, ник булмасын! — дигән.— Мөселманга дүрт тә фарыз. Хак мөселманмын, әлхәмдүлиллаһ!..

Барысы да аңа ияреп:

— Лә иләһү илләллаһ, Мөхәммәд рәсүлуллаһ! — дип куйганнар, капкан хәмерләренең хәрамлыгын онытып.

Каенатаның да зәһәре суынып, ачу куыгы кабарган җиреннән шиңеп төшкән. Сәвит чорында мондый әкәмәт булыр дип кем уйлаган?

Туйга бәла кебек килеп кергән Сафиулланы да шәпләп сыйлаганнар, түнгәч, арбасына салып, атын үз юлы белән җибәргәннәр. Икенче көнне айнып, кайда килеп чыкканын аңыша алмыйча, өч көн адашып йөргәннән соң гына, юл табып, Казанга кайтырга чыккан бу. Әмма шушы вакыт аралыгында чуашлар ягына ук барып җиткән икән дә Казанга кадәр яңадан ике көн буе атын куган. Ул арада инде Бибимаһруе кочагына сыенырга өлгергән Гарифҗан, икенче көнне Ерак Көнчыгышка хатыны белән чыгып киткән.

...Бер-бер артлы туган кызлары-уллары бер оя булып үсәләр, ди. Әле генә Казанда булып узганнар.

— Сине авылыңда калган хатының гомере буе көтә инде,— дигәч:

— И бахыр, бигрәкләр дә яраткан икән,— дип сагышланып та алганын сөйләгән иделәр.

Бер дә тик тормаган икән, машина яллатып, барып та килгән. Бүләкләрне дә мулдан алган.

— Гомеремнең иң чибәр чакларында көттем, инде дә чәчәгем коела башлагач кына күрештек, мәңге аерыласым юк! — дип, Гарифҗанның муенына бусы да асылынган.

Булса да булыр икән адәм баласында сынмас сөйкемле сөяк!

*Июнь, 1998*

# Багана фалы

Исмәгыйль абзыйның ике малае да, кечедән гәүдәле булып, беләктә тимер сындырып үстеләр. Аларның һәммә эш тәртибен белүенә, ялт иттереп, ай күреп кояш алганчы башкарып ташлауларына соклан-

мый мөмкин түгел иде. Кешеләр йокыдан торырга өлгерми, болар инде әллә нәрсәләр майтарырга җитешәләр.

— Бу — Исмәгыйль бәхетенә инде,— дип, әтиләре өчен авыл халкы бердәй куана, ә үз балаларын ачуланганда: — Исмәгыйльнекеләрдән оялыгыз, ичмасам,— дия-дия, җаннарын ашыйлар.

Исмәгыйль абзыйның бар эшне дә үзе башлап йөрүен, кулга осталыгын, телгә йомшаклыгын, орылмас һәм бәрелмәс булуын хәтта без, яшьләр белгән кебек үк, өлкәннәр дә яхшы аңлый, әмма нигәдер аннан үрнәк алмыйлар. Әллә хезмәтнең маймылны кешегә әверелдерүен төшенмиләр, әллә бер-бер нәрсәне безгә әйтеп бетермиләр?

Тоем дигәнең кешене алдамый икән ул!

Җәйнең балавыз эретер көннәре иде. Сабантуйлар — узган, печәнгә төшәргә — иртәрәк. Авыл халкының нәкъ каралты-кураны карый, читән-казык кага торган чагы. Без йокыдан торып кына килгәндә, ни гаҗәп, Исмәгыйль абзый кулына кечкенә күн чемодан тоткан килеш китеп бара иде инде. Өстендәге буйбуй көрән костюмы, аягындагы кара ботинкалары һәм ак күлмәге аның һичшиксез кунакка кузгалганлыгы хакында белдерә, янында хатыны Бибисара апаның булмавы гына болай уйлауның дөреслегенә шик тудыра иде. Ул, безнең турга җиткәч тукталып, башындагы фуражкасын салды, кыска итеп кистерелгән чәчен, маңгаен, муеннарын кульяулыгы белән бер-бер артлы сөртеп алды. Мине күреп, баш кагышып кына исәнләштек тә, юлын дәвам иттерде.

Инешкә йөгердем, көннең кичәгедән дә эссерәк буласына игътибар итеп тормастан, чыныгам, имеш, бер чумып чыктым. Бездә бөтен җирдән ул инешкә салкын чишмәләр кушыла.

Малай кешегә күп кирәкме? Суы элеккечә үк боз кебек түгел иде инде, анысы, шулай да җылы көннән оеган тәнне таратып җибәрергә җитә калды. Урамга менәрәк, Исмәгыйль абзый исемә төшеп, алар капкасы ягына әйләнеп карадым. Үзе киткәч, малайлары да иптәшләре кебек эшсез каласына иманым камил иде. Ялгышканмын. Тегеләр, икесе тиң куәтләнеп, Исмәгыйль абзыйларның урам як коймасын сүтеп яталар. Бер дә тик тора алмауларына хәйран итеп, әнкәйнең чәе суына күрмәсен дип, тизрәк өйгә элдердем. Мине әлегә үзебезнекеләр дә кул арасына кертмиләр шул.

Авылның күзе дә, колагы да, хәтта теле дә бар аның. Исмәгыйль абзыйның ерактагы сеңлесенә хәл-әхвәлен белешеп кайтыйм дип юлга чыкканлыгын чәй өстәлебез башына кунаклаган күрше апа сөйләп утыра иде инде. Аның саен минем өчен генә пешерелгән кайнар коймакны, сары каймакка манып, тәлинкә читеннән капкалый-капкалый гына эчкән чәй белән сыта.

Сүз уңаенда Исмәгыйль абзый өчен бераз хәсрәтләнеп тә алдылар. Юлы бу эссе көндә җайсызрак булыр шул. Бигрәкләр дә олы җанлы, кешелекле инде үзе. Ел да шушы вакытта якыннарын күреп-белеп кайтырга җаен таба, Аллаһының рәхмәте төшкере. Менә шуңа күрә дә малайларыннан уңган икән ул. Тормышы да җае белән генә бара. Аллаһының рәхмәте җирдә ятып кала димени?

Бу сүзләргә мин колак салып утырам. Коймакка үреләм, каймак ягын күзәтәм...

Чәйдән соң каз бәбкәләрен су буена куып төшерергә җибәрделәр. Менеп килгәнемдә күзне тагын Исмәгыйль абзыйлар ягына салдым. Уллары, дөбер-шатыр китереп, коймаларын сүтеп бетереп маташа иделәр. Юлымны шунда каердым. Аларның каршы ягындагы агачлык күләгәсендә минем ише ачык авызлар «таш сугыштыру» белән мәшгуль икән. Икесе — әбиләренә кунакка кайткан шәһәр сантые, берсе — елгыр күзле, тишек башлы, ком гарәбеннән дә болайрак кояшта ашалып беткән Галимҗан, безнең авылның затлы кушаматлы бердәнбер кешесе. Барыбызның аталышлары яки Бүре, йә Куян, яисә Тавык булса, моныкы ни җитте генә түгел — Граф, үзе бер титул.

Ташларын җәеп салулары була, Галимҗан җыеп кына ала. Хәрәмләшерлек түгел. Яңадан һәркем уртага берәр таш ыргыта. Һәммәсе дә тимер акча кебек түгәрәк, ваклар. Су буеннан чүпләп караганда да, андый шомаларны, уен өчен яраклыларны көне буена бишне дә табып булмый. Кулыңдагы ташны кисәк кенә итеп җирдә ятканнарның берәрсенә сылыйсың да, мач килде исә, шунысын үзеңә аласың. Юк икән, ташларыңны уртага саласың. Уенны күршең дәвам итә. Әүвәле кул белән ыргытып тидергән булсалар, аннан соң баш бармак белән чирттереп мач китерүгә күчәләр, анысы да барып чыкса, имән бармагы уенга керешә. Уң кулындагы бармаклары җиңеп бетергәч, чират сул кулга, аннан аның бармакларына тапшырыла. Ахырда — уч төбе, кул арты, терсәк башы... Безнең Граф әйтә, Казан якларында, ди, хәтта аяк бармаклары белән дә чирттерәләр, имеш. Монда әле, салада, андый осталыкка ирешмәгәннәр. Уң кулының баш бармагына барып җитә алучылар да сирәк. Ә Графның хәтта тел очы белән чирттереп тә тидергәне бар. Үзем күрдем! Ул әле тимер акча белән дә шулай уйный белә. Бервакыт ике кесәсен дә тутырган иде.

— Мач!..

Шәһәр сантыйлары эчләрен уганда, Исмәгыйль абзыйның уллары да безнең янга күләгәлеккә килеп утырдылар. Коймаларын сүтеп бетергән иделәр. Маңгайларыннан тир яңгыры ява.

— Барамы? — дип сорыйлар.

— Бара! — ди Граф.— Кәҗә майларын чыгаралар...— Сүзенә кушып баш бармагы белән чирттерә, мач килә.

— Күренә!

Граф шунда борынын маңгаеннан югарырак чөеп бер әйләндерде дә:

— Исмәгыйль абзый китүгә бүлешә башладыгызмы әллә? Коймагызны сүтеп ташладыгыз,— дип, кеше уйламаган сүзне әйтеп куйды.

Галимҗанның һәрбер шаяртуы шулай кешене мыскыллаудан гыйбарәт икәнлеген алар да белә идеме, әллә инде үзләренең кәефләре яхшымы, үртәлеп җәзаланмадылар, турыдан ярдылар:

— Яңасын коябыз! Багана чокырын казышырсың!

— Белмим!.. Ышандыра да алмыйм! — Граф шунда тагын берне бик оста итеп мач китерде.— Менә бу кәҗәләрне эшләтегез. Уйный да белмиләр. Мин тотышып торырмын.

Эшкә ризалашса, Граф була димени ул? Ничек әле багана тотышырга теләде диген? Монысы да бик гаҗәп.

Ул арада каз бәбкәләре, пип-пип сөйләнеп, алдан йөгергән әниләре артыннан чабышып урамга менделәр. Тел бистәләре: һаман такылдап кына торалар, үзләренең кайдалыгын белдереп, минем аларны саклап утырмавымны әнкәйгә белдереп! Су эченә үк кертеп калдырган идем инде үзләрен. Бер дә үлән генә йолкыйсылары түгел. Җим ашарга кайталар да җитәләр.

Аларны кабат куып төшерергә дип, артларыннан йөгердем. Тиз генә кайтмасыннар өчен, су буенда саклап утырырга мәҗбүр булдым...

Кичкә Исмәгыйль абзыйның малайлары койма баганаларын утыртып, җепсәләрен тарттылар. Граф та алар тирәсендә кайнашты. Шәһәр сантыйларыннан эш чыкмасы билгеле иде. Күренмәделәр.

Икенче көнне иртән койма коеп, кичкә кадәр туктаусыз диярлек чүкеч шакылдап торуы Исмәгыйль абзыйның малайларын мактау өчен әниләргә тагын бер сәбәп булды. Ә атна-ун көн дигәндә, этиләре бишекле мотоциклда кайтып төште. Аны китергән кеше югары оч Фәнүз абый икәнлеген танып, яннарына мин дә килеп бастым. Әмма ул озак тормады, Исмәгыйль абзыйга төенчекләрен тоттыруга китеп тә барды. Бераз утыртып йөрер, урам әйләндерер әле, дип өмет итүем юкка булды. Бу юлы кояш чыгарасы итмәде. Мөгаен, Графның һәм теге шәһәр сантыйларының да монда болгануы комачау иткәндер. Юкса кем дә алдарга бирмәс, күңеле киңлектә дан тотарлык үзе.

Исмәгыйль абзый төз итеп коелган, зәңгәрсу төскә буялган өр-яңа коймаларына, кабаттан чыгып-чыгып, сөенечен яшерми карап торды.

— Бергә эшләдек! — диде аңа Граф мактанып.— Баганаларын да утыртырга булыштым!

— Рәхмәт, энем! Рәхмәт, егетләр! — диде ул, барыбызны да олылап.

— Безнең катнашыбыз юк! — дип, шунда ук рәхмәттән сантыйлар өчен дә баш тарттым.— Графка әйтегез... Юк ла, ни инде, Галимҗанга!

Әмма Исмәгыйль абзый мине тыңлап тормады, койма башлатып нәрсәнедер күзәтте, ярыкларыннан карап, нидер күреп алды да ашыгып кереп китте. Аның йөзендәге елмаюы сүнгәнен тойдым, карашыннан кискенлек һәм усаллык уты чагылып калды. Нәрсәнедер уллары килештереп җиткермәгәнлекне төшенергә теләп, мин дә койма ярыкларыннан карап-карап алдым. Күзгә чалынырлык аны-моны тапмадым. «Әле буяулары да кибеп өлгермәгән, гаеп шунда гынадыр» дип уйлап, бу фикеремне башкаларга да әйтергә өлгермәдем, Исмәгыйль абзыйның йортлары ягыннан:

— Үтерәм, суям, оятсызлар! — дип кычкыруы котымны алды.

Ул сүзләре миңа төбәп әйтелгән кебек иде, арткарак чигендем. Шул арада капкаларыннан уллары бербер артлы очып-очып чыктылар. Артларыннан өлгергән Исмәгыйль абзый аларны сытып-ватып ташларга җилкенә иде. Без, тагын да куркышып, кайсыбыз кая сыендык. Уллары гына, һичбер тарафка качмыйча, җаннары калтыраган хәлдә:

— Әти, белмәдек шул,— дип аклана тордылар.

Шунда гына ничектер мәрхәмәте килеп, сабырлык йөгәнен кулына алган Исмәгыйль абзый:

— Иртәгәгә дөресләп эшләп куегыз! — дип әмер бирде дә өенә кереп китте.

Мескен уллары шул гөлләр кебек балкып утырган коймаларын каерып сүтәргә, бозарга тотындылар. Шунда алар янына килеп, кул араларына керергә атлыккан Граф:

— Мин дә булышыйммы? — дип тотынуга, Исмәгыйль абзыйның ике улы бердәм:

— Бар, ташыңны сугыштыр! Эш рәтен белсәң, болай көлкегә калдырырлык киңәш бирмәс идең! Табаныңны ялтырат! — диделәр җикеренеп һәм яннарыннан аны эт урынына куып.

Граф шунда ук кулларын җыйды һәм, ул-бу булмагае, диптер инде, алардан еракkарак таю ягын карады. Артыннан теге сантый иярченнәре дә тырык-тырык теркелдәделәр. Берсе, кесә төбендә тиен акчасын шалтыратып:

— Граф, әйдә акчага, Граф? — дип, уенга үгетләвендә булды.

Яңа коелган коймаларын аударып маташкан Исмәгыйль абзыйның кулга оста һәм эшкә булдыклы малайларын калдырып мин дә өйгә киттем. Ул арада көтүләр кайтып беткән, халык мал-туарларын карау белән мәшгуль иде.

Икенче көнне күрше апаларның тагын да безнең чәй өстәле янында сүз кабартмасын ялыкмый әйләндерүләреннән уянып киттем. Һаман да Исмәгыйль абзыйның улларын мактыйлар икән. Төне буе эшләгәннәр, мескенкәйләр. Коймаларын сүтеп, кабат җыйганнар, коеп чыкканнар. Инде төгәлләп-бетереп киләләр, ди.

— Ни булган соң?

Оркыя апаның соравына Гадилә түти шунда ук җавап бирде:

— Баганаларын баштүбән, очлары белән утыртканнар. Исмәгыйльгә шул ярамаган!

— Ә ни булган?

Оркыя апа тагын да шул соравын кабатлагач, Гадилә түтине аңлатып сөйләр дип көткән идем, ә ул башлаган сүзләрен дәвам итүен генә белде:

— Үчең бар кешегә генә шулай итәләр икән. Тормышы артка китсен, дип, капка-койма баганаларын төп башы белән түгел, очы белән җиргә утырталар икән, малайкаем! Менә ниләре бар бу дөньяның!

— Нәкъ шулай диме?

— Үче барлар эше икән. Әтиләренә ни ачулары булгандыр, белмим... Әмма дә улларын яткырып-изеп тукмаган.

— Сындырмаганмы?

— Белмим, ватылган-сынган җирләре юк, ди, ансы... Төне буе эшләделәр...

Минем уянып чыкканымны күреп, шикләнепме, алар шунда ук тынып калдылар. Исәнләшеп уздым да урамга йөгердем. Исмәгыйль абзыйның уллары, чыннан да, эшләрен бетереп киләләр иде. Тиз генә барып, баганаларын карадым. Аларның кичә җиргә күмелгән башлары бүген, кара бүрек кигән төсле, балчыклы башлары белән күккә карап торалар иде. Тормышлары башаяк килергә өлгермәгән, элеккечә үз җаена агачагына сөенеп исәнләштем дә, тонык сәламнәрен алгач, иртәнге чәемә кайтырга ашыктым. Юктан гына, багана фалыннан гына да тормышлар артка китәргә мөмкин икән шул, хак булса!

*Июнь, 1998*

# Яшәү сере

Яшәүнең серен борынгылар гамәлнең изгелегендә күргән. Хәерсез булу — изге гамәлне инкарь итү инде ул. Моны һәркем ике икенең дүрт булганы кебек үк яхшы белә. Әмма тормыш үзеңне диварга китереп терәмәсә, Аллаһыны да бик алай искә алып тормыйсың шул, кая ди ул изгелек һәм игелек хакында уйлау!

Мөнирә әби вафат булгач, җеназасына сеңлесе Бәрия түти дә килгән, беренче сүзендә үк, тыяла алмыйча:

— Бу дөньяда бер дә яшим дип яшәмәде. Яратмаган кешесенә барды. Аерылып та китә алмады,— дип әйтеп салган.

Бәрия түтинең кем икәнлеген белмәгән кешеләрдән берәүләр: «Бу апа саташадыр?»— дип уйларга өлгерсә, икенчеләре: «Күп серләрне белә торгандыр!»— диярәк авыз йомганнар. Ни әйтсәң дә, шул яратмаган иреннән дүрт бала үстереп, аяклы-кузле итмәгәнме соң әле ул? Җан сөймәгән кешең белән бер түшәккә яту җенгә кавышу кебек үк чирканыч нәрсә түгелме?

Җеназага кадәр ничек аягы йортларының сыңар идәненә дә басмаса, аннан соң да Бәрия түти кабат күренмәде. Тик сүзе генә, вакыт-вакыт калкып чыгып, капка төпләрендәге эскәмияләрнең берсеннән икенчесенә авыл буйлап күченеп, хәтта кичке ятакларның да җылысын һәм тынычлыгын алды. Бәндәләрнең йөрәкләре шул «Яратмаган кешесе белән яшәде» дигән сүзне телгә алуга жу итеп китә; хатыннар ирләренең күзләренә, ирләре хатыннарына, балалары ата-анасына сынап та, шикләнеп тә карый: «Йа Ходаем, Раббым, андый бәладән үзең сакла!»— дип әйтә торган булып киттеләр.

Тик дуамал Бутус кына чабатасын түргә элде:

— Мәхәббәт — юк нәрсә! Хатын — сыер, ир — ишәк! Җенесләре туры килми! Ярәштереп булмый! — дигән мөһерен дөнья йөзенә чәпәде.

Аның ул сүзләре чишмә янына серләшер өчен төшкән яшьләрнең колагын кисте. Әмма авыл, аның да сүзләрен дөрескә чыгарып, ахырда тынычлап йокыга чумарга өлгерде. Бутусның әүлиялыгы гаҗәеп тә вакытлы булып чыкты. Тик аның сүзләрен яшьли чибәрлектә дан тоткан, яратып кияүгә чыккан, иреннән итәк тутырып дөбердәп торган балалар алып кайткан, барысын да кеше итеп үстергән, инде яшен җитмештән уздырган Сабира абыстай исә аяк астына гына салып таптады:

— Ул Бутусның сыеры нидер дә, ишәге ничектер, аларын белмим. Әмма дә сөешеп барганга, яратышып яшәгәнгә ни дә җитми. Алтыным, Латыйбым гына иртәрәк үлеп китте бугай. Җитмешенә дә җитә алмады. Мәңге бергә булырбыз, диешкән идек. Китте дә барды. Ашыкты,— дип, ирен бик тә сагынып искә алды.

Кабат сүзләр кузгалды. Бер дә белмәгәнбез икән. Әллә чын, әллә ялган?

Ул Сабира абыстай дигәнебезнең ире Латыйп абзый хикмәтле кешеләрдән булган. Урамнан бер узуына, хатын-кыз тәкать бозган, капланып йөрәген тоткан. Әгәр дә аш мәҗлесләренә килсә, түргә генә утырган. Эчсә, чиләге белән күтәргән, тартса, балта элеп куярлык иткән. Кулында — эш, телендә тәмле сүз уйнаган.

Бервакыт болар туйдан кайталар икән. Латыйп абзый ләх, лычма, ди. Кыш көне. Һәркайсы үз көйләрен тапкан аяк-кулы тыңлаудан баш тарткан. Үзе җырлый, үзе сөйли икән бу. Ә Сабира абыстай бер дә аптырап тормаган, ирен тазга утыртып, шудыртып кына алып кайтып киткән. Латыйп абзый:

— Хатын, атыңны тыя төш! Бер җырлыйм әле,— ди икән.

Ә Сабира абыстай:

— Ирем, туңмыйсыңмы, көнне җылытып җибәрде бит әле? — дип сорый, ди.

Ә Латыйп абзый, хатынының бу сүзеннән хушланып:

— Майның чәчәк атканы, кызлар кочып ятканы...— дип җыр суза.

Шулай җилдереп кайтышлый өйләрен дә узып китәләр.

Икенче көнне халыкта аш мәҗлесенең хөрмәте зур булуы, кунакларның җырлашып күрше авылга кадәр барганы һәм кайтканы хакында сүз йөри. Латыйп абзыйга төрттереп, Сабира абыстайны үртәгәндәй итәләр. Ә ул, исе дә китмичә:

— Дәрт кузгалып, авылны биш әйләндек әле, ичмаса! — дип әйтеп куя.

— Ай-ай, тузмас булдың да инде,— дип, көнче хатыннар итәкләрен җыялар...

Аларның тормышлары шул рәвешлерәк барды инде, бер дә яшерен түгел. Латыйп абзый, кулга гаҗәеп тә оста булып, тоткан балтасын туры чаба, пычкысын-ышкысын уйнатып кына тора. Кызыкмаган кеше юк үзенә һәм эшенә. Аның хакында:

— Латыйп абзыйның купкан йомычкасы саен, кесәсенә акча коела, шуңа дөньялыкка исе дә китми,— дип сөйли иделәр.

Ул салган йортлар курчак өе сыман, эзе — эздә, җебе — җептә, сандык белән бер. Ул ясаган арба-чанага атны җиксәң, каян сизенеп алалар диген, әллә ничекләр уйнаклап-биепләр китәләр инде малкайлар, мин сиңа әйтим, хәйраннар каласың.

Бервакыт район үзәгеннән тикшерү максаты белән авылга вәкил килеп төшкән. Тарантасы шундый да җиңел кебек, шундый да күркәм икән моның. Аты да ни җитте генә түгел. Ак бәкәлле, солдат хезмәтен үткән, әфисәрләрне генә йөрткән. Имеш, маршал Рокоссовский үзе аңа атланып парадта катнашкан. Исеме дә Өрәкитә икән.

Район үзәгеннән чыгып килешли, вәкил, юл тузанын кубарырга өлгерми, безнең күмхуҗдан ат чаптырып барып җитешкән рәисебез Хәйрулла абзыйга очраган. Танышлар шул. Хәл-әхвәл сорашканнар.

— Кая барыш? — ди икән вәкил.

— Менә, эш йомгакларын илтәм,— ди икән Хәйрулла абзый, тузып беткән, күпне күргән, әмма кабинет тузаныннан мәхрүм калган, төсен югалтса да, таралырга ашыкмаган портфелен күмхуҗ арбасының төбеннән күтәреп күрсәтеп.

— Хуш,— дигән вәкил.— Бик яхшы! Ә мин — сезгә идем әле... Эшләрегезне карап кайтырга, тегесенмонысын, әйе!..

Хәйрулла абзый, әлбәттә, район үзәгенә барган вакытларда гына сакал-мыектан кырыла торган какча яңакларының ут кебек кызаруын яшерергә теләп, күмхуҗ эшендә алдау-йолдауларын вәкил белеп өлгерәчәген уйлаудан тәмам борчылып, әпен-төпен генә саубуллашкан да юлын икеләтә яхшырак тизлек белән дәвам иткән. Бу хәлдән, дөрес инде, тикшеренергә баручы, баш мәсьәләсендә өлешсез калмаган вәкилнең дә күңеленә корт төшеп, акылы хәйран иткән. «Тукта әле, үзе югында барып керим дә белим әле, өстенә басарлык булыр. Кыңгыр эшләре күптер!»— дип, Өрәкитәсенең тизлеген шулай ук ике мәртәбәгә арттырган.

Көннәрнең яхшы торган чаклары икән. Авылга вәкил карчыгадай килеп төшмәсенме! Уе бер генә: хәзер боларны утлы табада биетәм, туры юлга чыгарам, башларын ашыйм, имеш.

Идарәгә килеп кенә җитә, ишек төбендә авызын ерган шул ук Хәйрулла абзый каршы ала:

— Исән-сау гына ирештегезме, кордаш? — ди, аңа тарантастан төшәргә булышып.

Вәкил кызган хуттан әлегә аны-моны абайларга өлгермәгән икән. Ачык ишеккә килеп җиткәндә генә искәреп ала да:

— Эш йомгагын тапшырдыңмы? — дип сорый.

— Әйе,— ди Хәйрулла абзый,— план бүлеге мөдире Сәфиуллинның үз кулына тоттырдым, төгәл сәгате белән әйткәндә, тугыз да биш минутта.

— Алай,— ди вәкил, ни уйларга да белмичә.

Шулай да, сәгать сүзе чыкканлыктан, кулындагыдан вакытны карый. Уннар тулып кына узган икән.

— Ничек болай миннән алда җитештең? Узып киткәнең дә күренмәде...

— Безнең арбалар яхшы шул, сәвитнеке, тарантас ише түгел,— ди Хәйрулла абзый, серен сатып.

Әмма вәкилнең нигәдер ышанасы килми. Хикмәт арбада буламы соң, атта ул, имеш...

Кичкә, төянеп һәм төялеп киткәндә, үзенең җиккән аты Өрәкитәсен калдырып, Хәйрулла абзыйның аты белән элдерә. Тарантасы үзенеке инде. Әмма күмхуҗ тае шулкадәр йөк белән бары тик иртәнгә генә район үзәгенә кайтып җитә. Ә Өрәкитәне Хәйрулла абзый үз арбасына җигеп чыга, йомычка урынына гына очырта, ди, үзен.

Вәкил өченче көнне кичкә тагын күмхуҗ сыртына козгын булып килеп куна. Атларын алыштыруны дәгъвалый, хәтта тарантасын да калдырып, бу юлы Хәйрулла абзыйның арбасында Өрәкитәсе белән очкан бу. «Әйдә!»— дип әйткәнендә күзен йомган гына, инде район үзәгенә килеп җиткән. Әгәр дә мәгәр:

— Кем чаптырта анда? — дип, үзәк участок милиция майоры Гапсаттаров каршылап, ат башыннан тотмаган булса, Сарманны узып, Чаллыга ук барып җитәсе икән.

Хикмәтнең арбада икәнлеген аңлап алгач, сүттереп караганнар. Һичнинди аермасы юк икән. Шул ук күчәрләр, шундый ук кыршаулы дүрт тәгәрмәч, тәҗе-бәҗе дигәндәй.

Серне чиштерер өчен Хәйрулла абзыйны районга алдырткannar. «Себер дөмектерәбез!»— дип куркытканнар. Имеш, партбилетың кесәдә йөрткән хәлдә, сәвиттән сер яшерәсең!

Бөеренә таянган прокурор сорау ала, ди моннан.

— Бу бары тик Латыйпның гына эше! Ул ясады, ул гына гаепле,— дип аклана икән Хәйрулла абзый, кирәр тишек таба алмыйча.

Китертәләр Латыйп абзыйны. Сорыйлар:

— Синең эшме?..

— Нәрсә?

— Арба!

— Ә, арбамы? — ди Латыйп абзый, әлегә сүзнең ни хакында барганлыгын ачык кына төшенә алмыйча.— Арбаны мин ясадым, әмма монда ничек килгәндер, белмим!..

— Ансы безгә дә кирәкми,— диләр аңа, ни сораганнарын үзләре дә ачык итеп әйтә алмыйча, башлары тәмам буталып: — Бу арбаны хактан да син ясадыңмы?

Латыйп абзый инде болай тагын да кайтарып сорауларыннан соң шиккә кала. Ни уйларга да белмичә, арбаны биш әйләнеп чыга. Алла сакласын, халык дошманы исемен тагулары да бар...

— Йә-йә, җитте,— диләр моңа,— чыршы бәйрәме түгел, әйләнеп йөрмә! Әйт, ясадыңмы-юкмы?

«Әйе, дисәм, ни икән дә, юк, дисәң, ни икән?» дип башын кашый Латыйп абзый, тәмам гаҗизләнеп.

Бераздан соң гына:

— Ясаган идем шул... Гафу итегез!.. Әмма кемгә, хәтерли генә алмыйм, оланнар,— дигән сүзе белән катып кала.

— Тагын ясыйсыңмы? — диләр, аны сырып алып.

— Яраса, ясармын, ярамаса, ясамасмын,— ди Латыйп абзый, әле шөлләп, әле батыраеп...

Сөйләүләренә караганда, ул елны күмхуҗыбыз еллык табыш буенча районда гына түгел, бөтен Рәсәйдә беренчелеккә чыккан. Латыйп абзый ничә арба, ничә чана ясаганлыгын да оныткан. Аңа бары тик йомычкасы гына калган. Шуңа да инде аның хакында: «Кубарган йомычкасы саен, кесәсенә акча коела...»— диләр. Машина заманы ирешкәч тә, төшенә шул арба-чаналар кереп, саташып изаланган, мескен.

Кемнәр ничектер, әмма мин үзем аның булганлыгына, осталыкта тиңсезлегенә соклана идем.

Сабира абыстайның шушындый да ирне яратмаска һичбер мөмкинлеге калмаганлыгы мәгълүм иде. Әгәр дә яшәүнең сере нидә икән, дип баш катырсагыз, һичбер яшермичә, аларны мисалга китереп әйтә алам: ышаныч һәм җан тынычлыгы китерүче изге һәм игелекле гамәлдә ул! Шундый эшләрең булса, татлы мәхәббәттән дә өлеш тәти, бәхетең дә арта, бер дә яшерен, аңламаслык нәрсә түгел болар.

*Август, 1998*

# Әхмәтвәли гыйшкы

Татарлар балаларына катлы-катлы исемнәр кушарга яраталар инде ул. Сәбәбен дә беләм, борынгы ырым-ышанулардан ук килә бу. Баланы әүвәле исеменең беренче каты белән атап йөртәләр-йөртәләр дә,

авырып киттеме, шунда ук икенче катына күчәләр. Имеш, шуннан соң ул саулык-сихәт таба. Исемнең хикмәте бар инде анысы, яшереп торасы түгел. Гайфи көлдерә, Шамкай шамакайландыра, Мөхәммәд динле булырга мәҗбүр итә. Барысын бергә кушсаң...

Мөмкин хәл, әйе. Берсе булмаса, икенчесе җисеменә туры килер диптер инде, мулла куйган Әхмәткә Вәлине өстәп, әтисе улының таныклыгын Әхмәтвәли дип яздырып кайткан. Шәһәр җирендә биш катлы да килешә, имеш. Шул көннән бирле әнисе дә, күңеленә килгәндә, аны «Әхмәтем!» диярәк сөеп, ачуланганда «Вәли чукынчык!» дип, исеменә кяферлек галәмәте өстәп, кул күтәреп орыша торган булып гадәтләнеп киткән. Шунлыктандыр инде без аны Вәли дип кенә йөртә, Әхмәт икәнлеген исәпкә дә алмый идек. Хәер, аның моңа үзенең дә исе китмәде. Егет мәртәбәсенә җитүенә, и бәхетле, ике катлы исеменең уңайлыкларын татый башлады бу.

Аның хәтта борыны да ике диярлек, кеше кызыгырлык. Танышканда кызлар анысына да, монысына да игътибар итми калмыйлар. Әхмәт исә, ягъни Әхмәтвәлине әйтәм, төссезрәк кешеләрдән булса да, искә алынган борынга гына түгел, телгә дә бай, Аллаһының җырга да бәрәкәтле затларыннан берсе иде. Эсселәтми-суытмый, сыйпамыйча тотмый, дигәндәй, аның каршында хәтта тәкәббер һәм үзсүзле хатыннар да тәкатьсез кала икәнлеге хакында ишеткәләгәнем дә булды. Әмма ул яманатын таратып хурлыкка калмады бугай. Исеме коткара килгәнен яшермичә сөйли алам. Берәү белән танышканда-белешкәндә, үзен Әхмәт дисә, икенчеләр аның Вәли икәнлегенә шикләнми иделәр.

Йөрде егетебез, бер дә сер түгел, бик йөрде шулай Казан буйлап, матурдан-матурны күзләп, чибәрдән-чибәргә күз салып һәм кысып, чәчәкнең берсенә Әхмәт буларак кунып, икенчесеннән Вәли исеме белән очып китеп. Дөрес, бар яктан да килеп җитмичә, егетебезнең бер ягы китегрәк иде. Ул да булса, искәртеп узганымча, төсе юк! Менә кемне генә дә мисалга алып кара, ниндидер үзенчәлекле, бүтәннәрдән аермалы төскә ия, болындагы чәчәкләр, хәтта күбәләкләр дә шулай. Ә менә Әхмәтвәли, Ходайның бәндәне бар иткәндә бирмеш барча мөлкенә хуҗа булып та, төстән мәхрүм иде. Моны сизенгән кеше генә искәрде, тойганы гына белде. Ә игътибар итеп тормаучылар күбрәк иделәр. Шушы төссезлеге Әхмәтвәлине һаман хәрәкәтләнеп торырга, теленә салынырга, бүтәннәрнең күз уңына керү өчен, иң кимендә, җырлап җибәрергә мәҗбүр иткәнлеген бик сирәкләр белде. Мәктәптә укыган чорында да хәлләр шулайрак булды. Укытучыларга кадәр, алларында сыйныф журналы ачылып куелуга, анда һәммәбезнең фамилиясе язылуга, шуннан укып кына сорау биреп утырасы урында, Әхмәтвәлине парта артыннан чыгару, такта янына гомеренә бер тапкыр бастыру хакында уйлап та карамадылар. Чөнки аны күрми иделәр булырга кирәк. Ул гүяки пыяла кебек. Төссез. Тәртипсезләнеп, комачаулап сөйләшсә дә, тик тыңлап утыручы безгә эләгә, аз гына селкенеп куюыбызга да укытучылар түзә алмый. Ә Әхмәтвәлигә бар да бата. Төссез, чукынган, кеше күзенә чалынмый. Аңа — рәхәт, аны сизмиләр дә, белмиләр дә, күрмиләр дә, исәпкә дә алып тормыйлар. Ә менә безгә генә читен, селкенү дә мөмкин түгел, уңга бассак та ярамый, сулга борылсак та. Теңкәләребезне корытып бетерәләр. Миңа барсыннан да артыграк эләгә. Әхмәтвәли кызларның чәчен тарта, гаебе аның янындагы миңа төшә. Әхмәтвәли малайларның юлына аяк куя, чалып ега, нәкъ шул вакытта бүтән урамда, мәктәпнең башка катында булсам да, мине гаепилиләр. Бәхәсләшеп кара син ул өлкәннәр белән, бәйләнер нәрсәңне барыбер табачаклар, иң кимендә:

— Ни өчен чәчеңне уңга түгел, сулга тарадың? — диячәкләр.

Беләм мин аларны, бик күп сүз ишеттерделәр, такта алдына чыгарып, директорга чакыртып, линейкада укучылар алдына бастырып, әллә ничәләр тапкыр ачуландылар, юк гаепләр тактылар. Әмма барыбер бирешмәдем.

Бу Әхмәтвәлине әйтәм, Казанның иң чибәр кызына өйләнгән икән. Язылышырга баралар, ди болар. Яңа пешеп килгән калач кебек бер кашык сусыз да йотарлык кәләше сөйли моңа:

— Гөлнәзирәне теге мин әйткән төссез Вәли ташлап качкан, йөкле итеп...

— Алай икән! — дип куя Әхмәтвәли дә, ул Вәли белән бу Вәлинең бер үк кеше булмавын раслап, башын чабарга бирердәй кыланып.— Безнең туйга Гөлнәзирәңне чакырмадыңмы соң?

— Сез нәрсә? — ди икән аның куенындагы кәләше Зәмфирә.— Халык алдында, ул йөге белән чакырып, үзебезне адәм мәсхәрәсе ясап рисвай итәргәме?

— Ансы да бар шул, дөрес, җанкисәккәем! — дигән Әхмәтвәли дә.

Туйда кәләше, нидер сизенеп:

— Болар нигә сине Әхмәтвәли диләр?.. Вәли исемен кушып сөйлиләр? — дип сораган икән дә шунда ук җавабын да алган:

— Мулла кушкан исемем булганга!

— Ә мин Әхмәт дип кенә йөртсәм, начар түгелме? — Яңа пешеп килгән калачтай кәләшнең болай назланып соравы пычактай үткен кияүнең күңеленә хуш килеп, җаны нурланган.

— Бик яхшы булыр, җанкисәккәем! — Җавабы белән бергә рөхсәтен дә биргән.

Әхмәтвәлинең законлы хатыны, кайнар кумәч Зәмфирәдән бер-бер артлы ике баласы туып, үткен пычак иренең тәрбиясендә ике адым да читкә чыга алмыйча үскәннәр. Әмма теге Гөлнәзирәсен дә онытмаган, чукынчык, аңа Вәли булып барып йөргән. Андый вакытта төссез кеше булуның файдасы тия шул ул. Бу гына да түгел, җитмәсә, Казанның бер башында Әхмәтвәли икән үзе. Икенче очында — Әхмәт, өченче ягында Вәли исемендә, шулай төрле сыйфатларга кереп йөрүен дә дәвам иттергән.

Төссез кешенең картайганы да сизелми икән аның. Безнең әллә кайчаннан кыяфәтләр үзгәрә башлады, төсләребез уңарга тотынды. Ә ул, һаман шул килеш йөреп, илле бишендә егерме тугыз яшьлек кызга иярләнеп китте.

Китте, дидем диюен, әмма ни шул әле, ул вакытта аның мондый кети-метиләреннән хәбәрдар түгел идем. Хатыны Зәмфирә белән икәүләшеп Әхмәтвәли безгә килеп-киткәләп йөриләр. Ашка-фәләнгә генәме, кинәшкә һәм бурычка да кергәләргә өйрәнеп беттек. Тагын ул гына да түгел, Әхмәтвәли белән Зәмфирәнең аерылышу хәбәрен ишеткәч, аптырашып калдык. Ни ниткән галәмәт тагын? Чибәрлектә һәм күркәмлектә тиңе булмаган йомшак кумәч хатыны каршысында төссез, әмма үткен пычак Әхмәтвәли биеп кенә:

— Җанкисәккәем! — дип тора иде.

Нәрсә булган боларга? Җете кызыл тиз уңа диярлек уңарлыгы да юк бит!

Бу хакта хатын да, мин дә сүз кузгатырга куркып йөрдек. Аллаһ сакласын! Әллә ни булып куюы, гайбәттән гөнаһ галәмәте чыгуы бар. Сүзнең зәхмәте тия, диләр, бигрәк тә артыгын сөйләшсәң.

Хәер, алар рәхәт яшәделәр. Өстәлләре ризык һәм тансык сый белән сыгылып торды. Искәрткәнемчә, ике бала — бер малай һәм кыз үстерделәр. Берсеннән-берсе чибәрләр. Күзне сөендерерлекләр. Кадерле улларын хәтта өйләндерергә һәм үзчән-телчән киленнәренә җитәкләтеп чыгарып җибәрергә дә өлгерделәр. Килеп тә карамыйлар үзләренә. Кызлары да тиздән бәхетен табар кебек иде. Аллаһ бер һәм бар ул!

Әхмәтвәлине озак еллар күрмәдем. Тик хатыны гына аны сагына, безгә кергәләп, иренең кайда, кем белән торуы хакында сөйләп чыга торган иде. Кызларын кияүгә биргәнендә туйга чакырып, безне өстәл башында утырттылар. Зәмфирәнең элеккеге чибәрлеге, матурлыгы өстенә уңганлыгы һаман да аны бүтән хатыннардан өстенрәк итеп күрсәтә, хәтта ки: «Бу Әхмәтвәли юләрдер! Бүтәнчә булмас!»— дип, аерылган ире хакында уйлап та куя идем.

Кабан күле буенда гадәтемчә истирахәт кылып йөргәнемдә каршыма бер төссез адәм килмәсенме?

— Хәлләрең ничек? — ди бу миңа.

Шаккатудан югалып калган идем.

— Каян болай? — дим, соравына сорау белән.

Кәефнең шәп чагы иде. Бөтен тарафны чәчәкләр һәм яшеллек күмгән май аеның соңгы атнасы, җылы кояшның күл өстендәге дулкыннар белән лепе-лепе китереп күзгә уйнатулары, гомумән дә эчем-тышым кош сайрауларына ихласланып йөргән вакытларым иде, Әхмәтвәли шунда тагын да сорап куйды:

— Су төбеннән чыктыңмы әллә, дисеңме?

Аннан соң йөземә сынап-сынап карап алды. Әмма үзе күзләрен миннән яшерергә тырышты. Гөнаһлы малай кебек башын түбән иеп, ботинкаларының әле укчә артын, әле башын, аягын уң-сулга чалыштыра-чалыштыра карады.

— Яшь хатын алганыңны ишеттек,— дидем, һич тә исем китмичә.

— Сез Зәмфирә яклы инде! — диде Әхмәтвәли дә, һөҗүмгә күчеп.

— Нәрсә диим инде...— Чыннан да, бүтән төрле әйтер сүзем юк иде. Ачулансаң, үтмәячәк, киселгән икмәкнең телеме ялганмый, аның гамәлләрен өстенгә чыгарсаң, имансызлык һәм икейөзлелек була.

Шунда Әхмәтвәли акланган тавыш белән сөйләп китте:

— Мин Зәмфирәне ярата идем шул. Бик тә ярата идем... Бүтән кеше белән йөргән, белмәгәнмен генә... Эшенә баргач, Зәмфирәмнең шул адәм ахмагы белән бергә сөйләшеп утыргалаганнарын күргәнем дә бар иде. Менә ничек ул...

Кабан күленең суы ничә чиләк булыр, дигәндәй, чиләгемнең сыйдырышы шактый икәнлеген исәпләп, аның сүзләрен тыныч кына тыңлый бирдем. Казан шәһәре иләмсез һәм зур булса да, аның эчендә сүзләр тиз йөри, мин дә Әхмәтвәлинең үзеннән, һичшиксез, егерме алты яшькә яшьрәк кызны хатынлыкка алуын, хәтта ки бер малай да үстереп ятуларын ишеткәнем бар иде. Бу хәбәрләрнең хакмы-түгелме икәнлекләрен сорап тормадым, сөяксез телендә сүз борчакларын сикерткәнен тыңлый бирдем.

— И яраттым да инде шул Зәмфирәмне! — дип, очынып һәм күзендәге яшьләрен сөртә-сөртә сөйләнүендә булды Әхмәтвәлиебез, минем аны-моны белү-белмәүләремне исәбенә дә алып маташмыйча.— Шул мужик белән йөргән, өстемнән йөргән...

Зәмфирәнең дә әйткәннәреннән бер ишеткән идем: имеш, Әхмәтвәли, аннан аерылып китеп, яшь хатыны белән өч ай да тормаган, үзе кебек төссез бала алып та кайтканнар, дип. Һе, алай булгач, кайсы кемнең өстеннән йөргән икән боларның?

Мин һаман да авызыма май каптым. Әхмәтвәли туктамыйча сөйләнә бирде:

— Мине беләсең бит...

«Белмәү кая!»— дияргә уйлап та карамадым. Белми, дип уйласын әле!

— Мине беләсең бит! — дип кабатлады ул шул ук сүзләрен, борынын бераз югарырак чөеп, күбәләктәй канат кагынып.— Ил күгендә очкан бөркет кебек һәрнәрсәне сизенеп-аңлап йөрдем. Беркөнне Зәмфирәнең миңа: «Мин үземнең кешемне таптым, син дә үзеңә караштыр инде шунда!»— дип әйтәсен көттем. Шулай булып та чыкты!..

Әхмәтвәли күзен дә йоммый алдый иде кебек. Мин исә: «Юк, алай түгел, хәлләр болайрак булганнар!»— дип каршы төшмичә, сабыр гына тыңладым да тыңладым. Тик вакыт-вакыт кына:

— Тәкъдирдә ни язылганын бер Ходай үзе генә белә! — дип, яки:— Алай икән, һе!..— дия-дия, баш кагып яисә боргалап алгаладым.

Хәер, Әхмәтвәлигә акыл өйрәтергә җыенмый идем. Шунлыктан бары тик тыңлап кына торуны кулайрак күрдем.

Кабан күле буенда яшьләр дә йөри иделәр. Кайсылары — пар-пар, ә күпләре — төркем-төркем. Арада үбешкәннәре, кочышканнары һәм сөю-сәгадәт диңгезендә акылларын адаштырган мәҗнүннәре дә бар иде. Алар көлешкәләп калдылар, без исә Мәрҗани урамыннан театр тарафына таба бик тәкъва вә җай гына атлап бардык. Юлның очына килеп чыккач, бераз таптанып торып, аннан кире борылдык. Шулай йөренә бирдек.

— Мин әле Зәмфирәгә атап җыр да чыгардым...— Монысы минем өчен көтелмәгән яңалык иде.— Җыр дип инде, шигырен дә, көен дә үзем эшләгән идем, аннан яхшы көйче һәм шагыйрь белән эшкәртергә кирәк икәнлеген әйттеләр. Болай начар түгел. Тыңлаганың-ишеткәнең юктыр?.. Хәнәви Шәйдуллин репертуарында!..

Ул көйләп тә җибәрде. Аның җырлаганын тыңлаштыргалаганым бар иде. Минем колакка матур булып ишетелде. Зәмфирәне чыннан да ай-һай гына үлеп-өзгәләнеп яраткан, һич тә оныта алмый икән, дип уйладым. Аның мәхәббәте гыйбрәтле дә, мәгънәле дә кебек тоелды. Аларның кабат бергә булуларын күңелемнән теләк тели генә башлаган идем, яшь хатынының җылы кочагында карт сөякләренең шифаланып иркәләнүен һәм наз табуын, малай да үстереп ятуларын әле дә ярый исемә төшердем һәм сүзгә кучәргә атлыккан телемә тозак салдым. Тагын да шактый сүзләрен ишетеп, аннан соң сәгатенә карап, гафу үтенеп, ашыга-ашыга китүен артыннан карап калдым. Менә Әхмәтвәлине моннан соң да һаман төссез икән, дип әйт! Биредә Зәмфирәсе аны сагынып елый, тегендә яшь хатыны аңа җанын фида кылырга әзер! «Һай егетләр-егетләр, кая безнең кебекләр!»— диярсең, болай булгач.

Әмма Әхмәтвәлинең вакыйгалары моның белән генә бетмәде. Озакламыйча аның хакында яңа сүзләр таралып, өченче һәм дүртенче, һәм бишенче, һәм алтынчы хатыннары да булганлыгы, аларда да балалары үскәнлеге беленде. Зәмфирә белән мәхәббәт корып яшәгән чакларында да тик кенә тормаган, ирлек буасының суын мулдан файдаланган булып чыкты.

Бервакыт безгә Зәмфирә кергән иде. Бик тә хурланып, әмма киң күңелләнеп, белгәнен-ишеткәнен кабатлап-кабатлап, озак кына сөйләде:

— Ул, малай җаным, балаларын бер дә барып карамаган, аларга сыңар күлмәк тә алып бирмәгән. Оятсыз ул Әхмәтвәли! Әле Әхмәт, әле Вәли булып йөргән. Әтисенең эше инде, әтисенең! Улы ике төрле булсын өчен, катлы-катлы исем куйдырган аңа, бер дә башкача түгел! Әле, Аллаһы боерса, теге баласын ятим үстергән хатыны янына да бер күлмәк кыстырып барып кайтам. Ул малае да нәкъ Әхмәтвәли, ди. Барам әле, барам! Аллаһы боерса! Кара инде аны, сыңар яулык та алып бирмәгән...

Шушы сүзләрен хатын белән сөйләшкәннәрендә тыңлап утырдым да, күңелем йомшарып:

— Синең хакта, Зәмфирә, Әхмәтвәлине әйтәм, җыр язган икән әле,— дип белдердем.

— Һи, беләбез аның ул җырын, бишбылтырдан бирле беләбез! — Зәмфирә тезеп-тезеп китте һәм өстәп куйды:— Бөтен хатыннарына да шулай дип йөри икән. Имеш, җыр язган! Сиңа гына атап!.. Ышанмагыз, булмаганны! Юри генә сорагыз әле үзеннән, ул җырыңны Миңнуллин язмадымы, дип... Үзләштерде, үзенеке итте, диячәк... Әйтте диярсез!.. Инде ничә кешедән ишеттем, алдый ул, ялганлый!..

Инде дә күз алдымда төсләнгән иде дигән Әхмәтвәли шунда кабат элеккечә төссезләнеп калды. Аның сүзләрен исемә төшердем, хәтерем китеп, озак кына хәйран итеп утырдым һәм, ахырдан:

— Мондый гыйшык Әхмәтвәлидә генә була ала! — дип куйдым.

Әхмәтвәлинең гыйшкы — анысы да төссез икән!

*Октябрь, 1998*

# «Игорь кенәз»

Миннән нигәдер артист ясамакчы булдылар. Әйе-әйе, дөрес сүз, ялган түгел! Бу хәл минем үз башымнан егерме еллар элек узу сәбәпле, бүген аның бары тик хәтердә генә яңарган вакыты шул. Бәндәләр белән һаман да булгалый торган нәрсә — хәтере яңарып ала. Сәламәтлек билгесе ул. Кызыклы вакыйгалар искә төшсә, күңелләр күтәрелеп куя. Минем белән дә искә алырлык хәлләр булгалады. Мәсәлән, дип әйтик инде, бу хакта, ягъни «Игорь кенәз» исеме астында сезгә сөйләргә җыенган бу вакыйганы, Каһирәдә уздырылган гыйльми конференциядә чагымда, бер инглиз галименә бәян кылып, боек күңелен күтәреп хәйран иткән идем. Ул, минем каләм иясе кеше икәнлегемне белгәнлеге сәбәпле, берничә мәртәбә үгетләп тә карады:

— Язгыгыз моны, һичшиксез, хикәя яки истәлек итеп язгыгыз!..

Әмма бер дә вакыт җитмәде, Аллаһының амин сәгате ирешмәде. Инде хәзер, мөгаен, ул хаклыдыр, җылы гына әсәр чыгарга мөмкин, кем белә, дип, менә эшкә тотындым әле. Ходай рәхмәтеннән аермасын!..

Ә вакыйга болай башланып китте...

Мин ул елларда Казан университеты студенты идем. Алдымда алга әйдәүче максатым, тапкан юлым ачык, һәм ул килер көнемне якты итеп күз алдыма китертә, кимендә дөньяга яхшы исемем белән танылачагыма һичбер шигемне калдырмый иде. Әмма болар бары тик хыял гына булганнар, күрәсең, мең пот тоз ашыйсыларым, көне-төне эшләп тә нәтиҗәсеннән сөенә алмыйча гаҗизләнәселәрем гомерлек иде.

...Хәзергә укып йөрим. Безнең аудиториягә, ягъни лекцияләр залына, мөхтәрәм бер әфәнде керде һәм:

— Бүген Казанның иң шәп театрында — Опера һәм балет театрында — «Игорь кенәз» була, барыгызны да шунда чакырам! — диде.

— Борис патша булса да, барасыбыз юк! — дип борын чөйде безнең студентлар, операга күңелләре тартмавын әйтеп тормастан шаяртып.

Бары тик мин генә:

— Бер билетыгыз булмасмы? — дидем.

Ишетмәде дигән фикергә килеп өлгергәнемдә, ул җавап та бирде:

— Булмас шул!

— Кызганыч,— дидем, башымны иеп.

— Ә мин сезне бушка чакырам!..— Ул әфәнде каршыма килеп басты.— Уенда катнашырсыз! Операда!

Аның бу тәкъдименә аптырап калмау мөмкин түгел иде. Ни сөенергә, ни көенергә белмичә:

— Уку залына керәсе идем, гафу итегез... Бүген Мольерны сораттым...— дисәм дә, әфәнде өметен югалтмады:

— Аңынчы биш мәртәбә укып чыгарга җитешерсез әле. Уен сәгать кичке җидедә генә башлана. Күз алдына китерегез: йөзләрчә тамашачы каршында уйнаячаксыз!.. Театр түгәрәгендә берәр роль башкарганыгыз бар идеме?

Мин дә бирешмәдем:

— Әйе, бар иде,— дидем.

Ул тагын да ялгап китте:

— Әйтәм аны...— Салпы ягына салам кыстырырга да өлгерде.— Бөтен ягыгыз да артистлар кыяфәтенә туры килеп тора. Әйе-әйе! Менә бу — сезгә! Шушы чакыруны күрсәтәсез дә сәхнә артына узасыз. Анда барысын да аңлатырлар...

Ул арада елгыр егетләребез безне уратып алдылар һәм шундый ук чакыру билетларына ия булырга ашыктылар:

— Безгә дә, безгә дә! Без дә барабыз, без дә!..

Теләүчеләрнең һәммәсенә дә өлеш чыкты. Шулай итеп, барчабыз да опера артистлары булып китәргә уйладык. Кайда-кайда, ә менә Казан шәһәренең нәкъ уртасына урнашкан данлыклы Муса Җәлил исемендәге Опера һәм балет театрының олуг сәхнәсендә көннәрнең берендә артист сыйфатында чыгыш ясармын дип кем уйлаган? Дөресләп искәртергә дә кирәктер, мине сәхнә тормышы бер дә үзенә тартмый һәм, гафу, артистларны хәтта тиенгә дә санамый идем. Авыз күтәреп җырлап йөрүдән дә бушрак һәм хәерсезрәк бүтән нинди гамәл бар, дип фикер йөртүдән артыгына бармадым. Әмма тамаша ясауларын, театр уенын бер булса да күреп калырга тиешлегемне, шуннан соң сәнгать белән һич тә алыш-бирешем калмаячагын күңелгә төртеп куйган идем. Һәм менә — язмышның шаяртуы, бүген үзем дә уен сәхнәсенә менеп басарга тиешмен. Бу билгесез дөньяның сәхнә артын карап алуымнан алдымда торган максатлы юлыма хилафлык килмәскә тиеш иде дип белдем.

Театрда мине хуплап каршы алдылар. Хәтта аерым бүлмә биреп, каршыма һәртөрле киемнәр, кылыч, сөңге, калкан кебек сугыш җиһазлары китереп аударгач, өнемме бу, төшемме диярәк, аптырап ук калдым. «Сез ялгышасыз, кем беләндер бутыйсыз!»— дип әйтәсем, хәтта киреләнәсем килде. Әмма минем белән күп сөйләшеп-аңлашып торырга теләүче күренмәде. Ачык ишек төбенә кыяфәтле артистлар һәм җырчы бикәләр анда-санда килеп тамак кырды, операдан теге яки бу кисәкне сузгалап-сузгалап та җибәрүчеләр табылды. Уенга керешкәнче, һәммәсе дә тамак төпләрен ныгыта, телләрен югарта яисә, киресенчә, калынайтырга тырыша иделәр. Өч яклы көзгедәге шәүләләрен тамаша кылып, кенәз киемендә утыра бирдем. Бу опера дигәннәрен бер генә тапкыр да күргәнем юк иде, нәрсә эшләргә тиешлегемне дә белмәдем. Хәер, юри шаяртып кына шушы рәвешле киендергән булсалар да, үпкәлисе түгел идем. Артымда кемнәрдер сөйләнә бирде:

— Фуат Мансуров үзе дирижерлык итәчәк!..

— Харап кына булмасак ярар иде!..

— Сез нәрсә, бик хәер хаһ затлардан ул!..

Дөресен әйтим, минем өчен Фуат Мансуров исеме берни хакында да сөйләми иде. Әгәр дә Чыңгыз Айтматов, дисәләр инде, ул вакытта аңлашылыр иде. Чөнки әдәбият өчен, иҗат өчен, туган илемне һәм җиремне, әтием-әниемне калдырып, шушы ач һәм юксыллар шәһәре Казанга килдем.

Сәхнәгә чыгарга дәштеләр. Уен бара иде инде. Минем кебек үк киенгән егетләр төркеменә кемдер нәрсәләрдер аңлата иде. Мин дә алар янына килеп бастым. Ул арада сәхнәгә дә чыгардылар. Игорь кенәзнең кыпчакларга каршы сугышка барырга җыенуы һәм, гаскәрләрен туплап, хәерле сәфәр өметендә табынулары вакыйгасы иде. Мин исә шыгрым тулы залга югарыдан карап алдым. Без биек итеп ясалган басмада идек. Аннан баскыч сәхнә уртасына таба төшә. Ул урында хатыннар һәм кенәз Игорь үзе, җырлый. Менә кояш тотылды. Уенда мәхшәр вакыйгалары башланды. Минем кебек киенгән гаскәриләр җиргә каплана-каплана чукынырга тотындылар. Аларга аптырап-аптырап карап торуымны күргән Игорь кенәз миңа кул ишарәсе ясады, ятарга кушты, ул да түгел, сүзгә күчеп:

— И эт токымы! — дип сүгенде.— Ят, диләр сиңа, чукын!..

Мин аңа авыз еруым белән җавап бирдем. Шулай да тезләндем. Дуңгыз балалары кебек мәш килеп маташкан, әле аякларына баскан, әле кабат сәхнә тузанына баш орган гаскәриләр төркеменә сугышка күтәрелергә боерылды. Баскычтан төз баскан хәлдә бер-бер артлы төшеп, сәхнә артына чыктык та, икенче яктан йөгереп диярлек килеп, шул ук басмага икенче тапкыр менеп, кабат төшеп, сан күплеген күрсәтергә тотындык. Бер кулыбызда — кылыч, икенчесендә калкан иде. Әмма, төшеп килгән чагымда, баскычтагы хәерсез бер кадак башына минем җилкәдән асылынган плащ-япмам эләгеп калды. Кузгала алмас булдым. Ә көй дәвам итте. Мин тагын алга талпындым. Кадакка эләккән япмам мине бугазлап артка тартты. Чайкалып киттем. Тагын алга талпындым. Ә кадак ныклы иде. Дирижер бөтен сәхнәне бар тулылыгы белән күз уңында тота икән. Оркестрдан тагын шул ук, инде бер тапкыр уйналып үтелгән ноталарны кабатлатты. Сәхнәдәге тамаша минем чарасызлык аркасында тукталырга тора иде. Кузгалып китәргә тагын талпындым. Мизгелләр мәңгелеккә әверелгән кебек тоелды. Кадак башына ныклап ябышкан япмам муендагы элмәген тагын да катырак буды. Сәхнә тәмам хәрәкәтсез калды, көйчеләр туктады. Сул кулымны иркен хәрәкәт белән артка таба алдым, япмамны учладым һәм тартып җибәрдем. Ул шытырдап ертылды. Шунда гына дирижер сихерле таягын селтәп җибәрде, көй дәвам итте, халык үрә торып кул чабарга тотынды.

Ни булганын яшермим, җырчы ханымнар мине каты итеп кочты, кызлар — үпте, ирләр — тәбрикләде. Шулай итеп, беренче чыгышымда ук, гади мизгел эчендә дан алдым. Сәләтемне күреп, андый уеннарда әле бер, әле икенче рольләрне ышанып тапшырдылар һәм миннән һаман да гайре табигый, көтелмәгән бер хәрәкәт, мәгънәле бер чыгыш буласын көттеләр. Һәр уен ахырында, анда катнашканым өчен, бер сум акча ала идем. Ул вакытлар өчен зур сумма иде. Бер төшке ашны кырык бер тиенгә ашыйсың, ә бу исә, ашханәгә ике тапкыр кереп, корсакны тутырып чыгарлык.

Әмма сәхнәгә кереп китүемне, артистлык һөнәренә якынаюымны күңелем кабул итмәде. Әдәбиятны ташларга тиеш түгел идем. Никадәр чакырдылар, үгетләделәр. Ничек кенә уңышлы уйнамадым. Барыбер сәхнәне әдәбият өчен корбан итәргә мәҗбүр булдым. Соңыннан да килеп, театрда эшләргә күп мәртәбәләр чакырыплар карадылар, бөтен кыяфәтең-төсең — артистларныкы, дип үтенсәләр дә, үз сүземдә калдым. Кызганыч, әдәбиятта шәхси мәйданымны яулап алу гына бик авыр булды. Күп тапкырлар чигенергә, көенергә, хәтта җимерелеп төшәргә дә туры килде. Ә хыялыма, токкан максатыма җитәргә ерак, бик ерак сыман.

*Октябрь, 1998*

## Ат урлауның ние бар...

1912 елның икенче сентябрендә тиз йөрешле «Меркурий» пароходы, ягъни пар көче белән хәрәкәт итүче ак көймә Түбән Новгород шәһәреннән Казан каласына юл алды. Сәфәрләренең чалт аяз көннәр белән озатылып, шулай ук матур кичәләрдә Идел елгасы буйлап дәвам итәчәге билгеле булу һәммә юлчыларның күңеленә зур бер сөенеч өсти иде. Татар байлары, Мәкәрҗә ярминкәсендә олы табыш алып, театр һәм концерт тамашаларын карап, тәтәйләр белән туйганчы шаярышып, сыра шифасыннан йөзләрен кызартып, «кадимче»ләрнең сәнәк очыдай төртелергә әзер булган күзләреннән читтә тынычланып һәм күңелләрен шактый гына хушландырганлыклары сәбәпле, монда да үзләрен иркен тоттылар. «Меркурий»ның һәр затлы бүлмәсе, рестораны һәм түгәрәк башлы олы көзгеләр куелган ханәләре, татар сүзе, татар мәкаме, татар исе һәм татар яме белән тулып, ризыклардан да токмач, бавырсак, каһвә, чәй тәмнәре генә таралып, «Аллаһы әкбәр!», «Сөбханаллаһ!» сүзләре еш кабатланылу белән иманлы Нух көймәсеннән бер дә ким түгел төсле иде. Казан арты дип йөртелгән Арча—Балтач якларында гына түгел, ерак Ырынбур һәм Бохарага кадәр даны таралып, үзеннән алда барып җиткән «мин кемлек» хисабы белән яшәүче, мөэминлектә хәтта хәзрәте Гомәр мисаллы, кодрәттә, һичшиксез, хәзрәте Гали Арыслан мәртәбәсен тоткан, байлыкта Сөләйман пәйгамбәр кебегрәк булган Гатауллин Шаһимәрдан Гатаулла улы да, бәрәкаллаһ, шушы рәхмәтле көймәдә иде. Элекләрне Гатауллиннар ни сәбәпледер Медведев фамилиясен йөртеп, атасының бабасы дәүләт казнасына зур акчалар түләп, ахырда бу кушаматтан 1865 елда ук котылганнардан исәпләнелә. Хәер, туарга әзерләнгән һәм киләчәктә тагын да туачак балаларын көферлектән арындыру бәхетенә ирешкәнлеге хакында сөйләүчеләрнең үзләре түгел, сүзләре дә онытылган чаклар була икән ул.

Шаһимәрдан, җәдид һәм кадим кебек сугышларда һәм тарткалашуларда кайнашып маташмаган булса да, заманында Иж-Бубый һәм Казан мәдрәсәләрендә сигез ел чамасы гыйлем эстәп, заты хакында:

— Бу бала зур мулла мәртәбәсен табар! — дигән мактау сүзләрен күп ишетсә дә, хәтта язу тәртибен бик камил үзләштереп, шәкертләр өчен ничәмә китаплар күчереп, галим шөһрәтен алса да, Ходайның әмере, сәүдә эшенә күңеле ихластан ятып, укуын ташлаган, биш елда йорт-җирен ныгытып өлгергән, егерме биш яшендә үк Казанда ике кибетне кулга төшерергә җитешкән булдыклы кешеләрнең берсе иде. Аллаһы Тәгалә аның һәр эшенә юл ачып, бәхетен даим сәгать арттыра торды. Ул үзе дә рәхмәтле затлардан булып, зәкят һәм һәдияләрен канәгатьсез муллаларга да кызганмады. Хәтта җитмешләп хәерчене елга бер җыйдырып ашата торды. Бу кадәр яхшылыклары көннәрнең берендә үзенә олы савап сыйфатында кайтарылачагын күзаллый һәм шул өметтә иде.

«Меркурий» көймәсендәге Казан байлары бүлмәләренә урнашып алган, беразга гына һава суларга дип чыккан булып, уңнарын һәм сулларын тамаша кылып йөренгән, матур тәтәйләргә күзләрен кыскалап алырга өлгергән икәнлеге йөзләренә май кояшыдай ягылганлыктан, төс-кыяфәтләреннән вә көязлекләреннән үз алларына канәгатьлекләрен, кыланышларына карап кына да барысын-барысын, хис-тойгыларын тәмам аңларга мөмкин иде. Килешле кара казакидан, ак якага бәйләнгән зәңгәрсу җирлеккә ак борчаклы киң һәм тасланган тасма-бантлы яшь сәүдәгәр палубада әле яңа гына бер туташ белән танышты. Икесенең дә ялгыз икәнлекләре сизелде. Туташның кулындагы кечкенә зонтын җил чак кына алмады. Егетнең өлгерлеге ярдәм итте. Хәйләкәр дә икән әле, җитмәсә, туташның зонтыннан гына түгел, беләгеннән дә тотарга булдырды. Көлештеләр. Халыкның күз кырые боларга бәя бирергә маташканда, ургылып алга баручы «Меркурий»дан янда калган балыкчы көймәсендәге ике малай инде аларга кызыгып карап калдылар. Бары шул гына. Бүтән алай ук искитәрлек хәл булмады. Затлы кыяфәтләрен саклаган байлар, һава алыштыргач, бер-бер артлы югала тордылар. Яшьләрне һаман да күзәткән Гатауллин, үзенең кыяфәттөсе яхшы сакланганга куанып, хәйләкәр мәче кебек елмая иде, кара йомшак мыегын да бармак яны белән генә сыпырып куйды. Яр читендә калган урыс авылының чиркәү башындагы ялтыравык алтын гөмбәзеннән чагылган кояш «куяны» аның очкын күзләрендә уйнап алды. Гатауллин тамак кырды. Яныннан узып баручы ак күлмәкле, салам эшләпәле марҗа хатыны аңа сәлам бирде. Танышлар түгел иделәр кебек. Шушы көндә генә алар икенче тапкыр очрашалар һәм сәламләшәләр түгелме соң? Күлмәге чибәр, күлмәге! Әллә бу теге, әртис хатын Сәхипҗамалның үземе? Алай дисәң, чәче сары. Юк-юк, марҗа булыр, марҗа!

Байлар ресторанга җыела башлаган иделәр. Гатауллин да шунда юнәлде. Һәр тарафка йөз балкытып торган зур-зур тәрәзәле ресторан залы гүяки аны киң күңел белән каршы алды. Гатауллинның күзе нигәдер түргә, кадими киемле, елгыр күзле, тимер бәдәнле, җирән сакаллы кешегә төште. Теге дә карап куйды. Гатауллинның колагы чыңлап, йөрәге юктан гына жу итеп алды. Затлырак урын булсын дип, үзе дә түргәрәк атлады, өч кешелек өстәл янына килде. Шактый гына санга җыелырлык халык рәхәтләндереп татарча сүз куерта, арада хәтта шешәле сыра алдыртучылары да бар иде. Мосафирларның шушы кадәр дә үзләрен иркен тотулары Гатауллинның күңеленә хуш килеп, баягы адәмнән шомлануы озак та үтми юкка чыкты. Ул арада килеп җиткән ак пинҗәкле, кара чалбарлы официант, баскан урынында бераз таптанып алганнан соң, түбәнчелекле кыяфәттә урыс акценты белән татарча сорады:

— Ни боерудасыз?

Әмма Гатауллин аның кыенлык белән әйтелгән сүзләрен аңлый алмады. Официант җитез генә кабатлап өлгерде. Гатауллин шунда гына урыс авызыннан чыккан татар сүзенең матурлыгына игътибар итте һәм:

— «Йолдыз» гәзите юкмы? — дип сорады.

— Бар, әфәндем! — диде официант.

Гатауллинның бу җавапка күңеле хушланып, тагын да чәй китерергә кушты. Сырадан ук башларга кодрәте җитмәде.

— Аннан тагын да әмер итәрмен!

«Йолдыз» гәзите үткән атнаныкы иде. Казан һәм Рәсәй хәлләре белән бергә дөнья йөзендә булып яткан вакыйгаларга да бәяләр бирелеп, базар хаклары һәм башка шуныңише вак-төякләргә игътибар юнәлтелгән. Танышып чыккан мәкаләләреннән Гатауллин, канәгать калып, «Болгар» кунакханәсендә люкс нумерларның күпме торганлыгын исенә сеңдерде. Бер кич кунып чыгу өч сумга бәяләнә икән. Ярый-ярый, элеккеләре кандалалары белән бергә бишкә кадәр иде, хәерсезләрнең! Белдерүләреннән аңлашылганча, яхшы тәрбия күрсәтәчәкләр, милләтне сөендерәчәкләр, имеш.

Гатауллинның хәтерендә биш-алты ел гына элгәре булып узган вакыйгалары яңарып, эченә куаныч белән бергә дәрт һәм мин-минлек вәсвәсәсе тулды. Атасыннан калган мирас янына үзенең туктатусыз тоткан сәүдәсеннән кергән табышның кадерен дә белә, теләгәнендә исраф та кыла торган иде. Казанның татарлар телендә Искәндәр сарае дип йөртелгән Александр пассажына җигүле ат белән кереп, тәтәйләр янында атналар буена калып, ахырда ак ыштаннан гына чыгып качкан вакытлары да аз булмады. Ә килеп керүләре, һәй... Дөнья малы белән шаярды да инде. Татарга биш хатын да фарыз, дигән сүзләрне аз әйтмәде. Арчадан чыгуга, алдан иярдә атчы Галәвине җибәреп, Казан пәлисәсенә әйттерә иде дә, бар ашкыну белән кала урамнарына томырылып, алдан юырттыручының койрыгына бастырып чаптырта иде. Хәтта Искәндәр сараеның да капкаларын ачып:

— Гатауллин үзе килә! — дигән шау белән каршы ала иделәр.

Бар иде заманалар, бар иде атларны баштанаяк киендереп, яхшы чана белән тарантасларны ел эчендә туздырып ташлаган чаклары!

Бервакыт Тукайның үзе белән дә бергә булды. Мировой егет икән! Ул шигырь укулары, ул сүз сөйләүләре — күзгә күк белән җир тоташкандай күренә башлый. Андыйлар аз шул, аз!..

Гатауллинга кайнар пәрәмәч, бал, коймак һәм чәй китерделәр. «Йолдыз» гәзитен кире биреп җибәрде. Ул да түгел, палубада сөйләшеп калган теге егет белән туташ кереп, аның өстәле яныннан урын сорадылар.

— Утырыгыз, утыр! — диде Гатауллин, аларга игътибар итмәвен сиздерергә теләп.

— Рәхмәт! — диделәр.

Килеп җиткән официанттан болар чәй үтенделәр. Гатауллинның корсагында «тегермән ташы» кузгалып, бирәне ачылды, аш әзерләүләрен үтенде, кош итеннән затлырак төре юкмы икәнлеген сорады. Яратканы, әлбәттә, каз иде. Әмма анысы ук әлегә булмады, шулай да кичкелеккә өлгертергә ышандырдылар. Ни барына ризалык итеп тукланганыннан соң, Мисыр күгәрченнәредәй гөрләшеп өстәл башында утырган теге яшьләрнең үзләрен генә калдырып, аштан соң зиһенгә файдасы тияр, дигән уй белән һавага чыкты. Монда да озакка каласы килмәде.

Бүлмәсенә кайтып, өстәлендә калдырылган Шиһабетдин Мәрҗанинең «Мостафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар», ягъни «Казан һәм Болгар хәлләреннән кыскача хәбәрләр» китабының беренче томыннан 213 нче сәхифәсен ачты. Дөресен әйтергә кирәк, ул аны уку өчен түгел, бәлки кыяфәт мәртәбәсенә генә үзе белән йөртә, кирәккәндә генә ачып, танышкандай итә, кайвакыт анда язылганнар белән мавыгып та киткәли, һич югы, төче генә берәр галим кисәге була алмавына үкенгәли дә иде. Һәрхәлдә, шушы китапта язылган вакыйгалар һәм хәбәрләр аның күңеленә хуш килә, татарның электән нинди дәрәҗәдә бөек икәнлегенә куаныч һәм мактаныч хисләре уяна, тарих фәлсәфәсе аның әллә кемлеге өчен хезмәт итә башлый. Гатауллин алдында урыс, алман, инглиз, француз кебек зур һәм бөек милләтләр кечерәеп, хәтта мескенәеп калалар. Хәтта кайвакыт ул аларны кызганырга, җитмәсә: «И мескеннәр»,— дип, шул халыклар хакында юктан гына борчылырга тотына. Ахырда, үз милләте тарихы өчен булган горурлыгы өстен чыгып, урыс һәм алманнарның хәзерге хәлләренә бәя бирергә дә онытып, чиксез бер шатлык белән сөенә башлый.

Кичкә ресторанга дип күтәрелгәнендә, халык кәефенә хәйран калырлык иде. Теге туташ белән егетне, электән танышлары кебек исенә алып, күреп калырга теләгәндәй, халык арасыннан эзләде. Әмма алар монда юк иде. Дуслары һәм көндәшләре булган Казан сәүдәгәрләре Гатауллин белән эре генә исәнләште-

ләр. Тик сыра төтененнән башы әйләнгән тиречe Янбаш Гыйльметдин белән Кече Камалетдин генә, аның җилкәсенә кулларын салып, яннарына әйдәкләп утырттылар.

— Шаһимәрдан... Шаһимәрдан... Утыр әле, сөйлә әле... Ак атыңны әйтәм...— дип борчый ук башладылар.

Әмма сүз ул юртагы хакында түгел, бәлки Мәкәрҗә хәлләрен искә төшерүгә күчеп, татар театрын сүгүгә, татар мәдәниятен җиргә салып таптауга, хәтта кечкенә күренгән вакыйгаларны олы сәясәт итеп сөйләшү мәсьәләләренә кереп китте. Һични аңламаган, надан һәм ахмак кешеләрнең зурдан кубып гәп орыларына охшап калды. Бу тиречеләрнең бөтен хәсрәте кадими ыштан һәм җиләнгә күңел баглау гына булса да, ахирел-әмер, шушы соңгы елларда җәдитләнеп китүләренә хәйран итәрлек иде. Хәтта башларына Аурупа эшләпәсен кию, ак яка өстеннән төсле бант тагу, кәчтүмнән йөрүне дә дөрескә чыгарганнар, җитмәсә, үзләре дә шулай киенеп алганнар. Сөйләшүләре дә хикмәтле булып киткән. Шаһимәрдан, имеш, марҗаның кызыл битлесе яхшымы, әллә бераз гына алсуы әйбәтме? Нәрсә диләр, кара инде боларны! Кичәге Янбаш Гыйльметдин белән Кече Камалетдинне бүгенге җәдитчә кыланмыш Кәчтүм Гыйльметдин белән Эшләпә Камалетдин янына утыртсаң, билләһи, талашып, якалашып, кыйнашып, канга батышып бетәчәкләр. Аһ бу шомлы империалистларны!

Шаһимәрдан сүз сандугачын акыл читлегендә каплап кына тотарга булды, дөресен әйтеп тавыш чыгарганчы, күп эшләргә күзеңне йому хәерлерәк иде. Шуңа да:

— Марҗасына карап инде, Гыйльметдин, марҗасына карап, Камалетдин,— дип, мыек астыннан гына көлемсерәп, шаярткандай җавап бирде.— Мин үзем, ни, бик алай белеп бетермим, әмма дә ләкин, әйе, түгәрәгрәге, йомшаграгы әйбәтрәк була икәнен афәрин егетләрдән ишеткәләгәнем бар...

Тиречe империалистлар рәхәт табып көлешкән арада, Шаһимәрдан тагын да өстәп куясы итте:

— Көя төшмәгән булса!

Шунда гына тегеләр аның шаяртуын һәм хәтта, юри җайга торып, мыскылларга маташуын төшенеп алдылар. Хахылдаган авызларын:

— И хәсис, хәерче!..— дигән көфер почмагы әһеленә хас сүгенү белән йомарга ашыктылар.

Шаһимәрдан, эшнең ахыры зурга китәчәген шәйләп, ул арада икенче өстәлгә күченергә өлгерде. Әмма тиречеләрнең аны болай гына калдырмаячакларын ул әлегә белми иде.

Ризыкның затлысын, милли байларның карынына хуш килерлеген китерделәр. Кайда-кайда, әмма «Меркурий» көймәсендәге ашчы-пешекчеләр татарларның азык-төлекне мулдан куллануларын, сырага күңел салуларын, камырлы һәм итлене май кызганмый пешерергә кирәклеген яхшы беләиделәр. Шаһимәрдан кыздырылган каз ите, сумса, шулпа, пәрәмәч, коймак, каймак һәм бал янына, авыз тәме өчен дигән булып кына, бер шешә сыра соратты. Китереп өлгерүләренә, үз нәфесенең иярен атланып, тагын да балык ите кыздырырга кушты. Затын иркен тотуыннан сәүдәсенең дә яхшы барганлыгын аңларга өлгергән официант:

— Баш өсте, әфәндем! — дип елмайды.— Тагын ни дә кирәкмиме?

Мондый сорауларны Шаһимәрданның күәсе күтәрми иде. Карыны әлегә һаман ач икәнлеген тойган хәлендә, юктан гына җене килеп:

— Балыкның ике ягы да яхшылап кыздырылган, кылчыгы төшерелгән булсын! — дип әмер бирде.

Официант катлы-катлы баш өсте белән китеп барды. Хәер, монысына Баш өсте кушаматы бик тәятышып тора иде. Мөгаен, Казан мәдрәсәләрен күп күреп тә гыйлем биштәрен тутырырга өлгерми калган Сиргач мишәре булырга кирәк! Кибәнне югары куярга яратадыр?

— Рәхимегез, әфәндем!

Сумса белән шулпаны бетереп, казга күчкән Шаһимәрдан күтәрелеп карады. Ә, сыра китергән икән. Бик вакытлы.

Күрше өстәлдә шаулашып алдылар:

— Сез, әфәндем, җәдит, дисез, ягъни дә мәсәлән, гәзит, дисез, мәҗәлләс, имеш...

— Шулай дим шул!..

Өстәлләре ризыктан бушау сәбәпле, бераздан әфәнделәрнең күбесе, милләтчә булсынга кикеренеп, җиңел аяктан кузгала тордылар. Гыйльметдин белән Камалетдин дә шаулашып чыгып киттеләр. Аларны бүтәннәр алыштырды. Теге егет белән туташ күренмәде. Электән сыра эчүдә һәркемне хәйран калдырган әһеле көфер почмагы һәм дә яшереп кенә булса да яхшырак эчемлек белән сыйлануны читкә куймаган җәдитләр җыела башладылар. Кайсысына сыраны бүз шешә белән китерсәләр, икенчеләренә чәйнектә өстәлгә куйдылар. Гадәт һәм йолага хилафлык итүләр юк иде. Шаһимәрдан бу вакытта сыра парыннан шактый акайган, борчылудан бигрәк, матур гына кәефләнергә өлгергән иде. Ресторан түрендәге караңгыланып торган тарафка ихтыярсыздан күзе төшеп, инде әллә кайчан күргән-күрешкән, бурсык йөзле, калын, әмма кечкенә итеп кистерелгән сакаллы, туп кебек шома итеп кырдырган башының сул тарафына авыш-

тырып эленгән сай түбәтәйле кешенең анда күзләрен очландырып утыруын яхшы шәйләде. Үзара бик таныш кебек булсалар да, бер-берсен белүләре бары тик көрпә тел — саңгырау колактан һәм анда-санда, бу адәм фәлән бәндә түгелме, дип белешкәләүләрдән генә иде. Һәрхәлдә, Гатауллин да, ул кеше дә бер-берсен таныдылар булырга кирәк.

Күрше өстәл әһелесе үз эше белән мәш килде, чәйнектән чынаякларына кызыл шәраб бушатылды. Араларыннан берсе, Шаһимәрданның карап алуын күреп, аны карашы белән сөзеп узды да иптәшләренә нидер әйтте. Түгәрәк мишәр агае, карбыз шикелле тәгәрәп киткән кебек селкенеп, өстәлдәше сүзләренә колак куеп ияргәне хәлендә, ресторандагы кәефле кавем арасыннан төртеп аталган кешене каранып эзләде. Шаһимәрдан аның арка тарафында иде. Шунлыктан аны таба алмады.

— Кемне әйтәсез, тәкъсир?..

— Кая карыйсың, бире бак!..

Аның соравына күрә Шаһимәрдан әфәндегә теге сөйләүче адәм бармак белән төртеп күрсәтте. Мишәр барыбер күрмәде. Аның монда утыруын һәм барлыгын шәйләп тә тормастан, карашы караңгы өстәл ягына узды. Йомры мишәр, кинәт артка табарак тәгәрәп, тавышын яшермичә әйтеп тә куйды:

— Ба!.. Шәкүр карак! Нишләп йөри монда?

Аның сүзләрен ишетергә өлгергән һәр әһеле татар вә башкорт вә казакъ-кыргыз каерылып диярлек шул якка карадылар. Ат карагының гына керфеге дә селкенмәде. Бер иптәше-яраны беләнме нидер сөйләшкәләп утыруда булды. Шунлыктан һәркем, аңа текәлүдән бигрәк, юктан кызарып алган Шаһимәрдан әфәндене тикшеренделәр. Аңа җайсыз, уңайсыз, хәтта ачуын кайтарырлык халәт иңде. Эчкән сырасының парын күзләр кайнарлыгы гүя һавага очырды. Чыгып китмәкче иде, калын гәүдәле, баһадир чырайлы, буйга өч аршыннан артык булырлык берәү аның каршысына килеп басты. Минзәлә сәүдәгәрләренә хас рәвештә зәңгәр чалбар, кызыл чапан, ак чалма, йомшак читек кигән бу адәмнең тавышы да колакларны кисәрлек иде:

— Син, Шәкүр агай, бер дә галәмәт бе€дең кеше икән!

Шаһимәрдан һичбер сүз белән дә җавап бирә алмады. Борчылудан селкенгәләп куйды. Ат белән бәйләнеше зур булса да, ат караклыгына һичбер катнашы юк иде. Тутый кош сурәтеннән бер дә ким булмаган бу адәмне, ияк астына биреп, чөйдереп кенә җибәрәсе килсә дә, берни эшли алмады. Ярый әле шул арада Шәкүр карак алар янына үзе килеп басты. Буйга әллә кем түгел икән! Һәммә шөһрәтнең үзеннән читтә калмавын теләүдәнме, әллә Шаһимәрданны кызгануданмы моны эшләде? Һәрхәлдә, вакыйга шушы рәвешле булды. Минзәлә сәүдәгәрләренең күзләре уйнап алды. Болай да ерык авызы тагын да киңәеп, башының яртысы артка ишелде:

— Ха-ха-ха!..

Аның көлүе саңгырауны да колаклы итәргә мөмкин иде. Шаһимәрданнан гафу үтенеп тормастан, ат карагына борылды һәм баягы сүзләрен кабатлады:

— Һи... Шәкүр агай, синмени инде ул? Бер дә галәмәт бе€дең кеше икәнсең!

— Бе€дең, бе€дең...— Шәкүр каракның Минзәлә сөйләшенчә сүзләрне оста авыштыруы иләмсез сәүдәгәрнең кәефен тагын да күтәрде булса кирәк, сабый балаларча бар күңелен тышка чыгарып тагын да көлде. Инде боларның ни-нәрсә сөйләшүләре колаклы татарны да кызыксындырмый башлады. Көймә әһеле үз табыннарына борылган иделәр. Өстәлчеләр йөгереп-йөгереп ризык ташый тордылар.

— Шаһимәрдан, монда буш бугай? — Шәкүр каракның бу сүзләреннән бигрәк, исемен төгәл белеп эндәшүеннән Гатауллин аптырап, хәтта кулындагы сыралы савытын төшереп җибәрә язды:

— Ни?..

Шәкүр үзен хуҗаларча тотты. Мәгърур йөзен түбәнәйтми генә сүзләрен капчыкка тыгызлап тутыргандай кабатлады:

— Монда буш бугай?.. Монда буш...

— Әйе, тәкъсир...

Ул арада Шәкүр карак урын алырга, хәтта янәшәсеннән Минзәлә баена тәкъдим итәргә, яранына да монда күченергә ишарә итәргә өлгерде. Шаһимәрдан исә:

— Сез мине, Шәкүр, каян беләсез? — дип, аптыраулы күз карашына гаҗәпләнү һәм соклану катыштырып, бу мәгънәсез соравын бирде.

Шәкүр игътибарлы кеше иде. Ул арада өстәлендәгеләрен монда күчерергә өлгергән яранына нидер әйтте дә, туктап тор әле дигәндәй, Минзәлә баеның беләгенә бүрәнә бармакларын куеп, тыныч кына сөйләп тә бирде:

— Кемнәрне-кемнәрне, әмма ат яратучыларның һәммәсен дә исемләп беләм, хәтта Әмерекәнең Томнсонын да...

Бу Томнсон әфәнденең кемлеге Шаһимәрдан өчен дә, Минзәлә баена да караңгы иде. Шәкүр моны яхшы белә, шунлыктан үзенең мәртәбәсен тагын да арттырып, бер башка югары булырга исәбе. Һавалык.

Яшермәде, Әмерекә баеның ничек кара аргамагын яратуын, аңа хәтта вафат әнисенең исемен бирүен, башкаларны һәм бүтән барны-юкны сөйләп алды. Бу вакытта Минзәлә бае хәйранга калып, хәтта авызын ябарга да онытып утыра иде. Сүзенең ахырында Шәкүр аннан:

— Исемең ничек әле? — дип сорап куйды.

— Мөхәммәтҗан! — диде тегесе.

— Юктыр, алай гына булмас. Безнең татарда исемне катлы-катлы йөртергә яраталар. Иң кимендә Хаҗимөхәммәтхафизҗандыр әле! — Шәкүрнең бу сүзләре дә Минзәлә баен хәйран иттеләр.

Ул:

— Әйе, тәкъсир, нәкъ шулай,— дип, Шаһимәрданга да оялгандай карап алды.— Әмирелхаҗимөхәммәтханхафизҗан булам, атам белән мәрхүм муллабыз кушкан исем. Болай бала чактан Мөхәммәтҗан атап йөртәләр, сүз җае өчен Миҗан, диләр. Миҗан бай, әйе!

Сүзен әйедән башлап әйе белән бетергән Мөхәммәтҗан әфәнде көтелмәгәнчә оялып куйды. Аның бу кадәр иләмсез һәм озын исемен мулла бабай да гомерендә бер генә, колагына кычкырганда гына әйткәндер, метрикәсенә алай ук озын итеп язып тормагандыр, шәт. Әмирелхаҗимөхәммәтханхафизҗан. Үзе үк тулы бер җөмлә. Ягъни, гарәптән, фарсыны да исәпкә алып, татарга тәрҗемә иткәндә болай булыр: Хаҗ кылучыларның җитәкчесе, Аллаһы Тәгаләнең сөеклесе, хан гыйлемле җан... Моның белән генә бетсә?

Шәкүр һаман да тыныч иде. Бүре күзләреннән чагылып куйган очкыннарны шәйләүдән генә аның көлемсерәгәнен сизенергә мөмкин булды. Сүз арасында яраны юкка чыкты. Монысы да берәр хәйлә түгел идеме икән?

Мөхәммәтҗан әфәнде табак битендәге шактый олы бәрәңге борынын, урыныннан кузгатырга теләгәндәй, боргалап куйды. Аннан Шәкүргә карады. Бу вакытта аңа бала сыманрак кыяфәт кереп, нәрсәнедер тәфсилләп сорарга җыенганы аңлашыла иде. Һәм шулай булып чыкты да. Шаһимәрдан әфәнде Гатауллович каз ботына ябышканда, Мөхәммәтҗан бай сорау арты сорау яудырырга тотынды:

— Шәкүр агай, Шәкүр агай, дим? Минзәлә яниралының ак айгырын ничек урладың? Сөйлә әле? Эзеңә дә төшә алмадылармы? Әстерханга илтеп саттым, диген, ә?..

Шәкүр эндәшмәде. Бүре күзләре канәгатьлек белән йомылып алдылар. Аскы ирене кырыкмыш мыегына кадәр күтәрелеп, маңгае коры көнне яргаланган кара туфрак кебек сырга сыр килде. Җавап көтеп томаланган Мөхәммәтҗан, сабырлыгын югалтып:

— Сөйлә инде, Шәкүр агай? Билләһи, беркемгә дә әйтмәм! — дип үтенүендә һәм ант чүмерүендә булды.

Бу вакытта куркынган кыяфәттә Шаһимәрдан шомлы Шәкүргә карап утыра иде. Кулыннан каз боты төшеп китте, тәлинкә, чәнечке, кашыклар кузгалышып-шалтырашып алдылар.

— Бәрәч, син урладыңмы аны да?

Шаһимәрдан әфәнденең белмәгән кеше кебек болай әйтүеннән Шәкүр үртәлеп куйды һәм, яшереп тормастан:

— Мин идем ул, канә-ә...— дип сузды.

— Әйттем бит!..— Мөхәммәтҗан үз борынын әвәләде. Ул сөенә иде.

Шаһимәрдан әфәнденең бу арада йөзе туксан тугызынчы тапкырын кызарып чыкты. Гомере буе ат яратып, хәтта кочаклап яткан хатыннарыннан да шул дүрт аяклы хайваннарны өстен күрде ул. Күп вакытта тегеләренә җикеренсә дә, боларына чыбыркы селтәнергә дә беркемгә ирек куймавы һичбер яшерүсез һәр кешегә яхшы мәгълүм иде. Әгәр дә дөньясы уң белән сулын бутаса да, иң ахырдан базарга чыгарганы шушы атлар булачак аның. Моңа иманы камил. Шиһабетдин Мәрҗанидән гыйлем тәслим кылып, шушы олуг мөдәрристән фән каймагын чумырып алып калалмаса да, ахунлык мәртәбәсенә ихластан кызыгып, алтын сәгать йөртүне һәм атларга мәхәббәт хисен аңардан үзенә йоктырды тагын. Дәрес барышында Шиһабетдиннең, «Ихья» гыйлеменә кушып, баш ял итсенгә диптер инде, абзарындагы соры айгыры хакында, аның ничек Ашыт базарында арт аякларында биюе белән халыкны хәйран калдыруы турында тәфсилле-хисле озын һәм озак хикәяләүләре вакытында һәр шәкертнең ач күзләрендә очкыннар уйнарга тотына иде. Шаһимәрданга шуннан бирле ат чире йогып, тәмам кибеп, урын өстенә ятып, бу зәхмәттән үлем хәленә житкәндә, атасы Гатаулла, авылдан килеп, җиде кат толыпка төреп, зур кәрван сандыгына салып, үзе белән алып кайтты. Им-томчыларның кыңгыраулысы да, думбралысы да, кабаллы-тәлинкәлесе дә калмады. Һәммәсе аның җилеген суырды, атасының малына кинәнде, әмма файдалары булмады. Гатаулла абзый кул селтәде:

— Бу баладан кеше чыкмас, тизрәк үлсен дә илтеп күмәрбез! — дип, йорттагыларның болай да качкан котын алды.

— Әстәгъфируллаһ! — диделәр бар да, авызларын учлап.

Әмма Аллаһының рәхмәтеннән узмыш юк икән ул! Малай көтелмәгән җирдән сихәтен тапты. Төнлә белән саташып, хәлсез гәүдәсен сөйрәп, абзар-кура ягына чыкты. Атлар, пошкырып, солы кемердәтә иделәр. Шаһимәрданның сулышы ачылып китте. Ат исе аның баш авыртуын да, күңел укшуын да бетерде. Әмма тәнен калтырану каплады. Хәл алыйм дип утырган урыны әле кичтән генә өеп калдырылган җылы тирес булып чыкты. Ул, шунда чумып, тәмам онытылган хәлендә йокыга китте. Иртәгесен аны тирес эченнән табып алдылар. «Бала харап булган!»— дип елый-елый, урын өстенә кертеп салдылар. Әмма Шаһимәрдан шул көннең ахшам вакытында аягына басты, үз кодрәте белән тәһарәтен алды, намазга ниятләде.

— Бала китәргә җыенды,— диделәр өлкәннәр, сүзне колактан колакка күчергәләп.

Гатаулла абзый, аңардан өметен күптән үк өзгәнлектән:

— Хәерлегә булсын! — дип сузды.— Ходаның бирмешеннән узмыш юк!

Ни хикмәт, төне буе Шаһимәрдан убыр кебек ашап чыкты, ярты казан ашны бушатты. Моннан соң да аягына камил басмаса, җен токымы булачак иде. Аллаһының рәхмәтеннән уза алмады.

Ул елны яз иртә килде. Март ахырында ук яшел үлән чыгып, апрель урталарына көтү куарлык булды.

> Нәйсән җитсә — дөнья күрке,
> Куба суның ташкыны...
> Чибәр кызлар егет сайлый,
> Һич уйламый башкан,—

дип җырлап узган егетләргә Шаһимәрдан да кушылырлык иде. Әмма бусагадан атлап чыгарга рөхсәт булмады. Кыш буена им-том итеп, тәрбияләп һәм асрап яткан ата-анасы һәм инәкәйләренә ул да үпкәләмәде. Абзар-кура арасында йөреп, әтисе белән бер-ике тапкыр сәүдә эшенә барып кайтты. Шаһимәрданның учы майлы булды. Ни сатылмый яткан товар да базарда үз хуҗасын тапты.

— Баланы укытудан файда юк, сан саный белсә, безгә шул инде! — дип, әтисе Гатаулла аңа махсус кәрван җиһазлаттырды. Үзенең өмете, улының эше төгәл барып чыгасына иманын камил тотмаса да, күрше авылдагы карендәше Сәйфулланы күз-колак өчен килештереп куйса да, Шаһимәрданы аны аягыннан екты. Сәүдәнең беренче көнендә үк, илчесен җибәреп, товарының бетүен, керемнең бергә өч булуын, әгәр рөхсәт икән, маклер Җамали Хафизының үтмәс малын аз бәядән алырга җыенуын белдереп хәбәр салды. Гатаулла, болар хакында ишеткәч, ашыктырып ат җиктерде:

— Балага калган көн — таң атмаган төн! — дип, Арча базарына буран кубарып килеп керде.

Аны бугазлап становой туктатты. Тәртипне бозу, сүгенү, дуамаллану, бушбугазлану кебек әллә ниткән хулиганлыклар тагып, шулай Гатаулладан адәм мәсхәрәсе ясап, таңга кадәр рәшәткә артында йокысыз тотты. Ахырда «Өч көнсез Арчага керергә ярамый!» дигән тыюлык кәгазен тоттырып, җиде сум егерме биш тиенлек штраф салып, авылына кире озатты. Юлда танып калган кешеләрдән оят иде. Күрше авылгача ияреп килгән кылычлы атлы казак Сәмигулла, аңардан тәки бер мөгәричлек акча кысып, төн авызына кереп югалды. Тәмам тугарылып, өч хатынын бер итеп сүгеп ташларга әзер булып кайтып кергән Гатауллланы капка төбендә өчле-тугызлы мыегын сыпырып утырган улы Шаһимәрдан каршы алды. Сүз бер генә иде:

— Атай, Җәке мулласы Гарифның кызы, Бибисәрвәрҗәмиләне никахласак, Ходай Тәгалә колачын җәяр кебек! — диде.

— Бибисәрвәрҗәмиләң белән бергә үзеңне җәһәннәмгә олактырыйм! — дип, Гатаулла җикереп, инде генә сүгенмәкче иде, кинәт тартылып куйган хәерсез атының арбасыннан артка мәтәлде. Телен тешләп, авызына кан тулды. «Адәмне Ходай йөртә, шайтан — котырта!» дигән гыйбарәне башына кертеп караганы булмаса да, әллә кайдан гына шул әйтем исенә төшеп, колагы чыңлый башлады.

Усаллыкны чыгару тиеш гамәл түгел иде. Гатаулла атларын тугарырга боерды. Авырткан һәм имгәнгән җирләрен юк сыман тойды.

— Кая, ни майтардың? — дип, янында куыклы шәм күтәреп торган улына күз агы белән ишарә итте:— Сөйлә!

— Керем — биштән,— диде Шаһимәрдан, өйгә таба юнәлеп, кесәсенә яшергәнен әйтергә теләмичә.

— Алдыйсың! — Ата келәт ишеген ачты, кече утта янган лампаның яктысын арттырды. Сәүдә кенәгәләре гадәтчә шушында саклана иде. Хәзер санап чыгарачак! Шаярма Гатаулла белән, ул сарык түгел!

— Экономда, кенәгәсе белән! — Улы, үпкәләп, болдыр төбеннән генә хәбәр салды һәм, әтисенең тагын да әмерен көтеп, шунда тупсага утырды.

Гатаулла кабаланды. Кирәкле кенәгәне ачып, саннарны чут төймәсенә салып тикшерде. Келәтендә унлы лампа балкып янса да, Хафиз маклерга чыккан һәм аннан кергән акчаны таба алмады. Ахырда Шаһимәрданын чакырып:

— Илчең хаталы кеше булды! — дип, сүз башлады.

Әмма улы кырт кисте:

— Җамали Хафизының, Сәйфулланың малын сатып бирдем, мең биш йөз кырык бер тиен табыш алдым. Анысын үземдә калдырдым, кесә акчасы булыр,— диде.

Гатаулла әүвәле өнсез калды, аннан соң, сөенеч белән үзен юатып, улы белән килеште. Сәүдә эшендә Шаһимәрданның маһирлыгы аны хәйран иткән иде. Бөтен үтмәс товарын берочтан төяп җибәреп тә, улының аларны мал итүе үзе үк көтелмәгәнрәк бәхет шул. Ә ул, җитмәсә, кеше эшенә дә катнашып, үз кесәсенең дә җаен караган.

Мондый хәлне Гатаулланың гомерендә күргәне булмаганлыктан, бу сәгатьтә улы өчен сөенеп, күңеленә камиллек иңде. Аңа хәзер тыныч кына да яшәргә мөмкин. Кәсебен ышанып тапшырыр кешесе бар!

Шул көннән бирле Шаһимәрданның эшләре уңда булды. Аның хакында: «Кулына май буялган!»— дип сөйли иделәр. Әмма алай гына түгел икән шул, хәтта авыз-борыны да майга тәмам буялып беткән, үзе дә май чүлмәгенә әверелгән ул...

— Кара әле,— дип төртеп алды аңа Шәкүр карак, онытылып киткән җиреннән Гатауллинны дөньялыкка кире кайтарып,— Шаһимәрдан, мин әйтәм... Сиңа да ат җене кагылган, диләр. Ак айгырың хакында күп ишетергә туры килде. Ай-һай акыллы, имеш, төрекмән аты, диләр?

Кемнән-кемнән, әмма Шәкүр карактан үзенең бәгыре мәртәбәсенә күргән аты хакында Шаһимәрданның ишетәсе килми иде. Ул зимагурның кызыгуы бер дә юньлегә түгел, хәерсез!

Шаһимәрдан ишетмәмешкә сабышты. Китерелгән сыраны шунда ук бүлә башлаган Мөхәммәтҗанның кулына үрелде, шешәсен алып, салышырга тотынды. Шәкүр карак исә аның җанын үчекләвен дәвам итте:

— Яхшы айгыр, дип мактыйлар. Һай, бер күрәсе иде үзен, җилдәй җилдертәсе...

— Сатмыйм, сатыла торган мал түгел! — дип кырт кисәргә мәҗбүр булды Шаһимәрдан, бу хакта сөйләшүне озынга сузасы килмичә. Ачуы тәмам кузгалды, гүяки аның хатынына хезмәтчесе кул сузган да, хуҗасыннан көлмәкче булып маташа, имеш, оятсыз!

Шәкүрнең хәйләкәр күзләре ялтырап-ялтырап алдылар. Ул үзенең тыныч калуын сиздерергә теләсә дә, эче Шаһимәрданныкыннан кимрәк кайнамый иде.

— Мин ат сатып алучы түгел, мин — ат карагы! Шәкүр булам! — Аның болай ачу белән кайнарланып һәм үртәп әйтүенә күрше өстәлләрдәге сәүдәгәрләр, әңгәмәләреннән туктарга мәҗбүр булып, борылып-борылып карадылар. Һәммәсе колак салып тын калды. Шаһимәрдан исә Шәкүрнең сүзләрен җавапсыз гына уздырып җибәрергә тиеш түгел иде. Шунлыктан, алдын-артын уйламыйча:

— Миндә урлата торган ат та юк! — дип әйтеп салмасынмы.

Мөхәммәтҗан абзый тизрәк кыяклау ягын карамакчы иде, Шәкүр карак аның кулыннан эләктерде:

— Утыр, кузгалма! — дип әмер бирде.

Минзәлә татарының учы сытылды, бавыры ташка әверелде.

— Агай, дим, агай... Минем ни катнашым бар?

Суган суы сыгарга җитеп кызарып бүртенгән Мөхәммәтҗанга Шәкүрнең исе дә китмәде. Юктан гына килеп чыккан бәхәсен тизрәк ахырына җиткерергә ашыкты:

— Шул ак айгырыңны бер ай эчендә урламасам, исемем Шәкүр булмасын! Белдеңме, энем! — дип, Шаһимәрданның акылын алды.

Әмма ул бирешәсе итмәде, үчләшүендә һәм киреләнүендә булды:

— Миндә урлата торган ат юк! — диде, үрә басып.

Бу вакытта Шаһимәрданның йөзе, кызган күмер кебек, ут чәчеп тора, кечкенә күзләре елгыр энә тишегенә әверелеп калган иделәр.

— Урламасам, исемем Шәкүр булмасын!

— Урлатсам, бер мең тәңкә миннән!

Халык шаулашып алды. Шаһимәрдан өчен бу акча берни дә түгел төсле иде. Шушы бәя бәрабәренә ак айгырын абзарында саклап калырга өмет итте. Шәкүр карак аның кармагына кабарга тиеш иде. Бер мең тәңкә кемнең аяк астында аунап ята ди әле? Андый заманмы? Бер тиен өчен адәм балалары бугазга-бугаз килергә торалар. Ә монда — мең тәңкә! Кирәксә, хәзер кесәсеннән чыгарып сала ала!

— Урлатмасаң, миннән мең тәңкә! — Бу сүзләрен әйткәндә, Шәкүр карак сикереп басты, имән бармагын югары төбәп, уңнан сулга һәркемнең күзенә күрсәтеп узды.— Мең тәңкә,— диде кабатланып,— әгәр урлый алмасам, исемем...

Халык гөж итеп: «Бу кем, бу кем?»— дип, тегесе-монысы чуалышкан арада, аның юкка чыкканын күрми дә калдылар. Шаһимәрданның эченә ут оялап, акылы шашына, җаны кайный бирде. Янында Шәкүр каракны таба алмагач, иярченен күзләде, анысы да юклыктан бөтенләй дә сабырын югалтты. Ул кичекми көймәдән төшеп калырга һәм җәяүләп булса да авылына йөгерергә әзер иде. Шушы ук «Меркурий»дә истирахәт чигеп кайтучы приказчигы Нәгыймулланы, бүлмәсенә бәреп кереп, марҗасы кочагында оятлы ит-

те. Ахырда аңа барлык эшләрен калдырып, Чабаксарны узуга, бөтенләй дә сабыры төкәнү сәбәпле, Га-тауллинга ярга чыгып аяк басарга туры килде. Аңа:

— Кенәз, бәлки, Яшел Үзәнгә кадәр төшәрсез, моннан бер дә кулай түгел,— дип, урыс машинистлары әйтеп карасалар да, үз акылы үзе белән иде. Һичкемне тыңламады. Кокшай- скидан Семеновкага кадәр чаптырырга ат яллады. Таң беленгәндә, дусты Константин Дудовның бусагасында иде инде.

Аларның дуслыгы күптәннән килә. Дудов, Семеновкада кызыл мал сәүдәсе тотып, Казан белән ике арада исә агач дегете һәм сагызы белән сатудан узмаган майлы йөзле, җирән сакаллы, ни чирмеш, ни урыс һәм дә ни татар байларыннан иде. Тәрәзәсенә капланып, Шаһимәрданны танып алуга, ак ыштаннан йөгереп чыкты.

— Нәрсә, кенәз, таладылармы әллә? — дип бимазалана башлады.

Шаһимәрдан:

— Хуже,— дип, ат сорады.

Дудов аһ-ваһ итте. Чәйгә дә кереп тормасын белгәч, келәт башында йоклап яткан улы Семенны уятыр-га, ат җиктерергә боерды. Кужмарадан Чодраялга чыгасыларын, аннан Дөбъяз аша авылына кайтып ире-шәчәген ишеткәч, юлның кимендә атна ярымнар булачагын әйтте. Шаһимәрданның чыдамы бу кадәргә үк җитмәячәк иде. Атларны иярләтеп барырга булдылар. Дудов аңа үзенең иң яхшы дип белгән соры биясен атады. Семен белән каударланып чаптырдылар. Дудов исә:

— Кенәз, атны харап итмә, атны яндырма! — дип кычкырып калса да, сүзләрен ишетмәделәр. Берни эшләрлек түгел иде. Шунлыктан: — Биям харап булды! — дип, фуражкасын башыннан салып, каты итеп кулына кысты.— Биям харап булды!..

Ак айгыры бәрабәренә дусты Константинның йөгерек биясен яндыру Шаһимәрдан өчен берни дә түгел иде. Шунлыктан азга да тукталып ял алдырырга уйлап бирмәде. Тайга сукмаклары аның өчен таныш түгел иде. Юлсызлык һәр адымда диярлек көтеп торды. Инде кайтып җитәрлегенә ышанычы калмады, бу ур-манның бетәчәгенә, татар далалары башланып китәчәгенә өмете югалды. Шулай да алты көн дигәндә, тә-мам буталып, адашып йөрүләреннән соң, утлап узган көтү эзенә туры килеп, шуннан тайпылмый барып, Җәке авылына килеп чыктылар. Бабасы Гариф муллага куна төшеп, аның Казандагы Күл буе мәдрәсәсен-дә гыйлем эстәүче шәкерт улы Шәйхулла мәхдүмгә аталган яшь айгырын иярләттерде. Семенны, алтын ак-ча биреп, озатып җибәрде һәм юлын ялгызы гына дәвам иттерде. Бабасының:

— Кияү, ни булды, коймактан, балдан, каймактан, каздан авыз итмәдең? — дип, бераз кунак булырга кыставын да кабул итмәде, кыш урталарында гаиләсен төяп килеп чыгарга нияте барлыгын әйтте дә, галә-мәт бер маһирлык һәм омтылыш белән чаптырып, авылдан атылып чыгып китте, үрләр-сулыклар аша ту-рылап юл алды. Аның болай ашкынуында һичкемнең эше булмады, каршысына кем дә очрамады.

Авылында да аны көтми иделәр. Күбеккә батырып кайткан айгыры, нәкъ капка төпләренә килеп җит-кәч тукталуга, егылып аяк сузды. Янган иде, бахыр, хараплар гына булган иде. Каенише, мәхдүм Шәех үп-кәләр инде. Ярар, бу бәладән исән-сау котылса, үзенә туры атны багышлар.

— Нәрсә булды? — дип, утлар йотып каршы алган хезмәтчеләренә һәм хатыннарына, бала-чагаларына да игътибар итеп тормастан, ашкынып ишегалдына узды һәм ак келәтләре, таш пулатлары артындагы ат-лар аранына бәреп керде. Малкайлар дерт итеп куйдылар. Ак айгыры, тыныч кына солы күшисе урынга, ишекле-түрле тузынып йөри иде. Хуҗасын күрүгә, аңа таба пошкырынып килде. Араталык аша сузылып, кочагына башын тыкты.

— Казанның иң кәттә марҗасы да синең кебек булмас, бахыр! — диде Шаһимәрдан сөенеченнән һәм йомшап китте.

Алар бик озак бер-берсен иркәләделәр, бер-берсеннән иркәләнделәр. Болай онытылып, җанга җан, муенга муен берегүләре йорт халкы өчен гаҗәп хәл түгел иде. Ишегалды ягыннан хатынының, көнләшү-дән:

— Чукынды инде шул аты белән! Тәмам җенләнде. Үзен харап итмәгәе? Монда аунап, бер аты үлеп ята, ә ул анда икенчесен кочкан!..— дип, им-том иткәндәй төкеренгәләп сукрануы гына аны айнытып җи-бәрде.

Хаклы иде хатыны, бик хаклы иде...

Шәкүр карактан урлатмас өчен, шушы айгырын Шаһимәрдан бер ай буена абзарында кочаклап ятарга да риза шул! Тик менә ни әле, алай гына булыр микән?

Шаһимәрданның акылы кушланып, шунда ук бер фикергә килде: күрше-тирә авылларга хәбәр салыр-га, юлга, чокырларга, әрәмәлекләргә каравыллар куярга тиеш ул!

Кайтканыннан бирле өч атна узса да, Шаһимәрданга Шәкүр карак хакында һичбер хәбәр ирешмәде. Инде аталган бер ай вакыт хәерсезлеге һәм борчулары белән үтеп бара иде. Шаһимәрдан әфәнде дә, бу арада тынычланып, җанын урыныннан кубарган бәхәснең кызып китүдән генә булганлыгын төшенде. Шу-

лай да күңел тойгыларының бер тоем кылы һаман тартылып-тартылып куйгалады. Йортына Шәкүр каракны тәрәзәдән килеп керер сыман күз алдына китерде...

Айлы кич иде. Җиргә салкын сыкы иңде. Шаһимәрданның йорт тирәсен саклаган авыл агайлары, кичтән үк тергезгән учаклары тирәсендә гәп корып, көлдә күмелгән бәрәңге ашап, падишаһ хәзрәтләрендә егерме биш ел хезмәт иткән Солдат Гыймадетдиннең ничек Дунайда татарча сөйләшеп йөрүләрен, күз күрмәгән, колак ишетмәгән Әдрән диңгезе буйларында да татар сүзенең яхшы үтемле булуын, йөз дә беренче тапкыр булыр кимендә, тәмләп һәм йотлыгып тыңлыйлар, ара-тирә:

— Анысын әйтми калдырдың... Монысын да сөйләп уз инде!..— дип, ризасызлыклар да белдергәләүләре белән төнне уздырып маташа иделәр. Шунда ук араларында малай-шалай йокы таба алмыйча йөренә, уйный, төртешә. Аллаһы боерса, бүген-иртәгә бәхәс көне чыга, Шаһимәрдан җиңүче булып, Шәкүр карак оятка каласы. Инде ничәмә авыр көннәр һәм төннәр узды. Күбенә түзелде. Азга калгач кына уяулыкны югалту юк! Менә кызык итәчәкләр әле үзен, адәм көлкесе ясаячаклар угры Шәкүрдән!

Шаһимәрдан учак янына якынлашты. Әле яңа гына келә-йозакларын, тәрәзәләрен һәм тупсаларын тикшеренеп чыккан чагы, әмма келәтләр һәм абзар-куралар ягыннан шырт итеп агач сынган тавыштан сискәнеп китте. Аның нәрсәнедер абайлавын сизеп, янындагы иярченнәренең барысы да колакларын торгыздылар. Чебен очкан тавыш та ишетелергә тиеш иде.

— Урладылар... Урладылар... Тот... Тот! — дигән тавыш ишетелгән, каравыл кычкырган якка һәммәсе бердәм ташландылар. Аяк асларында бөтерелеп йөргән бала-чагалар читкә очты, алар кайгысымы хәзер.

Ул да түгел, якты ай нурында ак айгырның ялтырап-ялтырап алган гәүдәсе суда уйнаган чабак төсле күренгәләп калды. Бакча артлатып ул хәйран тизлек белән ераклаша бара иде.

— Атларны чыгар! — дип җикерде Шаһимәрдан.— Атларны чыгар! Артыннан төшәргә! Артыннан!

Татарга әмер кирәк. Ул шуны сөя. Кемнең алга чыгып дәшүе булса, артыннан калганнары иярә, анымоны уйлап маташмый.

Егетләре елгыр булып чыктылар. Кулларына утлы кисәүләр алып, атларга атланып, каракның артыннан дау күтәреп ташландылар. Бакча коймалары һәм читәннәре авып-ватылып калды. Шаһимәрдан үзе дә ат өстенә ничек менеп атланганын, кулына шахтерлар лампасы тоткан хәлендә чаптырып барганын сизенми иде. Чак кына мәтәлеп китә язганында гына айнып, атын тыярак төште. Кемнәрдер иярләреннән коелышып, атлар астында калдылар. Ул да түгел, Шаһимәрдан һәммә кешене узып алга чыкты. Тулган ай яктысында юл буйлап чаптырган ак айгырның сырты һәм көмеш яллары ялтырап әле генә күренделәр. Болай булса, куып тотасылар иде.

Шаһимәрдан тагын да атын куалады. Әмма сизенми калды. Алдында чокыр иде. Аты кинәт туктауга, башы аша китеп, шунда чумды. Сырты белән килеп төште. Күзләреннән утлар чәчрәде. Баш чүмече яңгырап куйды. Чигәләре әле киңәеп алдылар да чатнап авырта башладылар. Ул аңында иде.

Торып басты. Күктә, тулган ай тәмам җиде булып,бер-берсенә тагылышып әйләнә иделәр. Чаптырып килгән кешеләр чокырның яныннан гына узып киттеләр. Шаһимәрданны еккан ат, ни хикмәт, аларга иярмичә, гүяки гаебен таныган хәлендә пошкырып алды. Аллаһыга рәхмәт дими, нәрсә әйтәсең инде!

Шаһимәрдан, чокырдан күтәрелеп, атның йөгәненә ябышты. Һаман да башы әйләнүе бетмәгән, инде укшыйсы килә башлаган иде. Шулай да иярenә атлана алды. Кешеләре артыннан атын юырттырды. Әмма моннан хәле тагын да авырлашты. Атлатып кына барырга мәҗбүр иде. Баш сөяген ачып, су тутырганнар диярсең. Болгады да болгады. Чайкалган саен гүяки түгелеп китәдер сыман. Ул ак айгырын да уйламас дәрәҗәгә җитте.

Күрше авылның башында аны кешеләре көтә иде. Алар:

— Мәрдан абзый, авылны уратып алдык. Ат эзе монда кергән, әмма чыкмаган,— диделәр.— Авылда гына ул. Бер дә әллә кайда түгел! Шушында гына! Урап алдык! Таңгача сак торыйк! Иртәнге сәгать белән, якты күздә тиз табарбыз!

Бу тәкъдимнәрнең барчасын да кабул итәрлек иде.

— Шулай эшләгез! — диде ул, әмерен җиткереп.— Айгырны тапкан кешегә мең тәңкә бирәм!

— Мең тәңкә!.. Мең тәңкә!..— диештеләр кешеләре. Бу кадәр акчаны гомер буена да эшләп казана алмаулары һәм алмаячаклары аларның хыялларын тагын да хушландырды.

— Мең тәңкә!..

Ялгыш ишетмәдекме дигәндәй, алар бу сүзләрне тагын да бер-берсенә кабатладылар. Шул арада Шаһимәрдан атыннан төште. Алар күрсәткән тояк эзләре, чыннан да, юл тузанына кунган сыкыда аермачык диярлек ярылып ята иделәр. Танымыймы соң, бик таный, шуныкы, ак айгырының эзләре. Тоякка тояк, эзгә эз китереп баскан. Һәркайсы бердәй, һәммәсе тигезләр, муенса кебек!

Шаһимәрдан шул эзләр артыннан авыл урамына кереп китте. Бу вакытта каны кайнарланган, башының миңгерәве тәмам басылган, хәле яхшырып киткән кебек иде.

Эзләр аны, авыл урамына алып кереп, мәчет янынннан уздырдылар да тыкрыкка таба бордылар.

Айгыр монда бераз таптангалап торган. «Әһә, артыннан куучылар юкмы икән дип, Шәкүр карак тыңлаштырып маташкан инде» дип уйлап алды Шаһимәрдан. Ул да түгел, эзе кабат урам уртасына чыккан, юлын дәвам иткән. Әнә-әнә, йөгертеп кенә барган.

Шаһимәрдан урам буйлап киткән эзләрне карый-карый, тыңлана-тыңлана атлавында булды. Яңарак кына узганлыгы ярылып яткан һәм сизелеп торган арба юлына очрады. Кемдер югары як тыкрыктан төшкән, төнлә салам алып кайткан икән. Ул, борылып, сул тарафка кереп киткән. Саламы һаман да коела барган.

Айгырының эзен югалтмас өчен, Шаһимәрдан һаман да алга атлады. Әмма бераздан эше хөртиләнде. Тыкрыктан күтәрелгән ат көтүе барлык эзләрне бутап бетергән иде. Һай хәерсезләр, капка төпләре саен кереп киткәннәр. Җитмәсә, урам уртасына диярлек салам ишелеп калган. Монысы тагын каян? Теге йөк кереп киткән иде бит!

Шаһимәрдан чарасыз калды. Шулай да авыл башына кадәр килде. Чыгып киткән ат эзе юк иде.

— Бакча башларыннан сыптырмаганмы? — дип киңәште ул үзе белән үзе.

Әмма шунда ук аны ике елгыр егет эләктереп тә алдылар:

— Ә, каптыңмы, хәерсез!

Шаһимәрдан аларны уңга-сулга эткәләп куйды:

— Сез нәрсә, абзагызны танымаска!

Алар, аптырашып, аны шунда ук җибәрделәр.

— Белмәдек... Белмәдек! — диештеләр. Бу аларның гафу үтенүләре иде. Авылча.

— Шәкүр күренмәдеме?

— Саклыйбыз, узган-киткән булмады! — Егетләр чыннан да уяу иделәр.

— Бакча башлары, су буйлары ничек?

— Анда да безнекеләр,— диделәр болар, Шаһимәрдан абзыйларын сөендереп.— Авылдан чыкмады ул. Шунда булыр. Без уратып килдек. Каршысына төшәргә дип, монда ашыктык. Күрше авыллар да күтәрелеп килеп җиттеләр. Ул, безнең уратып алганны сизенеп, авылга кереп качты!

Шаһимәрдан бар халыкның да бу төндә уяу булуына хәйран итте һәм мең рәхмәтләр укыды. «Авыр чакта халыкка таян!— дия иде атасы, хаклы нәсыйхәт әйткән икән! — Җиңел чакта — дусларга!» Дуслар алар рәхәттә генә яхшылар шул, рәхәттә генә, акчаң барлыгын белгәндә генә!

Шулай да Шаһимәрдан бу каһәр суккан авылны кабат өч әйләнеп чыкты. Су буйларын да, бакча артларын да таң беленгәнчегә кадәр егетләре белән кат-кат тикшеренде, иснәнде. Кешеләрен даим уяу тотты. Һәм дөрес эшләде. Хәер, вәгъдә ителгән мең тәңкә берсенең дә күзенә йокы кертмәде.

Шәкүрнең, чыннан да, чолганышта калуына һичбер шик юк иде. Әгәр дә шушы хәлдә эш дәвам итсә, падишаһ хәзрәтләренең җиде йозаклы тимер читлегенә хәерсез ябалак, ат карагы ябылачак түгелме?

Шаһимәрдан, болар хакында уйлап, Шәкүр бәдбәхет өчен бераз борчылып, хәтта хәсрәтләнеп тә алды. «Андый кешене харап иттерергә ярамас, яхшы түгел!» Бу фикере урынлы булып чыкты. Чөнки халык арасында:

— Ул каракны акылга утыртырга кирәк! Капчыкка үзе килеп керде. Беркая да китә алмас, түрәне, үрәтникне, пәлисәйне чакыртыйк! — дип, иләмсез гауга купты.

Бу сүзләрне Шаһимәрданның үзенә җиткерделәр. Ул исә:

— Ашыкмыйк, җәмәгать! Сабыр итик, көлкегә калмагаек! — дип, бу кисәтүенә үзе дә хәйран итте. Чыннан да, көлкегә дә калырга мөмкин иделәр. Капчыкка кергәнең төлке түгел, мәче баласы гына булса, ни әйтерсең? Даның хәзер илгә таралачак!

Шаһимәрдан унбиш таза ирне сайлап алды. Калганнарны авыл тышында сакта калдырып, болары белән урамга таба атлады. Йорт саен кереп, тикшеренү-эзләнү эшләрен башларга тиеш иделәр. Мәзин авыл башында гына тора икән. Беренче булып аларга ул очрады. Шаһимәрданны танымый идеме, әллә кыланмышы шундыймы, башын кыегайтып-кыегайтып, маңгаена һич кирәкмәсә дә кулын куеп, озаклап карап торды:

— Кемнәр килә? — дип каршы алды.

Төнге вакыйгалар хакында ул берни дә белми иде. Шулай да:

— Кичә ахшам вакытында авылга чегәннәр кергән иделәр. Зимагур Гыйльметдиндә куна калганнарын гына ишеттем! — диде, сорауларга берьюлы җавап биреп һәм үзенең шиген белдереп.

— Кайда яши ул зимагурыгыз? — Шаһимәрдан бу соравын биргән арада, мәзин мәчеткә таба юл алган иде. Соңга калуы да бар шул, намаз вакыты керде. Халыкның әле кузгалганы да юк!

— Мәчеттән арырак, тыкрык эчендәге йортта,— диде мәзин, баруында булып, Шаһимәрданны егетләре белән бергә артыннан ияртеп,— күрсәтермен!

Зимагурның йорты — яхшы, каралты-курасы ныклы һәм биек читән белән уратылып алынган иде. Төнлә бутаган арба эзенең дә аның капкасыннан кереп киткәнлеген Шаһимәрдан чамалап-күреп килде. Менә болары аның үзенең эзләре.

Шул арада мәзиннең ягымлы тавышы авыл өстенә азан чакыруын җәелдерде. Озак та үтми, ишекләр, капкалар ачылганы, халыкның уянганы ишетелә башлады. Бары тик зимагур Гыйльметдин йортында гына хәрәкәт сизелмәде. Капкасын этеп караган иделәр, шайтан хәерчесе, ачылды да китте. Терәү дә салмаганнар икән үзләре.

Зимагурның ишегалды уртасында көлтә төялгән зур арба тора иде. Арырак — келәте, каралты-курасы, печән кибәне, тирес өемнәре. Ныклы һәм иркен тормыш белән гомер сөргәне күренеп тора. Каян килеп зимагур атаганнардыр?

Ике егете каралты-куралар ягына кереп китте. Шаһимәрдан үзе, тирес өемнәре янына килеп, биек итеп куелган печән кибәне янына атлады. Дәртләнеп кукырайган әтәч куркурлап алды, кетәклегендә кояшның чыкканын да көтеп тормастан, вак-төяк тавыкларын ияртеп, орлык чүпләштерергә ашыккан. Чит кешеләрнең йөргәненә исе дә китмәгәндәй кыланды сыман. Ул арада, Шаһимәрдан уң-сулны караштыргаңда, тирес өстенә менеп басты. Бу юлы тагын да кукыраеп тавыш бирде. Шаһимәрдан көнчыгыш якны күзәтте. Әле һаман да кояш чыкмаган, шулай да каурый болытларда алсулыгы сиземләнә иде. Төньяктан суык җил исеп, көннең җылы булмаячагын сиздерде. Кая ди инде ул октябрь аенда эсселек? И хәерсез гомер! Ни барысы дүрт ае җылырак булган кебек, аннан соң көннәр бозыла да бетә. Агачлар да яфракларын коярга тотына. Тапканнар бабайлар җәннәт асты туфрагын, кинәндергәннәр! Ярты дөньяны басып алып та, юньлерәк урын-биләмәләргә хуҗа була алмаганнар шунда!

— Шаяртма!.. Дурак дигәч тә!..

Йорт ягыннан ишетелгән тавышка Шаһимәрдан янына җыела башлаган егетләре дә игътибар иттеләр. Кайсыберләре хәтта сискәнешеп куйдылар. Хуҗаларның йокламавы аңлашылырга тиеш иде. Шаһимәрдан тәрәзәләргә якынрак килде. Ул да түгел, абзар-кура эченә тикшеренергә кергән ике кешесе дә аннан хәбәрсез чыктылар. Айгырның монда эзе дә юк иде.

Йорт эчендәге сөйләшүчеләрнең сүзләрен Шаһимәрдан аермачык диярлек ишетте. Араларыннан кемдер караштырып торган икән:

— Ишегалдында йөриләр! — дип, бүтәннәргә белдерде.

— Йөрсеннәр, айгыр — әллүр! — диде икенчесе, бу Шәкүр карак тавышы иде.

Тәрәзәләргә эчтән капланган чүпрәкнең кадак очы кадәр тишегеннән Шаһимәрдан якты лампа астындагы өстәл тирәли утырган кешеләрне күреп алды. Аннан соң, болай йөрүнең мәгънәсе юклыгын аңлап, ишеккә килде. Тартты. Ачылды. Керде.

Аны көткән иделәр.

— Сәлам, Шаһимәрдан! — диде Шәкүр бәдбәхет, өстәл түренә утырган җиреннән кузгалып та тормыйча.

Әмма кайтарып сәлам бирелүне өметләнәрәк көтеп тормады, әйләнәсендә утырган чегән кыяфәтле адәмнәренә:

— Әйдә, булмаса, өләш берәрдән! — дип әмер бирде.

— Атны син урладыңмы?! — дип, Шаһимәрдан аңа таба атлады. Әмма юлына тәрәзә янында торган камчат бүрекле адәм аркылы төште.

Шәкүр карак кесәсеннән олы күн кенәгә чыгарып, аннан бер мең сумлык бияләй кадәрле кәгазь акчаны алды һәм өстәлгә салды.

— Үзең бәхәсләштең! Менә, мең тәңкә акча! Бүген бер ай вакыт чыкты. Айгырыңны тапсаң, бу акча да, айгыр да синеке! Юк икән, бигайбә! Риза-бәхил! Куелган шарт — иман, малдан да, акчадан да өстен! Эзлә, айгырыңны тап! — диде, исе дә китмичә кәртләрен карый-карый.

Ул хаклы иде. Шарт үтәлергә тиеш! Ә юк исә, Шаһимәрданның дәрәҗәсе дә, байлыгы да һичнәрсәгә тормый, бәяләре сукыр бер тиен! Үзе күнде, Казан байлары шаһитлык иттеләр.

Шәкүр карак һәм адәмнәре кәртле уйный калдылар, Шаһимәрдан үз егетләрен чакырып, бөтен авылны тентергә, базларны да калдырмаска, чокыр-чакырын һәм сәндерә-түбә асларын да тикшеренергә әмер бирде. Шул сәгатьтән дөньяның астын өскә әйләндерү башланып китте. Шәкүр каракның аларда эше булмады, иярченнәре белән һаман да өстәл янында кәртле уйнап утыра бирделәр. Хәерсезләр!

Шаһимәрдан үзе үк, базларга кадәр төшеп, идән-сайгакларны каертып, ду китереп айгырын эзләтте. Ни башы, ни өянәге, ни егылуы, ни итагате онытылды. Печән өемнәре һәм эскертләр урыннарыннан күчерелде, кош-корт һәм мал-туар куркышып бетте. Авылдан хәтта көтүне дә чыгармадылар һәм читтән дә һичкемне кертмәделәр. Көн кичкә авышканда, бәрәңге бакчалары, яшертен базлары булмагае дип, башаяк актарылып, әрәмәлекләр кат-кат ергаланды. Әмма ак айгырның кыл бөртеген дә табучы булмады. Эз-

ләүне дәвам итүдән мәгънә юк иде. Һәммә халык тәмам арып һәм йончып бетте. Шаһимәрдан да, айгыры да, мең тәңкә акчасы да кирәк түгел кебек иде инде аларга.

— Әллә кайчан Әстерханга илтеп җиткергәннәрдер әле! — дип, Шәкүр каракның булганлыклары хакында риваятьләргә әверелгән вакыйгаларны бер-берләренә сөйләп, шуның белән күңелләрен юатырга тотындылар.

Халык акрынлап авыл башына җыелды. Кайсыберләре, кулларын селтәп, кайту юлына ук чыктылар. Шаһимәрдан аларны калырга, төне буе сак торырга өндәп карады. Әмма болардан файда булмады. Ак айгырның авылда булуына ышанычлары төкәнгән иде.

— Юк эш артыннан йөрибез,— диештеләр авыл агайлары,— эскерт астындагы энә дә табылыр иде бу кадәр актарынуга, бу кадәр эзләүгә!..

Шулай да берничә егет кичке сакка калырга килештеләр. Ә төн тыныч узды. Иртәнгә җирне катырып җибәрде. Суык аларның җилекләренә үтте. Шаһимәрдан суйдырып китерткән сарыкның сөякләре генә калды.

Таң беленгәч, тагын авылга керделәр. Бу юлысы мәзин инде мәчет манарасыннан азан чакыруын әйтеп маташа, халык аякка басарга өлгергән иде. Шаһимәрдан һаман да шул зимагур йортына килде. Ишегалларына сибелгән кош-кортлары аңа бу юлы да игътибар бирмәделәр, әтәче һәм тавыклары, кыткылдый-кыткылдый, элеккечә тибенгәли, орлык чүпли иделәр.

Шаһимәрдан, ишекне киң ачып, йортка узды. Ул күз алдына китергәнчә, Шәкүр карак үз адәмнәре белән өстәл янында һаман да кәртле уйнап утырырга тиеш иделәр. Әмма берсе дә күренмәде. Бу бушлык аны кергән җирендә һушын алып туктатты. Ятак өсләре дә буш, мич артындагы сәндерәдә һәм сәкедә дә адәм заты күренми иде. Шаһимәрдан артыннан зимагур Гыйльметдин авыр адымнары белән килеп керде. Ак ыштанын юантык корсагына таба күтәреп:

— Суытып җибәрде. Ай-һай, кыш салкын килер! — дип сөйләнеп алды, гүяки алар бергә гәпләшеп көн кичергәннәр, имеш. Исәнлек-саулык та сорашып тормады.

— Ат караклары кая? — Шаһимәрданның болай ачу белән эндәшүендә Гыйльметдиннең һич эше юк иде.

— Киттеләр, йокларга ятканда, юлга чыккан иделәр инде!

— Ничек?

— Шулай... Җыендылар да китеп бардылар.

— Ә айгыр кая? — Шаһимәрдан шунда зимагурның бугазыннан алды:— Айгыр кая?.. Зинданда черетәм үзеңне!..

Гыйльметдиннең бу сүзләргә дә исе китмәде. Шаһимәрданның кулын, якасыннан кубарып, читкә алды.

— Ни өчен зинданда? Айгырыңны урламадым, падишаһ хәзрәтләре алдында гаебем юк!..

— Каракларны, ат каракларын яткырганың өчен, өеңдә асрап...— Шаһимәрдан икенче тапкыр якаламакчы иде, Гыйльметдин бу юлы аның сузылган кулын җиңел генә этәреп куйды.

— Үзең күрдең... Берсен дә яшереп яткырмадым. Кем килсә дә, ишегем ачык, рәхим итсеннәр! Юлчыларга, кунакларга ишек ачарга Аллаһы Тәгалә үзе, Ходай кушкан. Ә айгырыңны урлауларын күрмәдем. Анда минем катнашым юк. Шәкүр карак белән үзең шарт куешкансың...

Бу сүзләре һәммәсе хак иде. Шаһимәрдан чарасызлыгыннан һәм тинтәклегеннән хәлсез калды. Хушлашмый чыгып китте. Анда көтеп торган егетләре аның артыннан иярделәр. Айгыры урланган, ат караклары качкан, эш узган иде инде. Бар тырышлыклары әрәмгә калды. Шаһимәрдан вакыйгаларның барышы, язмышының рәнҗетүе белән килешергә мәҗбүр булды...

Моннан соң җилләр дә күп исте, сулар да күп акты, дияр идек тә, ярар инде, берничә ел узуы мәңгелек алдында әллә нәрсә түгелдер!

...Әмма ни шул, ә Герман сугышы тарихны бүтәнчә борып алып китте. Падишаһка тел-теш тидерү гадәти әйбергә әйләнде, байларга көпә-көндез, курыкмыйча йодрык күрсәтүләре дә эчне пошырмый, дөньялыкны хәерсез битарафлык һәм мордарлык баса башлаган чор иде. Казанга килеп, Шаһимәрдан сыраханәдә гамьгә бирелеп утыра иде, аның өстәленә бер тавык та бер савыт китерделәр:

— Рәхим итегез!

— Сез нәрсә? — диде ул, аптыраулы карашын төбәп:— Мин боларны сорамадым!

— Юк,— диде китеручe,— моны сезгә сыйланыр өчен юлладылар...

— Кем?

— Әнә теге, җирән сакаллы әфәнде! Без яхшы танышлар, диде.

Бу җавапны ишеткәч, Шаһимәрдан шул якка борылып карады. Зур өлгеле тәрәзә янында Шәкүр карак үзе генә елмаеп утыра иде. Сәламләшеп, баш кагыштылар. Бу мизгелдә Шаһимәрданның аңа карата сак-

лаган ачуы һәм үпкәсе юкка чыкты. Ничә елга беренче тапкырдыр күңеленнән гаме юылып төште. Күптәнге якын дустын очраткан кеше кебек балкып күтәрелде һәм аның өстәленә бар ризыклары белән күченде. Кул кысышулары бик җылы, дустанә булды. Дөрес шул: «Этнең койрыгын кем киссә, шул яхшы!»

Шаһимәрдан кесәсеннән калын кенәгәсен чыгарды, Шәкүрнең алдына мең сумлык акча салды:

— Бирәчәгем калган иде!.. Рәхим итегез!..

Алар бер-берсенә карап тордылар. Шунда Шәкүр карак, тагын да җәелеп, елмайган җиреннән хахахалап җибәрде. Бераздан соң тыелгысыз көлүгә күчте, аңа Шаһимәрдан кушылды. Сыраханә халкы аларга күтәрелеп, борылып, аптырашып карап-карап алгаладылар.

— Былтыргы акча быелгы акча түгел шул! — диде көлүдән тукталган Шәкүр карак, бәяләрнең үзгәрүен, акчаның көче бетә баруын искәртеп.

Ул хаклы иде. Хәтта Шаһимәрдан да элеккеге гаярь, гамәлдә алдын-артын уйлап тормыйча эш итүче шашкын адәм түгел инде.

— Былтыргы акча быелгы букчага артык түгел,— дигән булды ул, үзенең кемлеген һич тә киметергә теләмичә.

Хәер, Шәкүр карак, шунда ук сүзне икенчегә борып:

— Сәүдәләр нишли? Эшләреңне бик алай тәгәри икәнлеген сөйләмиләр,— дип, Шаһимәрданның күңеленә авыр сүз арбасының күчәре белән төрттереп узды. Бераздан:— Башыңа бәла алма, булган эш — беткән эш! — диде юаткандай. Аның бу рәвешле әле суга, әле утка әңгәмәдәшен чумдырып-чумдырып алуы үзе үк хәйләкәрлеге һәм акылы билгесе иде.

— Айгырым белән кул артым да китте, бәхетемне урладың!..

Шаһимәрданның болай зарланырга хакы бар иде. Соңгы елларда, чыннан да, ни сәүдәсендә, ни гаиләсендә, ни иманында тотрыклык булмады. Бохарага киткән кәрванын казакъ даласында таладылар. Сыңар энәсен дә коткарып кала алмады. Вәкиле Миңнегалинең кисек башын Өре каласындагы таш мәчет ишек төбендә, күн капчык эчендә аунап ятканда табып алдылар. Зәйнулла ишаннан алган «Фатиха кәгазе» маңгаена чәпәлгән, теле киселгән, колакларына «тавык тәпиләре» эленгән иде. Моны кемнәр эшләргә мөмкин, дип, никадәрле баш ваттылар. Имеш, казакълар арасында, әле урыска, әле иманга күчеп, тәмам бозылып беткән бер кавем бар икән. Ни Коръәннән, ни Инҗилдән курыкмыйлар, ди. Үзләре шигырь әйтеп, җыру майтарып, шайтан чакыралар, аракы эчүгә бик хирыслар, күкрәк сугышып:

— Мокыт-быкыт, акыт-бакыт! — дип баш болгап, җаннарын иблис карамагына юллыйлар икәнлеген әллә ничә тапкырлар сөйләп, Шаһимәрданның казакъ ханнарына барырга ниятләнеп йөргәннәрендә күңелен кайтардылар.

Дөньялыкта мал бетмәскә тиеш иде. Җаен белсәң, кулга үзләре керергә торалар. Мокыт кавем белән ярышып яталар димени!

Шаһимәрдан бер-бер артлы ике кәрван мал алып, аның башына үзе менеп, хаҗ кылу нияте белән төрекмәннәр арасына чыкты. Аңа һәркайда кадер-хөрмәт күрсәттеләр. Нугай ата исеме белән Һиратка, аннан Һиндстанга юл алды. Һәркайда сәүдәсе уңыш белән гөрләп барды. Малы ишләнде. Нинди илгә-җиргә килмәсен, үзеннән алда Нугай ата исеме ирешкән, кемлеген күрер өчен, биш күз белән көтеп ала иделәр. Һиндстанда кәсеп юлын туктатып, кәрванын зур маллар белән йөкләп, иленә кайтырга чыгарып, озата калды. Үзе, хаҗилар җөббәсен киеп, кулына Коръәнен алып, асыл мөэминнәр гамәленә төште. Көймә белән Җиддәгә юнәлде. Аның кебек хаҗилар арада галәмәт күп иделәр.

Әмма бәхетен, чыннан да, сыер сөзгән иде. Мөхит диңгезенең кара дулкыннар айгыры тезгеннәреннән ычкынды. Иләмсез су тешләре, тау-тау булып ишелеп-ишелеп, көймәнең өстенә килде.

— Арабызда гөнаһлы бәндә бар, юкса хаҗилар юлын боздырырга Аллаһы Тәгалә рөхсәтен бирмәс иде,— дип гаеплене эзләп, шобага тотыштылар. Тәкъдир әмере Шаһимәрданга чыкты.

— Нугай ата, «Фатиха» укы, иманыңны яңарт, диңгез сине корбанга сорый! — диделәр аңа. Аны-моны уйлап өлгергәнче, күтәреп алдылар һәм тау булып килгән дулкынга чумдырдылар.

Аллаһының теләге шул идеме, Шаһимәрдан җаны белән хушлашырга да җитешмәде, аны шунда ук бирән диңгез йотты. Әмма упкынның бугазына ул сөяк кебек аркылы килгәнме, әллә Шаһимәрданның ризыгы бетмәгәнме, диңгез аны комлы эссе ярга чыгарып бәрде.

Күзен ачканда, Шаһимәрдан бер алачыкта бизгәктән шабыр тиргә батып ята иде. Аңа кайнар каһвә эчерттеләр. Иреннәре пеште, тамагына куырган кургашын койганнар кебек тоелды. Ул тагын да аңын югалтты. Хаҗилар җөббәсеннән булуы файдага иде. Кемлеген белеп, һәртөрле хөрмәтне күрсәттеләр, Коръән укып өшкерделәр, үләннәр кайнатып эчерттеләр. Бу кешеләр әле җәннәтнең фәрештәләре, әле тәмугның җеннәре кебек тоела иделәр. Шаһимәрдан үзен, һичшиксез, үлгәннәр исемлегендә дип уйлады. Шулай да җәннәтле буласы килә, янында буталучыларны да шунлыктан фәрештәләр сыйфатында күрергә

тели иде. Бу кешеләрнең кара тәнле, җен кыяфәтле икәнлекләренә аптырап, җитмәсә, казан астында ут көйрәвенә дә күзе төшеп, чыннан да, гамәле хараплыгын, тәмугка эләгүен уйлап, ара-тирә бөтенләй хәле китеп, файдасы тияргә мөмкинлектән иман кәлимәләрен укып, тәүбәләр әйтеп елаштыра башлады.

Аның янына ике адәм килделәр. Аяк-кулларыннан тотып күтәрделәр дә казан өстенә китерделәр. Ул кайный, быгыр-быгыр килеп, эссе пар ата иде. Шаһимәрдан үзен анда салуларын теләмәде. Бәргәләнде, тартылды. Әмма көче җитмәде. Казанның пары аның бугазына утырды, тончыкты, буылды. Хәле китте. Тәне көядер кебек тоелды. Шунда кабат аңын югалтты. Тәмугка төшүендә һич шик юк иде!

Әмма Шаһимәрдан барыбер бирешергә теләмәде. Бар белгән догаларын һәм Коръән сүрәләрен күңеленнән туктаусыз укып, шушы бәладән иртәме-соңмы котылу өметендә калды. Телендә бу сүзләр иде:

— Аллаһы Тәгалә барча колларына да рәхмәтле, мәрхәмәтле!

Йокылы-уяулы укынуларын ишеттеләр булырга кирәк, аны бүтән бер тапкыр да казан янына китермәделәр. Аягына басканда, үзен сихәтләнгән итеп тойды. Аның алдында һәркем тез чүкте:

— Юныс! Юныс! Әлхәмдүлилләһи! — дип сәлам бирделәр.

Шаһимәрдан бу сүзләрнең мәгънәсен төшенергә өлгерде. Балык авызыннан чыккан Юныс пәйгамбәр хакындагы кыйссаны ул бала чагыннан ук белә иде. Халыкның ялгышуы аны куркытты. Мөмкин булса, тизрәк китеп барыр, качар иде. Шулай да ул монда тәмам ныгып җиткәнче калырга мәҗбүр. Кешеләрнең аңа мөгамәләсе яхшы, холыклары тигез һәм хөрмәтчел иде. Үз мәкаме белән Коръән дә укып җибәргәч, яшекарты, күзләреннән яшьләрен чыгарып:

— Йа рәсүл, йа Аллаһ! — дип сәҗдәләр итә башлагач, Шаһимәрданның тагын да коты очты. Артка чигенде. Шунда кулына Коръән китереп тоттырдылар. Ул аның үзенеке иде. Хәтере яңарып, исенә төшерде: юлдашларының көймәдән ташлаган чакларында, күкрәгенә кыскан шул Казан басмасы «Кәлиме-Шәриф» иде. Аңа һәммә әһеле, изге олуг затка өмет белән караган төсле, могҗиза теләп күз текәделәр. Шаһимәрдан алай ук арбадан төшеп калганнардан түгел иде. Әмма әле генә башы да эшләп җиткермәде, шулай да күңеленә килгән фикеренең җебе очына ябышты. Коръәнен ачып укый да башлады. Аның тавышы халыкка могҗиза булып ишетелде. Күзләренең яшьләнүеннән сизенде. Аллаһының рәхмәте, Юныс пәйгамбәр хакындагы аятьләргә туры килеп, иш өстенә куш дигәндәй, хикмәт янына хикмәт иде бу.

Аны күтәреп кенә алмадылар. Әллә кайлардан ишетеп, әле аксакаллар, әле сукырлар җыелыша, гарип-гораба балаларын күтәреп килә башладылар. Шаһимәрдан:

— Мин рәсүл түгел, мин пәйгамбәр түгел! Нигә киләсез? — дип, аларга үз телендә мөрәҗәгать итеп карады.

Әмма күңел чиләкләренә өмет суы тутырып җыелган халык аның бу сүзләрен әллә ниткән бер догаөшкерү, Аллаһының хикмәтле сүзе сыйфатында кабул иттеләр. Егыла-түнә:

— Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр! — дияргә тотындылар.

Аларның сәҗдәләре Шаһимәрданны куркуга салды. Ике кулын да күтәреп, артка таба чигенде, үзе:

— Мин — Нугай ата, мин — Шаһимәрдан! Нишлисез? Нигә мине җәберлисез? Мин беркем дә түгел! — дип, коты алынган хәлендә сөйләнде. Гарип-гораба халык тезләрендә аңа таба якыная торды. Ул диварга барып терәлде. Ахырда: — Лә иләһә иллаллаһ, Мөхәммәдүррәсүлуллаһ! — диде.

Аның сүзләрен халык та бердәм кабатлады. Йөзләрендә шатлык һәм сөенеч иде. Һәр сүзен дога һәм Аллаһының хикмәте дип кабул итүләре сәбәпле, Шаһимәрдан чарасыз калды. Гарәпчә сөйләшә белмәвенең җәфасын менә шушында барча тулылыгы белән татыды. Хәлсезләнеп егылды. Һичкемне күрәсе килми иде.

Халык аның янынан тәннәренә сихәт табып китәр, дип, башына да китермәде. Әмма язмыш аңа бәхет сукмагына юл күрсәтте. Шаһимәрданның даны Юныс әүлия исеме белән еракларга таралды. Ул үзенең ата-анасыннан мирас итеп алган татар сүзенең никадәр сихри һәм тәэсирле икәнлеген бары тик шушында, чит илдә, ят халыклар арасында татыды. Югыйсә кешеләр, илләреннән аерылып, ана телләреннән башканы белмичә хафада калалар, ә ул тулы бәхеткә төкәнде. Әүлиялыгын үзе дә танырга мәҗбүр булды.

Аңа көннән-көн кешеләр күбрәк килә, барысы да сәламәтләнү өметендә алдына егыла, тынычлык табып, гүяки әбелхәят суын эчкәндәй балкып китә иделәр. Шаһимәрданның йорт хуҗасы да күзгә күренеп баеды. Һәрдаим аның өчен җан ата, гомерендә һичкемнән тапмаганны аннан казанганга, аңа урынын да түргә күчерергә мәҗбүр булды. Әмма монда торып калу Шаһимәрданның исәбендә дә юк иде. Юлга чыгар өчен кулында малы булса, һич тә тоткарланмаячак ул!

Шушы уйлар белән йөргәнендә, ул үзенең күңеле тутыга барганлыгын тойды. Байлык җыярга керешүе моңа сәбәпче икәнлеген уйлап та карамады. Ә көннәрнең берендә агач күләгәсендә ялгызы гына утыра иде, ике кешенең кочаклашып, җырлашып һәм төрткәләшеп килүен күреп хәйранга калды. Ни кайнар канлы гарәп халкында ком чүленең эсселеген якалашу белән сүндерергә омтылу хисе барлыгына инде сәерсенми иде югыйсә. Әмма болай ук булырлар, мондый хәлне дә тамаша кылырга туры килер, дип, башына

да китермәгән иде. Исенә Казан шәһәре килде. Андагы бурлак урысларның, артыгы белән эчеп алып, әүвәле урамнардан кочаклашып, җырлашып узуларын, аннан тыкрык һәм чатларда каннарга батып калай әтәчләрдәй сугышуларын-чәкәләшүләрен хәтеренә китерде. Бу вакытта аңа шул якташлары, нинди генә юньсез булмасыннар, бик якын һәм үз булып тоелдылар. Шуңа да күләгәдән чыкты, теге, кочаклашып, сугышып һәм дәгъвалашып килүчеләргә таба атлады. Шушы дөнья читендә дә урысларның пәйда булуы сәеррәк иде.

Аралары якынлашкан саен, Шаһимәрдан үзенең буе кечерәя барганын тойды. Бу ике кеше дигәне гәүдәгә олы булып чыктылар. Шушы Йәмән илендә мондый кешеләр юклыгы аңа яхшы мәгълүм иде. Әмма болар да гарәпчә сөйләшә, тарткалаша, Шаһимәрданга игътибар да итеп тормастан, бер-берсенең башларына субай чүкечедәй олы йодрыклары белән тондырыша иделәр.

Шаһимәрдан таңга-гаҗәпкә калды. Бу ике кеше дигәнен һич тә камил дәрәҗәдә ике зат дип булмый иде. Дөресрәге, һәркайсында икешәр аяк, икешәр кул, берәр баш, ә гәүдәләре — уртак. Кеме беренче булып төртсә дә, шунда үзе үк кычкырып җибәрә, авыртуны беренче булып үзе тоя иде.

Моның ат кәмите түгеллеген аңлаган Шаһимәрдан алар янынннан тизрәк качу җаен карады. Иләмсез олы гәүдәле бу мәлгуньнәр аны таптап китәргә дә мөмкин иделәр.

Халык йорт түбәләрендә шушы хәлне тамаша кылганда, Шаһимәрдан өй биеклеге зур таш тавы өстенә үрмәләде. Ә тегеләр ул арада төртешүдән сугышуга, сугышудан елашуга, елашудан дөмбәсләшүгә күчтеләр. Ахырда икесе дә, тәмам арып, аунаган җирләрендә ятып калдылар. Аларның шушы хәлдә гырлап йокыга китүләре шулай ук бик сәер иде. Шаһимәрдан бу күргәннәрен ничек дип аңларга да белмәде. Исән чагында, таш тавыннан төшеп, алачыгына таба ашыкты. Кайтып ишеген ябуга, түбәдән хуҗа сикерде һәм:

— Әэҗүҗ-Мәэҗүҗ! — дип, теге адәмнәр яткан якка төртеп күрсәтте.— Дәҗҗал...

Ул хаклы иде. Бу хәл, чыннан да, Әэҗүҗ-Мәэҗүҗ галәмәтеннән булырга тиеш, башкача аңлату мөмкин түгел!

Шаһимәрдан тагын да хәтерен яңартты. Дөбъяз агы Җәке авылының атаклы мулласы, бабасы Гариф хәзрәткә атын харап иткәннән соң, айгыр вәгъдә ителеп тә, алмашка бия китерә килгәч:

— Безнең татар кавеме Әэҗүҗ-Мәэҗүҗдән булырга кирәк! Искәндәр падишаһ безне тәрәккый иткән кавемнәрдән аерып куяр өчен, Дәрбәнд илендә биек дивар төзеткән,— дип, әллә нинди бер тарих китабын укуын, Шәкүр каракның исә моңа дәлилле мисал икәнлеген сөйләгән иде.

Ялгышкан хәзрәт, ялгышкан! Менә нинди була икән ул Әэҗүҗ-Мәэҗүҗ! Менә кем икән ул Дәҗҗал!

Әмма Шаһимәрданга озак уйланып утырырга насыйп булмады. Авылның олы агайлары ишекне күтәреп керделәр. Йорт каршысына барча халыкның җыелганлыгын Шаһимәрдан дә алар тупсадан атлаганда ук күреп калды. Керүчеләр шунда ук сәҗдәгә киттеләр. Аларның:

— Йа Мәһди, йа коткаручы! — дигән сүзләрен Гатауллин аңларга өлгереп калды. Аны хәзер Юныс дип һичкем атарга җыенмавын төшенде. Борынгыдан килгән хәбәрләрне, Коръән аятьләрен ул үзе дә белә иде. Ахыр заман җитсә, Дәҗҗал кубар, Әэҗүҗ-Мәэҗүҗ чыгар, әмма аларга каршы Аллаһы Тәгалә Мәһди пәйгамбәрне җибәрер!

— Юк, мин — ул түгел, Мәһди түгел! — дияргә ирек бирмәделәрме, әллә әйткәннәрен дога дип кабул иттеләрме, барысы да «Аллаһу әкбәр!» сүзләре белән тагын сәҗдәгә киттеләр. Вакыйгаларның һаман да шулай халыкка кирәкчә борылыш алуына ул күнегеп беткән иде. Әмма Дәҗҗал һәм Әэҗүҗ-Мәэҗүҗләр белән алышырга кодрәте җитмәячәк! Моны гына яхшы аңлый. Ялган пәйгамбәрлек, ялган әүлиялык үзен ахырда, һичшиксез, харап итәчәген дә күзаллый. Тик нишләргә мөмкин? Качып китсә генә инде!..

Шаһимәрдан шушы фикереннән тыш башкача чарасы юклыгын яхшы аңлады. Тик менә кая, ничек качып китү җаен гына белми интегә. Барыбер мәсьәләнең ахыры килеп чыгасы, оятлы булачагы аны куркыта иде.

Нәкъ шул вакытта Дәҗҗал дигәннәре кабат купты. Үкерү авазына борылып караса, ул алар өстенә кулларын болгап килә иде. Куркынган халык, гүяки тавык чебешләре тилгәннән өркенгән кебек, кайсы кая йөгерешә-кача башлады. Дөяләр, сискәнеп, диңгез ярына ташландылар, тузан, гауга купты. Шушы мәхшәрдә Шаһимәрдан ныклы тезгененә бәйләнгән, уңга-сулга тартылып-дулап та ычкына алмаган җирән бияне күреп алды һәм аңа таба йөгерде. Атка утырырга өлгермәде, ул аны дөяләр артыннан дулатып алып китте. Малкайлар шулкадәр дә куркышкан иделәр ки, күбеккә батканчы чаптылар да чаптылар. Кичкә дөяләр үзләре Шаһимәрдан тирәсенә елыштылар. Инде аларга ул үзе хуҗа иде. Йорт хайваннары шундый җаннардан инде алар, үзләренә адәм баласының баш булуын яраталар, аңа сыеналар, аңа буйсыналар.

Шаһимәрдан кире кайтырга теләмәде. Калкулыкка күтәрелеп, һәр тарафны күзәтте. Дөяләрне җыеп бетерде. Нукталарын бер-берсенә бәйләде һәм ятып йоклады. Аллаһының рәхмәте, төн тыныч узды. Аның артыннан куып та, эзләп тә килүчеләр булмады. Икенче көнне ерактан узып баручы кәрванны күреп, артыннан иярде. Ялгышмады. Юл аны Йәмәннән читкә, еракка алып китте.

Шам илендә Шаһимәрданның телен аңлаучы төрекләр күп булып чыкты. Кырык бер баш дөясен сатып, шактый гына акча юнәтте. Калган сигез дөягә товар йөкләп, Һират һәм Бохара тарафына озатучы хезмәтчеләрне яллап, юлга чыкты. Сәүдәсе һәр базарда уңышлы барды. Кәрвансарайларда халык авызыннан Йәмән илендә яшәүче әүлия хакында гаҗәеп хәбәрләр, риваять һәм хикәятләр ишетеп, күңелендә хәтта шул кешене күрү теләге дә кузгалды. Әмма аңа бары тик көзгегә генә карау кирәклеген, ул аны шунда күрәсен, сөйләнелгән сүзләрнең үзе хакында барганлыгын башына да кертеп карамады.

Шаһимәрданның кулы мал кергәнне ярата иде. Никадәр күбрәк булса, шулкадәр сөенечлерәк. Ул гына да түгел, мал үзе дә аның кулы аша узуны сөя иде, ахрысы.

Шушы исәпләре белән Шаһимәрдан Бохарага килеп җитте. Әмма бу вакытта кыш фасылы кереп, коры һәм суык һавадан гаҗизләнгән шәһәр халкы арасында һәртөрле авырулар башланып, аңа да йокты. Тора алмас хәлгә төшеп, урын өстендә атналар буена юньле тәрбия күрмичә, тәмам ябыгып, үлем түшәгендә ятты. Товарына-малына күз-колак булучы юк иде. Ни иманлы мөэмин-мөселман халкы саналган бохараларның нәфесе бозык, кальбләре сафлыкны оныткалыгын танырга мәҗбүр ителде. Ун көн дигәндә, малтуарларына яңа хуҗалар табылып, күп өлеше әмирнең хәзинәсенә алдырылган, Шаһимәрданның үзенә тамгасыз сәүдә иткән, дип гаеп тагылган иде. Ялангач калып та, Аллаһы рәхмәте белән кабат тернәкләнеп киткән, яңадан аякка басып та, йөзтүбән мәтәлгән кешенең күңеле тулы сабырлык булырга тиеш иде инде ул. Үз малын кабат кулына кайтару өчен, Шаһимәрдан ничәмә тапкыр әмирнең бусагасына килеп карады. Әүвәле камчылап сөреп чыгарсалар, ахыргы килүендә зинданга салып, язга кадәр тоттылар. Бу зиндан дигәннәре үләксә базыдай чокыр булып, анда гаепле дә, гаепсез дә бер үк түбәнлеккә ыргытылган иделәр. Ризык та юк дәрәҗәсендә, бирелгәне дә этләргә ташлана торган коры сөяк һәм чүпле арпа бөртекләреннән генә гыйбарәт булса да, Шаһимәрдан бирешмәде, үз өлешенә теше-тырнагы белән ябышты. Шунда ул үзенең ахмаклыкларын уйлап, безнең мөселман хуҗасы, безнең падишабыз дип ышанып йөргән Бохара әмиренең исламга, гаделлек һәм хаклыкка һичбер катнашы юклыгын, намуслы кяфер белән чагыштырырлыгы да калмавын төшенде. Әмма терсәк тешләргә соң иде инде.

Зиндандагыларның кайсыберләрен вакыты җитеп чыгара, хөкемгә тарта тордылар. Берсе генә дә кире кайтарылмады. Нәүбәт Шаһимәрданга да бүген-иртәгә җитәргә тиеш иде. Әмма һаман да аны искә алучы булмады.

Адәм баласыннан бар да йөз чөерсә, бәла ярдәмгә килә, әгәр дә Аллаһы кушса, дигәннәрен ишеткәне бар иде аның. Нәкъ шулай булып чыкты да.

Зиндан эченә баскыч төшергәннәр иде. Югарыдан кемнедер дәшеп кычкырган вакытта, кинәт җир кузгалып, тетрәнеп куйды. Зилзилә кубарга тиешлеген һәркем аңлап, югарыга атылды. Шаһимәрдан алардан калышмады. Берләре түбән очтылар, сытылдылар, харап булдылар. Якты дөньяга борын төртүгә, Шаһимәрдан әүвәле бер почмакка сеңде. Тавыш-гауга, буталыш дәвам итте. Җир, тагын бер калтыранып, диварларны ярды, бозды. Анда да, монда да үлем иде. Шаһимәрдан, ничек тә Бохарадан чыгып, төрекмән арасына, көнбатышка таба юл алды. Казакъ даласына ышанычы юк иде.

Мең газап һәм гаделсезлекләр аша үтеп, иленә кайтып егылган ирнең кадерле булырга хакы бар! Әмма Шаһимәрданны монда да мыскыллау һәм түбәнлекләр көтеп торган икән. Аны һәлак булган дип бүлешеп, хатыннары, җәһәтрәк яшь хезмәтчеләренә чыгып, башлы-күзле булып беткәннәр, малларын бүлгәләшеп, йортын-җирен туздырганнар.

Шаһимәрдан кайтып төшүгә, ярты авылы йокысыннан калды, ярты авылы тавыш-гауга коткысына бирелде. Хәләл малына кул сузарга һичкемнең хакы юк иде. Кайтарып бирергә теләүчеләр дә күренмәде. Шаһимәрданның бәхетенә, Җәке мулласы Гарифның кызы Бибисәрвәрҗәмилә, карт хатыны, әле кияүле булырга өлгермәгән, таланганнан калган малы белән сукранып яшәп ята иде. Аның анысы да:

— Хатын өстенә хатын алып, бала өстенә бала таптырып, әллә кем булмакчы идең. Үзең олагуга, барысы таралып беттеме? — дип, Шаһимәрданны мыскыллаудан узмады.

Үлеп котылган кеше генә мәсхәрәнең авырлыгын күрми. Шаһимәрдан сер биреп торырга, тавыш-гауга куптарырга ниятләсә дә, ахырда: «Бу җәфалардан, хәсрәт капчыкларыннан котылдым әле!»— дип, эчтән куанды, тыштан үзен ачулы күрсәтеп, һичкем белән исәнләшмәс һәм исәпләшмәс булды. Яңадан да сәүдәсен яңартып, Казанга мал белән килер дәрәҗәгә җитте. Тәүге базарыннан соң әл-хәл алгач, сыраханәгә аяк басты. Шәкүр карак белән очрашуы да нәкъ шушы керүендә булды. Бу вакытта илдә — сугыш, Германның күтәрелгән, халыкның гаҗизлеккә төшкән еллары иде...

Шаһимәрдан өстәлгә җәеп салган мең сумлык акчасына кызганып карап алды һәм:

— Шәкүр агай, ал моны...— дип үтенде.— Дөнья читеннән шушы бирәчәгемне тапшырырга кайттым. Алачак тотмый, бирәчәк тота икән!.. Шулай да, ничек урладың ул айгырны?.. Эзеңнән килеп тә табалмадым шул!..

Шәкүр карак күзләрен елтыратып елмайды да:

— Бүтәнгә булса, сөйләмәс идем. Ярар, сиңа әйтим инде,— дип сүзен башлады.— Эш болай булды, кем, энем хәзрәт... Шактый газапладың син мине, билләһи! Ай буе урманда яттым. Егетләрем тузына башладылар. Төннәрен төшә идем. Ә авылыңны әйләнә буенча катлы-катлы уратып саклыйлар. Ихатаңа да керерлек түгел. Шулай да сәндерәңә менеп яттым. Көне буе күзәтеп, белешеп, җай эзләп аптырап беттем. Минем бәхеткә, синең көенечкә, яшь хатының белән ат караучың печәнлектә шаяргалыйлар икән. Берсе әйтә: «Кирәкми, Ярулла, эшебез сизелсә, адәм хуры булырбыз»,— ди, икенчесе: «Йә инде, Гыйззебану, бер кочканнан гына кендек чишелми»,— дип, тегене үчекли. Онытылып киттеләр дә ачкычларны төшергәннәрен сизми дә калдылар... Ишетеп беләм, башлы-күзле булганнар икән!..

Шаһимәрданның сабыр гына тыңлап утырудан гайре чарасы юк иде.

Шәкүр карак исә сүзен дәвам итте:

— Шуннан шул ачкычларны алып, үз кесәмә салдым да, эшнең ахырын уйлап, бераз йокыга талдым. Әй кыштырдыйлар, әй печәнне болгаталар. Уянып китсәм, Яруллаң ачкычларын эзли икән... Мин айгырны урлаган төндә келәтең бикле түгел иде. Егетләрем белән бергә, чегән сурәтенә кереп, күрше авылдагы Гыйльметдингә төштек. Аңа аны-моны белдермәсәк тә, халыкта сүз булган икән инде, ул да барысыннан да хәбәрдар иде...

Айгырны аларга урлап кайтардым... Ялганчы йозак: «Килегез, кил, мин — ачык!»— дип көтеп тора иде. Атны чыгаргач, шалт бикләп куйдым. Ачкычларны шунда, нигез буена ыргыттым... «Бикле ишектән дә Шәкүр карак атны алып чыга!»— дип сөйлиләрме?.. Юк сүз ул! Юк сүз...

Сөйләгәннәренең шушы кадәресеннән вакыйганың ничек булганлыгы аңлашыла иде. Шаһимәрданның җөпле хәбәрне бик алай ук ваклап тыңлыйсы килмәде, әллә күңеленә борчу иңеп, сабырын югалттымы:

— Артыңнан бастырып килдек, авылга кердең, чыкмадың? Туздырмаган җир калмады, бәрәңге бакчаларына кадәр һәммәсен казып-болгатып чыгучылар булды. Айгыр табылмады. Кайда иде? — дип, Шәкүр каракка күзен дүрт итеп төбәде.

— Бер дә әллә кайда түгел иде,— диде аңа җавабында һаман да тыныч Шәкүр.— Тирес астына тыктык без аны. Тирес астына!.. Чаптырып кайткан мәлгә арбага салып китердек тә аякларын-башын бәйләп күмдек тә куйдык. Ә тирес өстенә орлык сиптек. Таптылар инде, диген идем дә, һичкемнең башына килмәде. Ә тавыклар, шул орлыкларны җыеп, рәхәтләнеп тибенеп йөрделәр. Менә шулай булды эш. Тирес астында атка бернинди зыян юк, яхшырып кына китә ул!

— Әйтәм ул тавыклар рәхәтләнеп тибенәдер иде,— Шаһимәрдан үзенең ахмаклыгына үзе үк хәйран калды. Моңа кадәр күпме мал күреп, дөнья белән шаярып һәм уңын-сулын болгатып яшәгәндә дә, бүтәннәрнең ахмаклыкларыннан көлеп йөреп тә, үзенең шундый ук ахмаклар рәтеннән булганлыгын тануы аңа җиңел түгел иде. Әмма монда да ул үзендә көч тапты: — Адәм көлкесе!..

— Ярар, вәгъдә — иман! Үпкәләштән булмасын, Шаһимәрдан, очрашырга язсын! — Шәкүр карак аның өстәлгә салган мең сумлык акчасын алды да, кесәсенә бөтәрләп тыгып, артына да борылып карамыйча чыгып китте. Аның җиңел һәм йомшак адымнары бу ирнең кемлегенә бер дә бәрабәр түгел сыман иде. Ул авыр басып, кукраеп йөрергә тиештер дә, әмма бераз бөкрәеп, каранып кына атлавы бик затлы тәкъва картларны хәтерләткәнлектән, һичкемнең игътибарын җәлеп итмәде.

Шаһимәрданның исенә теге күп сүзле Минзәлә бае Мөхәммәтҗан килде. Нигәдер аны күрергә уйлады.

— Минзәләгә кәрван җиктерергә!..— дип, үзалдына әйтеп куйды. Бу аның үз-үзенә әмере кебек иде. Һәм ул шулай эшләр дә!

Шаһимәрданның монда озаклап, кайберәүләр кебек калгып утырырга исәбендә юк иде. Өстәлдәге ризыклардан кайсыларын юл азыгы өчен үзе белән җыеп алды да китеп барды. Казанда эше беткән, гүяки уңы-сулы тигезләнгән, күңел борчулары сүнгән кебек иде. Һичкемгә күтәрелеп карамыйча, атын җиңел генә йөгертеп барды. Көннең кичкә авышуы да аны ашыктырырга тиеш иде. Әмма моңа исе дә китмәде. Казанны чыккач, күңеле моңланып, бераз җыр сузды. Дәрвишләр бистәсеннән соң, юл чатланып киткән урында күңеленә кайнарлык иңеп, «аһ» авазын чыгарды һәм, арбасыннан төшеп, җиргә ятып елады да елады. Бу вакытта хәтере саташкан идеме, әллә дөньялык аның барлыгын бер мәлгә онытып тордымы, һични уйламас хәлендә шактый озак ятты. Аны йокы да алмады, күңеле генә, чиксез галәмнең бушлыгында адашып йөргән шикелле, һаман да утырып җитмәде...

Гомернең узулары берни түгел, хәере белән үтсен! Әмма җан тынычлыгын югалту бик хәтәр нәрсә икән ул. Аны эш белән, мәшәкать тартып та җаена китереп булмый.

Шаһимәрдан башын күтәреп карады. Инде төн узган, таң аткан, кояш күтәрелеп бара иде. Аты юл читеннән үлән чемченә, ерактан кемдер шашынып һәм ашкынып чаптыра, бу якка таба дуамал тизлектә ки-

леп маташа иде. Ни хикмәтле хәл бу, дип, Шаһимәрдан шул тарафка карап торды. Килүче, тизлеген арттыра төшеп, узып та китте. Аты ак күбеккә баткан, барча тәгәрмәчләре уңлы-суллы чөелә, арбадагы адәме, аягүрә баскан килеш, дилбегә башын туктаусыз болгый иде. Бу хәл Шаһимәрданны нигәдер гаҗәпләндермәде, киресенчә, бары тик тынычландырды, җаен җаена кайтарды. Ул өркеп читкә тартылган атын юлга чыгарды да каударланмый гына китеп барды.

Әлегә Шаһимәрдан килер көннәре хакында: байлыгыннан тәмам коры калып, йорты-җире хәтәр янгыннан харап булачагын, ахырда Казанга килеп урнашачагын, гомеренең соңгы көннәрен данлыклы сәгатьче сыйфатында уздырачагын белми иде. Әгәр дә белсә, егыласы урынына бу юлы салам җәеп куячак ул, билләһи!

Инде генә тернәкләнеп киттем дигәнендә, Октябрь инкыйлабы чыгып, әле чехлардан, әле кызыллардан җәберләр күргәч, НЭП вакытлары ирешеп, кабат беренче байлар хисабына керәчәген дә күз алдына китерә алмый иде хәзергә. Күрәчәген кеше каян белсен ди инде! Узганнар хакында искә алуы гына да бик алай ук җиңел түгел, сабакларын искәреп, киләчәккә өмет баглыйбыз да — һаман ялгышабыз...

Ә, әйе, Шаһимәрданның НЭП чорында байлыкка ирешүе, яшереп торасы түгел, Шәкүр карак белән бәйле булды. Әмма ул аны һичкемгә белдермәде. Ул вакытта хатыны — тугрылыклы җан гүр иясе иде инде. Үзенең яшьрәкне чамалап йөргән чаклары...

Вакыйгаларның дәвамын төгәлрәк итеп минем дә беләсем килә, тик аларны тәфсилләп аңлатыр кеше табылмады. Хәер, бәлки, алай әһәмиятле дә түгелләрдер, мөгаен. Дөнья һаман үз җае белән бара бирә. Кешеләрнең нindиләре генә тумый да, эз калдырып үтми. Әмма, еллар узган саен, заманалар күчә, үзгәрә тора. Тарихта шан һәм дан белән яшәп киткән шәхесләрнең дә хәтер сандыкларыбызда сакланган төсләре уңа, бетә. Шәкүр карак хакында да әллә никадәр вакыйгалар ишеткәнем, хәтта театрларда караганым, китапларда укыганым бар... Әмма...

Ат урлауда, ат карагы булудамыни хикмәт! Ат урлауның ние бар! Ә менә кеше булып калуның серләрен язып, сөйләп, аңлатып, төшенеп һәм төшендереп бетерергә мөмкинме?

*Октябрь, 1998 — июнь, 1999*

# Ак Ай буендагы кич

Матур көннәрнең берсе иде, ялгызым гына балыкка киттем. Өйдә хатыным, балаларым, һәр сүзендә йомшаклык һәм хөрмәт-ихтирам таптыра торган әби калды. Юлым шактый ерак булып, Казанны ташлап чыккач та ике сәгатьләп барып, әллә кайчан кызыгып йөргән Ак Ай күленә җиттем. Мондагы балыкның аз түгеллегенә иманым камил генә түгел, алдан белешеп, бер бәрәкәтле сәфәрем вакытында хәтта төнлә дә чыра яндырмыйча күрә торган очлы күзләрем белән шаһит булган идем. Бары тик җәтмә салып сөзмәсәләр генә ярар иде. Ни дисәң дә, үз күлләре шул, «Алга барыш» күмхуҗының шәхси милеге, аларның дәүләт белән бүлешми, аны-моны белдерми генә баеп яту чыганагы. Рәисләре Хуҗин Зариф Әлмөхетдин улы — Олы Әвен— шушы күлне көзлектә һәм җәйлектә сөздереп, балыгын анда-монда ярты бәясенә генә озатып, акчасын учлап кесәсенә тутыра да, Анталиягә, ягъни без күреп белмәгән Төркиягә китеп бара. Артыннан бөтен күмхуҗлары белән елга бишенче мәртәбә: «Хәерле юл!»— дип куллар болгап озата калалар да, ул күздән югалуга, рәхәтләнеп бәйрәм итәргә, туйлашырга тотыналар. Һәммәсен бәхет баса. Дөньялары түгәрәкләнеп китә. Ә Олы Әвен хикмәтле Мәрмәрә диңгезе буендагы, әллә тагын да арырак җирләрдәме таралып-бүселеп ятканда, авыл халкы да иркенәеп-матураеп һәм шул ук вакытта таркалып китәргә өлгерә. Юк-юк, сез нәрсә, Олы Әвеннәре бер дә начар кеше түгел, тик менә ике төрле авыр чире генә бар. Берсе — күмхуҗдагы колларына тамчылатып кына булса да акча түләми, хезмәт хакын бирергә дә җыенмый, икенчесе — гелән өянәге кузгалып тора, тиктомалдан сугыша-кыйнаша башлый. Хатыны әйтә, имештер, күп эчүеннән шулай. Айнык чагында бер дә алай түгел, ди. Шулайдыр инде, ялган сөйләп тормас.

Мин беләм, бу көннәрне аларның Олы Әвене һичничек ялга китә алмый, ил башлыгыбыз авыл һәм районнар буйлап сәяхәткә чыкканын бер атна буена радио-телевизордан такылдыйлар, гәзитләр олы-олы сәхифәләрен аллы-артлы тутырып язалар, мул иген кырларында йөзеп йөргән сурәтләрен бастыралар. Зариф Әлмөхетдинович аның янында, алгы рәтләрнең берсендә ияреп йөри булыр. Димәк, балык сөзелмәгән, күл буенда һичкем юк. Кармагыңны сал да чүпләп кенә утыр.

Ак Айның биш ягы да әрәмәлек, урман һәм агачлык иде. Машинамны сөзәк яр буена ук китереп туктатырга теләмәдем. Суны пычратуы бар. Килеп җитүгә, учак ягып, кармакларны суга ташладым да, беренче өч балыктан шулпа пешерергә ниятләп, әрәмә ышыгындагы машинаның радиосыннан музыка җибәрдем. Концерты шәп иде.

Оҗмах, егетләр! Чын оҗмах. Әнә балыклары да мине генә көткәннәр, калкавычларны йөгертеп тә тормыйлар, селкетер-селкетмәс җәһәт кенә төпкә алып китәләр. Чиләк түгел, капчык белән килергә кирәк булган.

Учакка утыртылган чиләгем кайнап чыгуга, тәм өчен аны-моны, яфрак һәм үлән ише белән бергә бәрәңгене дә салып, әле яңа гына тоткан балыкларның өчесен чистарттым, аларны шулпага чумдыруыма биш минут та үтмәгәндер, яныма «УАЗ» машинасы килеп туктады. Көтелмәгәнрәк кунак.

Машинадан чыккан кеше миңа яхшы таныш иде:

— У-у, Хафизов,— диде ул, исемемне әйтеп тормастан исәнләшеп,— син дә мондамыни?

Мин як-ягыма каранып алдым:

— Әллә тагын кем дә мондамы?

— Кем? — диде Насыйри, минем кебек үк карангалап.

— «Син дә мондамыни?» дигәнегезгә әйтәм.

Насыйри җайсызланды, күгәренде, өшенде. Зур түрәләрдән булуын исемә төшерергә азаплана идеме, кукраеп алды да:

— Мине кешегә санамыйсың инде, ә? — дип әйтеп куйды.

Иренсез булып та иреннәре турсайган иде.

— Әле килдегез генә түгелме? — Мин акланырга мәҗбүр идем.— Гафу итегез инде, Насыйри әфәнде...

— Ярар, бер юлга! — Ул хәзер канәгать иде.

Шунда тагын бер машина күренде, Татар мәзәге кушаматы белән танылган «Ока» машинасы иде бу. Эченнән чыккан кешесе озын торыклы, кара мыеклы, яшенә күрә ак йөгерергә уйлап та карамаган калын кара чәчле, саесканныкыдай борынына эленгән алтын кысалы күзлектән Дәвис әфәнде иде. Аның көн дә иртәдән кичкә кадәр сөйләнүче бер иҗат коллективында зур түрә булып эшләве, әмма белеме белән ул урынга якын да килергә тиеш түгеллеге һәркемгә диярлек мәгълүм булганлыктан, дәрәҗәсе дә мактап телгә алынырлык ук булмыйча, күркәмлеге белән исә, Ходай рәхмәте, үзеннән өстәгеләрнең хатыннарына бик ярый, диләр.

«Ока»сыннан чыгуына, аның гәүдәсенә бәрабәр машинасы бөтенләй дә кечерәеп, кызыл кандала кадәрле генә калганлыгын шәйләми мөмкин түгел иде. Мин көлемсерәргә мәҗбүр инде.

— Балык тотып буламы? — диде ул, шулпа исен тоеп, борынын җыера-җыера.

Безнең хакта үзара танышлар, диярлек үк түгел иде. Юлларыбыз бергә туры килгәндә дә, ул кул биреп тормый. Күр әле аны, югыйсә исемемне дә белә икән, фамилиямне дә.

Учактан чиләкне читкә алып:

— Сез килү хөрмәтенә, җәмәгать, шулпа әзер! — дип, аларны әлегә хәстәрлек ителеп бетелергә өлгермәгән табыным янына дәштем. Алар, әзергә-бәзер өйрәнгән ике түрә, бик теләп ризалыкларын бирделәр. Минем каты-коты гына булып күренгән өстәлне шунда ук киңәйтеп һәм мулландырып җибәрделәр. Уртага икесе дә олы шешәле берәр «Абсолют» аракысын чыгарып утырттылар.

— Сыйлыйк әле үзеңне хәзер,— дип мактанырга тотынды Насыйри.

— Екканчы! — дип өстәп куйды Дәвисе.

Насыйриның кечкенә гәүдәсеннән үсеп чыккан нечкә һәм озын муенына утыртылган гаҗәеп олы күренгән шакмаклы башына, чәпәлеп кенә ясалган йөзенә төртке-төртке итеп куелган күзләре, мәгънә эзләгәндәй, сынап карап куйдылар. Җеп белән сызылгандай тоелган авызында иреннәре бөтенләй дә юк дип белә идем, турсайтканындагы кебек, елмайганында да бераз күренәләр икән. Бу хәлгә игътибар итүемне белмичә, үзенчә уйлап, ахрысы:

— Бездән качып ята алмадыңмы? — дип куанып куйды ул.

Мин балык шулпасын бүлгән арада, алар аракыларына ябыштылар. Көннең кичкә авышуы, җиңелчә генә җылы җил исеп куюы вакытның матур һәм күркәм үтәчәгенә бер яхшы фал кебек иде. Шулпа тәменнән мин аларның иреннәре суланганын, шуңа күрә тел очлары белән аны ялаштыралардыр, дип уйлаган идем, ялгышканмын. Аракылары бүленүгә, каршыма бер стакан тутырып утырттылар да:

— Калдырып тор! Тот моны! — дип әмер иттеләр.

Икесе дә олы урында эшләгәннәре сәбәпле, минем ишеләр алар өчен санга керерлек түгел иде югыйсә. Ул кадәресен яхшы аңладым. Мәгәре дә гадәтемчә баш тартсам, моны үзләрен кимсетүгә санаячаклар.

Ике ут арасында озак калырга ярамый иде. Тизрәк бер фикергә килеп, яки аларның фәрманына буйсынырга, яисә үзем булып калырга тиешмен!

Мин икенчесен сайладым.

Алар:

— Син нәрсә? — дип аптырап калгандай булдылар. Әмма бераздан, тагын да батыраеп: — Кешегә санаган идек. Сине хөрмәткә алып сыйламакчы идек. Безне санга да алмыйсың икән! — диделәр.

— Ярар! — дидем, бүтән чарам калмагач.— Шулпаны бүлеп бетерим инде.

— Күпме күтәргә була! — Сабырлыклары күңел алачыкларыннан чыгып китеп маташа иде.

Шулпаны китерүгә, савытларны чәкештердек. Мин, алар күтәргән арада, стаканны кире куйдым. Дөрес, түгәргә дә, хәтта эчәргә дә мөмкин идем. Болар, күреп алуга:

— Әйдә-әйдә, син нәрсә! — дип, тагын да фәрманнарын башыма күсәк урынына тондырырга тотындылар. Ахырда: — Безне генә исертеп, кызык итмәкче! — диделәр.

Бу сүзләреннән соң, киресенчә, мин кимсенергә һәм үпкәләргә тиеш идем. Әмма алай ук мескенгә каласым килмәде, юктан сәбәп табып:

— Егетләр, йөрәк начар, бик авырта...— дип угаланып зарландым, акланунын җаен эзләдем.

Алар мине аңларга тиеш иделәр кебек. Әмма колакларына да элмәделәр:

— Юкны сөйләмә! Синекедәй йөрәк бездә булса әле! — дип, кабат үгетләргә һәм ачуланырга тотындылар. Ахырда, үпкәләп, мыскыллап, икенче һәм өченчене дә күтәрделәр дә барлыгымны ук оныттылар. Мин кармакларымны караштырып килергә иттем дә үзләрен генә табын түрендә калдырып киттем.

...Күккә йолдызлар калкып, инде шактый соң булганлыктан, учак янына әйләнеп килсәм, боларның икесенең дә «булулары» җиткән, берсе утта аркасын җылытып ята, икенчесе машинасы тирәсендә кайнаша, аякларында тора алмыйча, әле артка, әле янга чайкала иде. Балыклы чиләгемне куаклар арасынарак куеп, кармакларымның бүселеп чуалмаганмы-юкмы икәнлекләрен тикшердем дә, йокы өчен алып килгән, агач төбенә салган әйберләрем янына барып, балыкчы әсбапларымны тал кәүсәсенә терәтеп куйдым. Кыек саплысы авып-авып тинтерәткәч, анысын яткырмакчы идем дә, өстенә басып сындырырлар йә дип, сап башы белән җиргә кададым. Ул вакытта Дәвис һаман машинасы янында кайнашадыр кебек иде, салонына кереп, руль артына ук утырган икән, кабызып җибәрде. Җылытыр да йоклар дисәм, ул йөртеп үк китте.

Аның юлны күрүенә шигем юк иде, ә ул, машинасын үкертеп, туп-туры минем өскә таба килә башлады. Читкә чак тәгәрәп өлгердем. Һәм бу, кармак сапларын сындырып, урын-җирләремнең измәсен китереп, агачка барып сыланды.

— Булдырды! — дияргә өлгермәдем, «Ока»сын кабат артка бирде дә, минем «Жигули»ның яныннан гына узып, Насыйриның «УАЗ»ына барып сыланды. Болай да кечкенә «Ока»сы бөтенләй дә коймакка әверелеп калды. Инде дә тынычланды дисәм, йокысыннан сикереп торган Насыйриның артыннан чаптыра башлады. Дәвиснең шашканлыгын уйларлык урын юк түгел иде.

— Хафизов, туктат, таптый бит!..

Тавышын кызганмыйча үкерүче Насыйри, күл буен чаң каккандай шаулатып, кая керер тишек таба алмыйча, уңга-сулга чаба бирде.

— Хафизов, туктат бу юләрне!..

Мин аны-моны уйларга өлгергәнче, Дәвис, «Ока»сын үкертә-үкертә, һаман да Насыйрины куалый, бергә эчкәннәренең бар рәхәтен чыгара иде. Чыннан да, ул яки шашкан, яисә нишләгәнен белмәслек дәрәҗәдә исергән. Шик юк. Әмма бу юләрне ничек туктатырга?

«Ока»дагы Дәвис өркенгән Насыйрины һаман да җан-фәрманга акыртып куа бирде, ә мин аның артыннан йөгердем. Каешы ычкындырылган чалбарым теземә кадәр төшеп, аны күтәрергә өлгермичә, комга башым белән барып кадалдым. Муеным сынды дип торам. Җитмәсә, телемне дә тешләгәнмен. Әле чалбарны тиздән күтәрергә, әле башны ком эченнән чыгарырга тырышып чәбәләндем. Башы-койрыгы сумалага ябышкан саескан кебек, ни дә эшли алмый җәфаландым.

Ахырда тырышлыкның нәтиҗәсе булган кебек, мин дә тәки аякларыма бастым. Дәвис «Ока»сында һаман да Насыйрины куалый, инде өченче «круг»ка киткән иделәр. Тагын аларның артыннан йөгердем. Ялан аягым, ташларга-шешәләргә, агач ботагы, тамыры һәм төпләре ише нәрсәләргә бәрелеп, кадалып, чәнчелеп бетте.

— Үтерә, Хафизов, коткар! — дип кычкырынган һәм йөгерүдән туктамаган, кая керергә тишек таба алмаган Насыйрига: «Суга чум, суга!» — дип әйтергә өлгермәдем, сүземне кабул итеп, күлгә сикерде.

Әмма «Ока» да аның артыннан чумды...

Дәвисне тартып чыгарганда, инде гырлап йоклый, дөньялыкның рәхәтенә чумган иде. Ә аның хакында безнең кайгыруларны, әллә үлгәнме, дип котларыбыз очканны белеп тә бирмәде. Булса да булыр икән адәм баласы!

Урын ясап, үзен шунда йокларга салдык. Киемнәрен сыгып, кабат тергезелгән учак янына киптерергә элдек. Ак яка, кара костюм, галстук! Шәп егетләр шундый була инде алар. Килгәнендә гади генә киенгән төсле иде, кайчан алыштырып өлгергәндер, Ходай белсен!..

Иртәгесен боларның башлары «икегә ярылган» иде. Шунда ук «төзәтергә», ике яртыны, бергә кушып, бөтен итәргә утырдылар. Мин болай да төне буе аларны саклап чыкканлыгым сәбәпле, йөзләрен дә күрә-

сем килми, ялымның түмен бетерүләре өчен үпкәдә идем. Төнлә булган хәлләрне дә исләренә төшереп газапламадым. Үзләре дә бик яхшы беләләрдер, ахмак малайлар түгел!

Дәвис үзенең кипшергән киемнәрен киеп алды. Тагын да берне күтәрүләренә:

— Егетләр, минем машина кая? Саттыгызмы әллә? — дип сорап куймасынмы.

— Балык тота,— дидем мин дә, исем китмичә генә.

— Ягез, егетләр! — Сүзләремне Дәвис шаярту дип кабул иткән иде булса кирәк.— Машинам кая?

— Балык тота,— дидем һаман да бик җитди кыяфәтемдә.— Күл төбендә!

Насыйри гына бер сүз дә эндәшмәде. Түрәләр арасында кайнашып, агына да, күгенә дә ярап, кешелеккә өйрәнеп беткән, чукынчык. Ник бер кәлимә, тел очына керерлекне генә булса да әйтсен.

Ә Дәвис гаепне миннән күрә башлады.

— Шаяртма, егет,— дигән була әле, җитмәсә.— Булыр күл төбендә... Шаяртма!

— Әллә кичәге хәлләреңне оныттың? — дидем ачу белән.—Ниләр кыланганыңны?

Ул түрә булса да, мин сездән сингә әллә кайчан күчкән идем инде. Аның моны ошатмаячагын күңел белән сизендем, әмма тел айгыры кысан аранында уйнаклый, сүзләр тезмәсен тешләрнең ачык ишегеннән тибеп кенә очыра бирде. Ахырда:

— Насыйри, ни карап торасың, әйт үзенә! — дидем, сынган кармак сапларын күтәреп күрсәтеп.— Боларның ни гаебе бар иде?

Шунда ничектер кинәт кенә күңел тынычланды. Шым булып калдым. Насыйриның сүзсез торуына артыгы белән хәйран итеп, ачуым кабарудан узып, шешеп шартлар хәленнән кинәт шиңгән, үзем зураеп кабартылып та тыны чыгып беткән куык кебек шәлперәеп төшкән идем. Дәвиснең миңа карап-карап куюы һәм, җитмәсә, берни булмагандай елмаюы тәмам аптырашта калдырды. Кичә дөнья яңгыратып үкереп елап йөгерә-йөгерә ярдәм сораган Насыйриның бүген каршымда телсез торуы, ни уңнан һәм ни сулдан сүз кузгатмавы бик тә хәерсезлек галәмәте кебек тоелды. Әллә соң мин үзем саташканмынмы? Әллә соң боларның берсе дә булмадымы? Алай дисәң, Дәвиснең «Ока»сы су төбендә. Әллә болар, киңәшеп, бер-бер хәйлә уйлаганнармы? Булырга мөмкин, бик мөмкин!

Шул уем мине «каенга» китереп терәде. Йөрәкне жу итеп кайгы биләп алды. Әгәр дә машинасын суга салып, бу алдан уйланылган эшләре булып, гаепне өстемә өеп калдырырга ниятләсәләр? Баш-аягың белән «тиреслек»кә кертеп чумдырачаклар, комга гына кадалып калмассың.

Кичке ак айлы күл буендагы вакыйгалар, хәтеремнән эреп югалырга теләпме, берсе икенчесен алыштырып, күз алдымнан кабат уздылар. Түрәләрне белмәссең, барысы да алдан уйланылган, барысы да шулай булырга тиеш итеп эшләнелгән кыяфәт чыгаруларының сәбәпсез генә булмавы да мөмкин.

— Балыкка барам, ял итеп кайтам! — дигәнемдә хатын да каршы килмәгән иде югыйсә, хәтта:

— Бар, картым, бар... Бераз җилләнеп кайт,— дип, хәерле юллар теләп озатып ук калган иде. Нинди кара мәче аркылы чыкты да, кайсы авыр аяклысы очрады икән?

Ялымның һичбер яме һәм тынычлыгы калмады. «Түрәләрне мондый вакытта арага кертәләрмени?»— дип ачуландым, тиргәдем, салып таптардай булдым үземне. Хәер, бу эшне миннән башка да хәл кылучылар табылды. Дәвис белән Насыйриның һәр сүзе, һәр карашы җанны кыйный, эчемдәге барны һәм юкны айкап, канатып, укшытып чыгара, аларның төрткеле сүзләре аяклардан-куллардан зәңгәр күк йөзенә кадаклап куйгандай иде. Имеш, менә хәзер бу ике вәхши учакка тагын да агач өстәрләр, телләрен ялап куярлар һәм мине тереләтә шуның ялкыны өстендә кыздырырга тотынырлар. И хайваннар!..

Бераз тынычланырга кирәк иде. Әйткәләшүдән соң кабарып киткән мунчаксыз хыял бозавы, акыл басуларын таптап-изеп, фикер болынымда чабып йөри. Аны ничек тә тыярга кирәк! Юкса бер уй артыннан икенчесе кузгалып, төзек мантыйк рәвешенә киләчәк, һәм мин дә реаль тормышка түгел, фантазиям белән тудырган хыялый хакыйкатькә ышана башлаячак идем.

Шунда Насыйри бар уйларымны юкка чыгарып әйтте дә куйды:

— Хафизов дөресен сөйли!

Дәвис усал итеп миңа текәлде. Гүяки ул төне буе юләр сатмаган да, безне аптыратып җанга тимәгән, имеш.

— Шулай да, егетләр...— диде дә Дәвис, болай да зур авызын торба итеп ачып, хихылдый башлады.— Шулай да, егетләр...

Аның ни өчен көлүен мин аңламадым, Насыйри да телсез кала бирде. Дәвис һаман көлүендә булды. Аның авызы колагына җитеп, ияге өзелеп-өзелеп төшкәндәй тоелды, мыегы сирәк озын кашы белән кушылып бетте. Бераз тынычланганын көттек.

— Шулай да, егетләр,— диде ул һәм, тагын да бераз көлгәч,— минем машинаны кая яшердегез соң? Әллә сатып ук җибәрдегезме?

Мин һични эндәшмәдем. Ачуым килү чиктән ашкан, авызымны ачсам, тел аждаһасы ирек алып, Дәвисне буып ташлаячак иде. Аннан соң, алдан әйтеп ташлап, тагын бер утны үз өстемә алырга мөмкин идем, шымыттым. Насыйри, акыллы баш, минем сүзне күтте. Вакытым күплектән ашыгырга исемдә дә юк иде. Аннары, алар икесе, аерым машиналарда булсалар да, бергә килделәр, хәлләрен дә, минемчә, үзләре үк башкарып чыксыннар, ягъни чукынышып китсеннәр!

— Ярар, шаяртмагыз инде, китәргә вакыт!

— Салган көеме? — Сүзләрем үз җайлары белән чыктылар, аларны тешләрем тоткынында калдыра алмадым.

— Алай гына,— диде Дәвис, әйткәнемә шунда ук җавап биреп,— мулла кызында да була! Закон ул кешесенә карап, кешесенә!

Аның миңа төбәп әйтүе күрәләтә мыскыллавы иде. «Ока»сының үчен алырга җыенганлыгын аңладым, тагын да эндәшми калырга булдым.

— Чүп басты дөньяны,— дип мыгырданды ул.— Әрсезлекләрен әйткән дә юк! Чүп шулай инде, әрсез була. Йолкып торасың, калкып чыга... Утыртканны үстерми!

Аның кискен йөреп сөйләве, кулларын әле югары күтәрүе, әле ботларына чабуы яки юләрләнүеннән, яисә мин кемлегеннән иде.

Дәвис кинәт туктап калды. Күлгә карап торган җиреннән борылмыйча гына:

— Насыйри, кил әле монда! — дип, аны үзенә дәште.

Тегесе дә хәйләкәр шул.

— Нәрсә булды? — дип, янына барып басты.— Ни бар анда?

Мин дә якынайдым. Күл төбендәге «Ока»сын күреп алуына шигем юк иде. Аның, бармагы белән төртеп:

— Бу нәрсә? — дигән җирендә кадерле машинасы иде.

— Бу нәрсә? — диде ул тагын да.

Мин эндәшмәдем. Насыйри җавап бирергә мәҗбүр булды:

— «Ока»ң?!

Алар бер-берсенә карашып куйдылар һәм, ике калай әтәч кебек, калкышып, якалашып кычкырышырга тотындылар.

— Үзең тыктың, суга үзең керттең! — дип җикеренде Насыйри.

— Син нәрсә, мине ахмакка саныйсыңмы әллә? — диде кызарып бүртенгән Дәвис.

— Минем машинаны кара, аңа кем бәрде? — диде шунда ук Насыйри.

— Синең «УАЗ»ың — казнаныкы, аңа ни пычагым булсын! — Дәвис аны якалаган хәлдә селки, гайрәтләнеп күтәреп-күтәреп куя иде. Араларына кермәдем.

— Таптап үтерә яздың! — дип җикерде Насыйри, буыла-буыла.

— Бер карак кимрәк булыр иде,— диде Дәвис, һаман да тынычлана алмыйча.

— Үзеңне бел! — дип акланды Насыйри.

Мин һаман араларына кермәдем. Инде машинасын күл төбеннән чыгарырга вакыт җиткән иде. Аркан китереп, суык суга кердем. Аларның икесеннән берсе аякларын да чылатмаячак иделәр. Насыйриның «УАЗ»ы белән сөйрәтеп чыгардык. «Ока» суга чумган тавык шикелле иде. Дәвис аны биш әйләнде, башынйөзен тотты. Ишеген ачып җибәрүгә, өстенә су агып төште. Әмма бу юлы ул сүзсез иде.

— Зыян юк,— дигән булды Насыйри,— тагып кайтабыз да Юныс абзыйга илтеп куябыз. Бер айга эшкә алырсың үзен. Бәлки, күбрәккә... Машинаңны өр-яңа итеп бирер. Кулы — алтын!

— Һәм шулай! — дип, аның җилкәсенә сукты Дәвис.

Әле бая гына калай әтәч кебек бер-берсенә ташланган ике түрә кабат җан дусларга әверелделәр.

Киткән чакларында кулларын минем балыкларга суздылар да:

— Син боларны безгә бир, үзеңә тагын тотарсың, монда балык — мүре! — диделәр.

Каршы килмәдем.

Алар киткәч, кармакларымны җайлап, яр кырыена төшеп утырдым. Әмма бер балык та тота алмадым. Хәтта чиртеп тә карамады...

Икенче көнне хатын, эшеннән кайтуга:

— Насыйриның хатыны мактанып туймады. Дәвис белән балыкка барганнар икән, берәр чиләк тотып кайтканнар,— дип кат-кат сөйләде.

Мин, үземне уңмаганга һәм булмаганга чыгаруларына карамастан, һични әйтмәдем, бары тик:

— Дәвиснең машинасы ни хәлдә икән? — дип сорап куйдым.

— Ә нигә? — диде ул.— Хатынын «Волга»да килеп алды.

— «Ока»да йөри иде түгелме соң?

— Сатканнар инде, яңа «Волга» алганнар. Булса да булыр икән уңган кешеләр...

— Әйе, булса да булыр икән!

Бүтәнчә аны-моны сөйләшмәдек. Хәер, артык сүзнең мәгънәсе булыр идеме икән?

Шушы вакыйгадан соң Ак Ай ярына бер дә аяк басмадым. Ул күлгә барсам, тагын Дәвис белән Насыйри килеп чыгар да балыкларыма кадәр алып китәрләр кебек тоела иде.

Ә бервакыт Дәвис очрады. Сәлам бирүгә:

— Син теге юлы Ак Ай буенда кызык иттең, ә? — дип әйтмәсенме.

Аны-моны эндәшми китеп бардым. Булса да булыр икән кешеләр!

*Сентябрь—октябрь, 1998*

# Дөнья бәһасе

Дөньяның терәге көн дә кирәк була торган акча, имештер. Акчаны  су кебек, диләр, ага да бетә, бармак араларына да кысылып калмый. Әмма мин аның тагын да бер канунын беләм: акча чыкмаган җиренә керми, кермәгән урыныннан чыкмый. Аның чыга һәм керә торган ишекләре төрле булганга, чыгучысы керүчесенә, керүчесе чыгучысына комачау итми. Шунлыктан аның чыгар җирен бикләп куярга, керер ишеген ачык калдырырга мөмкин. Бу яктан һичкем Карун белән ярыша алмаган. Аның җыйган бар байлыгы һәм акчасы дөнья йөзен алтын белән каплап бетерергә җиткән, диләр. Хәтта Фиргавен дә Карун белән ярыша алмаган.

Гомер — үтүчән, ә үлем — килүчән. Монда казанган матди байлыкны анда алып китеп булмаганын борынгылар белгәннәр һәм рухи кыйммәтләрне үзләштерүнең мәгънәсе зурлыгын төшенгәннәр. Чыңгыз кебек бөтен дөньяга баш булып та, олуг ханлык һәм дәүләтләр тотып та, Сөләйман кебек бар серләрнең сәбәбен аңлап та, монда, җир йөзендә торып калырга мөмкин түгел.

Болар хакында тәфсилле сүзне сөйләргә яраткан Зарифулла хәзрәтнең абыстае Хафизаттәй ашка чакырулы иде. Кемгә диген, Казанның иң каттә бае Исхак әфәнделәргә. Имеш, машинада килеп аласылар, китереп куясылар, ди. Болай зурларга җыенгач, аш-суда гына түгел, садака-хәердә дә мул кыланырлардыр!..

Әүвәле токмачлы аш килеп, аның янына бәрәңге һәм майлы ит бирделәр. Тәлинкәләренә өеп салганнар. Коръәннең ике кечкенә һәм ун аятьтән торган бер кисәген Хафизаттәй озаклап сузып, көйдә ялгышып булса да укыганнан соң, ерак бабалардан алып туачак оныкларның балаларына кадәр җиткереп дога кылды. Аннан ары үзе дә белмәгән, әмма ишеткән һәм шулай кирәк тапкан сәетләргә, мәлик вә мәликәләргә, барча пәйгамбәрләргә атап тагын да «Сөбханәкә»не, «Әлхәм»не, «Колһуаллаһ»ны укыды. Тагын да аларга китереп һәртөрле ил башлыкларын, түрәләрен, түрдәгеләрен һәм түрдәгесезләрен ялгады да, аларның исәнлегенә дога кылып, кабаттан көннең санына, мөселманнарның иминлегенә, кяферләрнең мәрхәмәтенә атап аятьләр чыкты. Кабаттан башламакчы иде, аш суынганына ишарә итүләрен исенә төшереп, әкбәр әйтте, амин тотты. Аш янына җыелган кунаклар тәмам арып һәм алҗып беткән иделәр. Амин тотылуга, кесәләреннән сары «йөзлекләр» алгалап, Аллаһ кабул итсенгә, абыстайның канәгать калуына өметләнеп, акча өләштеләр. Моның белән генә дә бетмәде. Бирелгән садака-хәергә атап дога кылу өчен Хафизаттәй кулларын күтәрде. Барча җәмәгать, суфинәкъкаш сурәткә кереп, бәндәлек хәсрәтенә төштеләр. Аминга җиткәндә, йоклыйсы йоклап алган, елыйсы елаган, сүгеләсе сүгелгән, анысы да, монысы да булырга өлгергән иде.

Суынган ашның кадере булмый, диләр. Хафизаттәй абыстайның тәлинкәсенә кайнар шулпа өстәделәр. Ит тә калмады, бәрәңге дә. Аннан соң өстәлгә бәлеш китерделәр. «Борынгылар төбен мактыйлар!»дип, Хафизаттәй монысында да алдатмады. Бәлешне җиңүгә, Аллаһыга тапшырып, гөбәдиягә тотындылар. Ашказанына җиңелгә килә диярәк, каклы чәй китерелде. Аннан соң авыз тәменә атап какланган каз чыкты. Аны да тәмамлауга, вак бәлеш китерделәр. Кайнар шулпаны эчеп җибәргәндә, яхшы була иде, анысын да бирделәр. Ул арада итле пәрәмәчләр өлгереп, аларга куе сары каймак сала-сала, борычын-тозын мактап ашагач, тамак ялына җимешле чәй чыгарылды. Абыстай сөт өстәтеп, өчне эчкәннән соң:

— Кыстыбыйны китерергәме? — дип рөхсәт сорауларына каршы, әүвәле сарык ите булганда, яхшы икәнлеген белдерүгә:

— Кайсы якта ничек инде,— дия-дия, алма белән җимешләр салып тутырылган дәү тавыклар чыкты.

Моннан соң кыстыбыйга урын калмаслыгын юкка фараз иткәннәр икән. Майда гына пешкән ризыктан кем өстен булсын ди инде? Бармакларын өммәтчә ялап, «Бәракаллаһ!» белән кикереп, инде менә хәзер балга-майга чират җиткәнлеге беленде. Чәкчәк, бавырсак, кәрәзле бал, кала конфеты, тартмалысы һәм чикмәнлесе, әчесе һәм төчесе белән бишәр чынаяк һинд чәе сөтсез генә эчелде. Инде дә дога кылынды, ризыкка рәхмәт әйтелде, Аллаһыга «хәмде» укылды. Шунда хуҗабикә, нәкъ вакытын белеп, «Татарстан

торты»н чыгарды. Аны өлешләп, тагын икешәр чынаяк чәй эчелде. Күркәм гадәт буларак, Хафизаттәй абыстай күчтәнәчкә төенчек төйнәтергә яулык чыгарды.

— Әле үткән җомгада Камалиләрдә булган ием, сөякле ит, каткан торт, бөрешкән алма тыгып җибәргәннәр. Хәдисендә пәйгамбәребез әйткән, ашның күчтәнәче, дигән, ашның үзеннән өстен булыр, дигән, әйе, балакайлар! — диярәк сөйләнеп алды.

Кеше ишетеп-күреп белмәгән әллә ниткән Камалинең хурлануыннан соң хуҗабикәнең дә оятлы буласы килмәде. Иң татлысын һәм яхшысын ашъяулыкка мул итеп тутырды. Үзен олы бер тау ясады. Хәер, Камалетдин дигәнен Хафизаттәй абыстай үзе дә белми, әллә бар ул, әллә юк. Җамалидерме, бөтенләй дә Гыйльметдинме, андамыни хикмәт! Әйтелгән дә бетелгән инде.

Тагын да озаклап ике-өч вак сүрә, аларга ияртеп озын һәм ахыры-башы югалырлык дога-фәләннәр укылып, илгә-йортка, аның хуҗаларына һәм әһеленә рәхмәтләр, озын гомерләр, сәламәтлек, иминлек, яхшылык, күркәмлек, бәхет-сәгадәт һәм тагын да әллә ниләр теләнде. Шуның белән Коръән ашы тәмам булып, абыстайны, башка әбиләр белән бергә, машиналарда гына өйләренә озаттылар. Хуҗаларның сыртыннан олы йөк төште. Сөенделәр һәм тынычландылар. Аллаһ кабуллардан итсен!..

Ә сез акча, дисез. Акча акча инде ул. Чыккан урыны кергән җире түгел. Ничек килсә, шулай китә дә бара. Кертмәсәң, исе китеп тормый, ишек шакылдатып та азапланмый.

Җәмәгать, юкка акчага кызыгасыз! Сөекле бәндәләрен Аллаһы Тәгалә бер дә буш итмәс!

Кайтып җитүгә, Хафизаттәй абыстай, кеше алдында санап утыруы яхшы булмый, дип бөгәрләп кенә тыгып-җыеп барган садака-хәерне таслап берәмләргә кереште.

— Әлхәмдулиллаһ, Аллаһы кабул итсен,— диде ул үзалдына.— Улым да сораган иде. Аңа да җитәрлек. Шул хатыннары белән чуалып кына харап булды. Үз бәясен дә бетерде, дөнья бәһасен дә белми калды...

Ул арада улы, кайтуын искәртеп, ишек төймәсенә басты. «Фәләнеңне төгән итим!» дип сүгенә башлаганчы, абыстай тизрәк ачу ягын карады.

Бер ишектән кергән акчаның икенчесеннән чыгарга әзерләнүе иде бу.

*Май, 1998*

# Маҗаралы Гыйльметдин

Хөсникамал апаның Гыйльметдин исемле малае кечкенәдән үзсүзле булып үсте. Кычыткан белән дә пешекләп карадылар, каеш-чыбыркы да «ашаттылар», әмма юньгә кермәде, тәртә ватып чапкан айгыр кебек кызу канлы иде. Орылды-бәрелде. Әмма һәр шайтанга каршы үз догасы бар, диләр түгелме? Гыйльметдиннең дә бер-бер нечкә җире булырга тиеш иде. Моны һичкем белергә өлгермәде, малай егетлек яшенә керергә җитеште. Тик аның, солдатка киткәндә, артыннан елап калучы да табылмады. Әнисе Хөсникамал апа да:

— Абыйсын да кыйный торды, әтисен дә дөмбәсләде, кайтмаса да, исем китми,— дип сөйләгәненә бөтен авыл, авыр сулап:

— Шулайдыр шул, котларын алып бетергән икән,— диделәр.

Егет котыпка, дөньяның тәмугына эләкте. Әллә ниткән атом су асты көймәсендә йөзә икән, имеш. «Казан» дип атала, ди. Хаты килеп төшүгә, Хөсникамал апа укып та тормаган. Гәзит китерүче кыз, Гыйльметдиннең сабакташы:

— Апа, алай итмәгез инде, җыртмагыз,— дигәч кенә, бераз күңеле йомшарып:

— Мә, кызым, нишләтсәң дә ярар, үзең укы,— дип, кулына тоттырган.

Шушы вакыйгадан соң авыл халкы Хөсникамал апаны ачуланып телгә ала башлады. Гыйльметдин, нәрсә дисәгез дә, алар өчен үз балалары кебек якын иде. Авылда шулай инде ул, бар да «үзләренекеләр».

Гыйльметдингә сабакташы Гөлчирә җавап язып җибәргән. Гадәт өчен, тәртип саклаптыр, күрше-күлән белән бергә әти-әнисеннән дә сәлам юллаган. Моны ишеткәч, Хөсникамал апа:

— Ул кызны күрсәм, чәчен йолкыйм әле,— дип ачуланган. Әмма кеше баласына тиярргә акылы гына юл бирмәгән.

Шуннан соң Гыйльметдинне искә алучы да, бар дип белүче дә булмады. Хезмәт срогы да үтеп китте. «Менә кайтып төшәр!»— дип тә көттеләр. Әмма ул юк иде. Гүяки дөнья йөзендә яман Хөсникамалның Әтәч Гыйльметдине Чучак елгасы буендагы Әдһәм авылында тумаган, сигезьеллык мәктәбен тәмамлап, мәҗбүри рәвештә урта белем алу өчен, тугыз чакрым ераклыктагы Ыңгырчакка барып-кайтып йөрмәгән. Дөрес, аның Хатирә Җәмиләсе белән мәхәббәт уены уйнаганнары хакында электән сүз йөри иде. Кияүгә чыкканда да, мескенем, елаган, диләр. Бер дә юкка түгел, Гыйльметдингә аталган күз яше, имештер. Мо-

ны ишеттергәч, хат ташучы Гөлчирә кеше алдында Җәмилә белән алышкан икән дә, тик якалашуга ук эшләре барып җитмәгән.

Шул вакыйгалар сәбәбеннән генә Гыйльметдин берара сүзгә кертелеп алынды, әмма дә җиткән кызлары булган ата-аналарга тагын да серләр ачылды: ул холыксызга барысының да күңелләре ятып, йөрәк түрләрендә мәхәббәтнең кызыл гөлләре кукраеп чәчәк атып ята икән шул, Аллаһ сакласын!

Монысы гына онытылган иде, сөйкемле сөякле егет хакында икенче төрле сүзләр кузгалып, аны эттән алып эткә салучылар, дуңгыз-чучкага чыгаручылар аз булмады. Бу хәлләрдән кабердәге әби-бабалары да туксан тугыз тапкыр әйләнеп кенә түгел, бөтеренгәләп ятар иделәр. Әмма ул юк-барларга исән булган әти-әнисенең һичбер исе китмәде. Чөнки Хөсникамал апа улы Гыльметдинне әрәм китеп югалганнар исемлегендә йөртте.

— Акыллы бала булса, юне булыр иде, башына җиткәннәрдер,— диде.— Бер орылып бәрелгәндер дә, суга ташлаганнардыр? Кайтып йөреп аптыратмас, иншаллаһ!

Аның «иншаллаһ»ы бу очракта артык һәм урынсыз булса да, күрше-тирә авылларда Хөсникамалның улы да су төбендә калды, балаларыбызны армия хезмәтенә бирмибез, дип, яз-көзләрен ду килеп митинглар ясап, вәкилләр сайлап, ил башына юллатып, кызыл һәм ак әләмнәр болгап йөрделәр. Хәер, бу хәлләр шулай ук Гыйльметдин өчен хәсрәтләнү түгел, үз малайларының кайгысын күтәрү генә иде. Шулай да, халыкның күңеле белән бергә, Хөсникамал апаныкы да бераз кузгалып, узышлый чәйгә тукталган карен-карендәш алдында күз яшен сыга, улын юксына торган булып китте. Ананың хисләре кузгалып, улының ни начар яклары да онытылды. Вакыйгалар чылбырында Гыйльметдинне изгегә чыгарып, фәрештәләр хисабында йөртә башлаган иделәр.

И дөньялар, диген, һаман да бер көенчә генә бармый икән ул!

Вакыт үз җаенда ашыгып, Гыйльметдиннең сабакташларыннан кайсысы өйләнеп тормыш корды, күпләре кияүгә китеп бардылар. Җәмиләнең дә бер-бер артлы кызлары туып һәм малайлары үсеп, Гөлчирә дә ару гына кешедә тормышлы булды. Бәндәдә бүтәннәрнең кайгысы димени хәзер!

Бу елларда Әдһәм авылының сигезьеллык мәктәбен дә уртага әйләндерделәр. Өлкән укытучылар да ялга китеп, яңалары килде. Батырлар һәм ил каһарманнары өлгесендә яңа буынны тәрбияләүгә алынган яшь мөгаллимәләрдән сары чәчле, зәңгәр күзле, чибәрлектә йотар өчен бер кашык суың да кирәк булмаган озын толымлысы, Хөсникамал апаларга җитмеш кереп, улы Гыйльметдин хакында белешеп, бик матур кыйсса язды. Хәтта район гәзитендә дә хикәя итеп бастырдылар. Әмма егетнең фотосурәте булмау гына эчләрен поштырды. Әллә ниткән эзтабарлар эшкә керешеп карады, сабакташларын тинтерәтеп бетерделәр. Тик мәгънә генә чыкмады. Гыйльметдиннең төс өчен сыңар сурәте дә юк иде. Ниндирәк икәнлеген сораштырып, рәссамга махсус йөкләп, бик матур бер сурәтен карандаш белән төшерттереп, Хөсникамал апага алып керделәр.

— Улыгызга охшаганмы? — дип сорадылар.

Сурәтнең биш алдына, ун артына төште анасы. Тамаша итте. Мондый да чибәр, мондый да мәһабәт «улын» күреп хәйран калды:

— Нәкъ үзе! — диде, һичбер шикләнер урын калдырмыйча.

Быел гына ике катлы итеп ак кирпечтән салдырып керелгән мәктәпнең иң зур залының иркен түренә Гыйльметдиннең ошбу сурәтен элдереп куйдылар. Купшы буяулар белән күз явын алырлык итеп ясалган иде. Җитмәсә, янына эре алтын хәрефләр белән ил батыры булганлыгын, Рәсәй президентының аңа Герой исеме биргән фәрманын да яздырып элделәр.

Бу соңгысы Әдһәм авылы халкын гына түгел, хәтта район башлыкларын да хәйран итте. Сурәте сурәт инде, ә менә фәрман белән берсе дә таныш түгел. Хәтта Хөсникамал апа да белми икән. Мөгаллимә кыз:

— Мин әле сезгә яхшы билгеле дип торам. Гәзитләрдә басылды,— дигәч кенә:

— Әйе-әйе,— дип, барысы да башларын каккалаганнар. Авылларына гына түгел, хәтта бөтен районнарына да санаулы гына килгән ул гәзитләрне хаҗәткә дә җиткерә алмауларын әйтеп тормаганнар, бичаракайлар. Сурәтен соратып, мөгаллимә кыз, хәрби комиссариаттан адресын таптырып, хәтта «Казан» атом су асты көймәсе капитаны исеменә хат та язып караган, тик җавап кына килмәгән икән.

Хөсникамал апа, кемне югалтканын, изге улына бәддога укып ялгышканын аңлагач, Аллаһы каршында ничәмә-ничә мәртәбәләр тәүбә-истигъфар кылды. Аны Гыйльметдине хакында сөйләтергә җыелыш саен чакыра, бәйрәмнәрдә түргә утырта торган булып киттеләр. Карасана, улы илгә-көнгә һаман яхшылык кылып торган икән!

Гыйльметдиннең тавыгы күркәгә, кәҗәсе сыерга әйләнде дигәндәй, һәркемнең, белгәне-белмәгәненең, теленә керсә, аның белән соклану, мактану гадәти күренеш булып китте. Ходай язгандыр, бу хәлләр шушы рәвешле кайчанга кадәр барыр иде, әмма беркөнне авылны гүяки яшен сукты, Гыйльметдин үзе кайтып төште.

Ишектән килеп керүенә, әнисе гөрселдәп идәнгә ауды, күземә күренәме, дип, әтисе авызын ачкан хәлендә телсез калды.

Энеләре-апалары кайсы-кая таралышып беткән, өйләнешеп-ярәшеп, үз оялары белән тора иделәр. Күршедә генә яшәп яткан чыбык гәүдәле олы апасының әнисеннән ипи калае сорарга дип керә барышы икән, энесенә тап булуга, чинап җибәргән. Мәгәрем шул тавышының утә миләүшә сыйфатта чыгуы гына Хөсникамал апаны айныткан, атакайларына да җанын кайтарган.

Беренче сораулары бик гади һәм гадәти булган:

— Кайда йөрдең?

— Солдатта! — дигән Гыйльметдин.— Үзегез озатып калдыгыз бит!

— Без сиңа ун ел хезмәт ит, дип әйтеп җибәрдекмени? Кайдалыгыңны чуртым да белми, монда елашып беттек!..

Шулай сөйләнеп, апасы, әнисе, әтисе һәм Гыйльметдин үзе кочаклашып үкерешкәннәр. Аны-моны аңламый һәм белми калган тирә-күрше дә кереп-нитеп аптыратмаган. Үткән-булган үпкәләүләре дә онытылган.

— Әни,— дигән Гыйльметдин,— мин өйләнеп кайткан идем...

— Кемгә? — Хөсникамал апа аптырап калган.

— Бер кызга инде...— Гыйльметдин җавабында озаклап аңлатып торырга итмәгән.

— Кыз икәнен беләбез! Кем кызына? — дип сораган әтисе.

— Яхшы кешенең кызына... Сез анысын сорамагыз,— дигән тагын да аңлатып торуны кирәк тапмаган Гыйльметдин.

— На когу-у? — дип кайнарланган апасы, энем, мөгаен, туган телен оныткан да, ни сораганны белми такылдый диярәк уйлап.

Әмма Гыйльметдин әйтер сүзендә авызын ачып калган. Дөрес сөйләшмимдер, ахрысы, болар мине аңламыйдыр диярәк аптыраган.

— Аһ, марҗа алганмы? — дип, Хөсникамал апа кулларын йодрыклаган. Әмма: «Йортка кертәсем юк!»— дияргә ашыкмаган.

— Марҗа шәп була инде ул,— дигән шунда күңеленә гайрәт төшкән әтисе.

— Ни сөйлисез? — дип чатнаган апасы.

Ахырда уртак бер фикергә килеп, бакча башында көтеп калган бу марҗа киленне өйгә дәшәргә кирәклеген барысы да җөпләп тавыш биргән.

«Киленгә беренче көннән усаллык күрсәтергә ярамый» дигән халык сүзен искә алып, тавышта каршылар булса да, анысын ук исәпкә алып тормаганнар.

Гыйльметдинне күрергә бөтен авыл халкы җыелган. Районнан да шәхсән үзен чакыртып телеграмма китерелгән. Бу кадәр хөрмәт һәм ихтирамның сәбәбен аңламый йөргән Гыйльметдинне күрергә ул арада хакимият башлыгы үз персонасы белән килеп төшкән. Хәтта ишекләрен шакып кергән. Марҗасы белән Гыйльметдин түрдә ыспай гына утыралар икән.

Геройлык орденын күрсәтүне үтенгәннәр.

— Нинди геройлык ул? — Гыйльметдин аптыраган.

— Менә, синең! — дигәннәр аңа.

— Булмаганны, каян килеп? — дип, Гыйльметдин кире каккан, исе дә китмәгән.

Шунда барысы да тавыш-гаугада бозылышып алганнар. Сары чәчле мөгаллимәне эт урынына ачуланып, Гыйльметдиннең мәктәптәге сурәтен чыгарып ташлаганнар.

— Никләр генә кайттың?! — дип офтанган әнисе.— Син югында бик әйбәт иде әле. Бозып ташладың барысын да!

Гыйльметдингә көн калмаган. Авылдан гомерендә икенче тапкыр, инде бу юлы бөтенләйгә үк чыгып киткән. Аның кайда ничек хезмәт итүеннән барысы да бихәбәр калганнар. Шулай да мәктәптән чыгарылган сурәтенең камиллектә һәм матурлыкта бик тә кайтыш икәнлеген төшенгәннәр. Гыйльметдиннең үзенә җитәме соң!

Китеп дүрт көн узуга, аны эзләп хәрби комиссариаттан чаптыртып килеп тә җиткәннәр. Хөсникамал ападан:

— Улың кая? — дип сорыйлар икән.

— Чыгып китте, Аллага шөкер, олакты,— дия икән бу сөенеп.

— Апа, нигә алай әйтәсез? — ди икән комиссар, аптыраудан күзен сөртеп.

Үпкәләгән ана яшереп тормаган:

— Герой түгел икән ул! — дип әйтеп салган.

— Нигә Герой булмасын? Менә ордены, медальләре, президентның фәрманы. Үзен хәбәрсез югалды, дип, боларын безгә җибәргәннәр, гаиләсенә тапшырырга. Ә ул исән кайткан икән. Аларның, апа, көймәләре Боз диңгезендә харап булгач, улыгыз зур батырлыклар күрсәтеп, аны коткарып калган...— дип сөйли биргән комиссар.

Аның каршында Хөсникамал апа ни әйтергә дә белмичә аптырап тора икән.

— Әмма бүтән бер очракта, хәрби бурычын үтәгәндә, агым аны чит тарафка алып киткән. Ә орден-медальләре безгә кайтты. Тапшырасы иде...

Хөсникамал апа аңа һични белән булыша алмаган. Чыгарып тондырылган барча язмаларны мәктәпкә кабат кертеп элгәннәр. Тик менә фотосын гына һаман да таба алмыйлар, ди...

Хөсникамал апа инде тәмам олыгаеп бетте. Улының орден-медальләрен үзендә саклый. Кайвакыт аларны ачып карый да:

— Ни җирләрдә йөри икән бу хәерсез бала! — дип ачулана да елап җибәрә.

Чыннан да, Гыйльметдин хәзер кайда икән? Гәзит аша да эзләтеп караганнар, милициядән дә сораткаsucceed каннар. Һаман да белүче юк, ди. Аның исемендә, фамилиясендә генә дә йөздән артык кеше яши икән, күбесенең туган елы, көне дә туры килә, тик Әдһәм авылыннан гына түгелләр. Гомумән дә ул Әдһәм авылында андый кеше тудымы икән, дип аптыраучылар да бардыр? Дөрес уйлыйлар. Кешенең кадере кем булуы белән генә шул әле ул!.. Юкка борынгылар әйтмәгәнме: «Үзеңнән кечеләргә сукма, пәйгамбәр булуы бар, өлкәннәрне рәнҗетмә, каргышы төшмәсен!»— дип.

Хаклык бар ул. Тик без аның кайдалыгын һәм ниндилеген генә белмибез. Юкса үзебез дә фәрештәләр сафына басар идек.

*1998*

# «Татар»

Язгылыкта-көзлектә дөнья сазга бата торган иде. Шунлыктан җәйнең-кышның тизрәк килүен өмет итәсең.

Дөньяны, үзегез беләсез, энәсеннән җебенә кадәр тәмам җиткереп бетереп булмый инде аны.

Ул елны җәйгелектә без, төзүчеләр бригадасы, зур гына эшкә алынып, йортлар күчерү, яңаларын салып бирү белән мәшгуль идек. Кереме дә ярыйсы гына, анда-монда җитеп бара төсле. Һәрхәлдә, ертыкны ямарга, юкны бар кылырга ярады тагын. Ил белән кубып, шаулашып Куйбышев ГЭСын төзиләр. Аның күтәрелгән суы авылларны басарга тиеш. Ашык-пошык урын күченәләр. Бөек бәла булып халыкның канын сыккан сугышның яралары төзәлеп тә җитмәгән, алга таба яшисе, чиксез бәхеткә илтүче социализм юлыннан коммунизмга барып җитәсе бар. Соңга калырга ярамый. Анда череп беткән капитализм койрыкка басып килә. Ә монда Рәсәй халкы һаман да чыра яндырып яши. Алай ярамый, кемнең кем икәнлеге, тел тегермәне ак он урынына алабута тартканы беленүе мөмкин.

Һәркемнең дә көне көнгә генә ялганып барырлык хәлдә. Безнең дә артык җир юк, кимлекне әйтерлек түгел. Әмма зарланып маташасымы соң? Җанкисәккәемне сагындым әле. Уйланып-уйланып аптырадым да, өйләнеп тә хатынны җылы кочагымнан мәхрүм итүемне төшенеп, Казанга кайтып киттем. Бер атнадан әйләнеп килергә тиеш идем. Безнең монда эшләребез гөрли. Бригадамны ялларга халык чират тора. Бер йортны күчереп салуыбызга, икенчеләре йөгереп килеп җитә.

Хәер, куллар суктырылган, эшләр килешенгән. Кара урысларның оясы саналган, җәй буе тирем түгелгән Николовка авылына гына түгел, күрше-тирә район үзәкләрендә дә үземне таный башлаган, әмма исем белән әйтәсе урынга, кушамат тагылып, Татарин аталган чакларым. Беләктә — гайрәт, йөрәктә — ут дигәндәй, күзгә төртелгәнне читтә калдыру юк иде анысы.

Көзлекне хатын урыс авылында уздырырга теләмәсә дә, җылы кочагымда җанын эретеп алгач, затлы Казанны, бу юлысы гына, беразга гына дип, калдырырга риза булды. Сүз һәм җыр чыгарып озатышулар ясап маташмадык. Хатыным бар булган күлмәген-чүпрәген бер кечкенә төенчеккә төйнәп кулына алды, мин исә ипләшкән фанер чемоданымны тоттым. Пристаньдә халык әллә ни күп түгел иде. Безнең кебек бәхет эзләп китүчеләр «Тургенев» теплоходына төялешә башлады. Нижныйдан ук килүче урыс һәм калын мишәр егетләре үзләренә җайлы урыннар алып бетергәннәр, безгә юл буена җилдә өшеп барырлык почмаклар гына калган иде. Шулай да хатынның бәхете аркасында миңа да урын табылды тагын. Соңрак танышып белешкән мишәр егете Насыйри:

— Чибәр түтигә мына мында утырса да ярый,— дип әйтмәсенме.

Хатын оялып торса да, тизрәк шунда елыштырдым. Мишәр егете, хәйран олы адәм, бер-бер учында да аны-моны рәхәтләндереп утыртырлык иде. Минем дә барлыгымны күреп алгач, гәүдәмнең иләмсезлегеннән шикләнепме, бераз тагын да ипләнеп:

— Дәдәгә дә үзрә утырмак урын вар,— дип, ике капчык йөген читкәрәк этте.

Ялындырып торырлык хәлдә түгел идем. Утыруыма, каршыдагы матур марҗа хатыннары, итәкләрен җыештырып, бот ялтыраткалап алдылар. Тәүфыйклылар да инде үзләре. Хатын, алар өчен оялып, йөзен яшергәндәй читкәрәк борды. Ә минем күз очкыны тегеләрнең түгәрәк тез башларын җылытып үзды. Моңа кадәр теләсә ни сөйләп килгән булырга кирәк, мишәребез ярты җирдә калган сүзен дәвам итептер, көлкеле вакыйгасының мин ишеткән ике сүзеннән үк марҗаларны кабат рәхәтләндереп кеткелдәтә башлады. Без генә хатын белән һични аңламый калдык. Хәер, бераздан аларның көлешүенә колак салып, минем җанкисәккәем дә елмайгалый башлады. Моңа кадәр:

— Ул күз күрмәгән, колак ишетмәгән җирдә туганнарсыз күңелсез булыр инде! — дип баш катырып бетерүләреннән соң, бу рәвешле генә ярыйсы ук яктырып киткән йөзен күрү минем өчен куаныч иде. Шушы хәлдән сөенеп, мин дә мишәрнең эре сүз борчагын чүпләргә генә уйлаган идем, кайберәүләр инде кузгалыша башлап, төшәргә әйберләрен барларга тотынгач, урыннарны алыштырырга туры килде. Бу юлысы иркенрәк мәйданны яулап өлгердек. Шул арада югалып торган мишәребез үз биләмәсенә әйләнеп кайтты. Ул да түгел, юлны дәвам иткәндә теплоход эче кабат халык күче белән шыгрым тулырга өлгергән иде.

Кичкә генә Сәнгиләйгә килеп җиттек. Төшеп калгач, колаклар тынычланып, һавалар иркенәеп китте. Шактый озак килүебез сәбәпле ачыгылган икән. Мондагы ашханәне яратып калган идем. Хатынны шунда дәштем. Аны-моны әйтмәде, артымнан иярде. Әмма урамда йөгереп йөргән дуңгыз балалары, шәһәрдән соң күзгә тиз чалынучан тәбәнәк һәм халкы кебек үк төссез йортлары аны миңа елышырга мәҗбүр итте. Җитмәсә, ашханә төбендә тәмәке көйрәтеп утырган эшсез һәм кыяфәтсез мужиклар аларган күзләре белән аңа ашардай итеп карадылар. Бу җирләр минем Казан күгәрченем өчен чит һәм ят, рухсыз кебек тоелганын үземнең дә элегрәк күңелемне укшыткан, инде онытыла барган кичерешләремне исемә төшерүемә үк аңлап алдым. Инде генә, күңелен күтәрим дип,назлы сүз катмакчы идем, яннан берәү, узып барышлый:

— Хо, Татарин! — диде.

Митрофан икән. Сакал-мыегын чиста итеп кырдырып алган, өстенә костюм, аягына күн итекләр кигән.

— Кияү егете булгансың! — дип шаяртырга өлгердем.

Ул да калын иренле, зур тешле авызын киң ачып ыржайгандай елмайды да сүзләремне куәтләп куйды:

— Булмый болай, ялгызыма озак каңгырырга туры килде. Тәвәккәлләргә булдым!..

Мин, аның җилкәсенә сугып, бәхетләр теләдем дә, аннан соң ашханәгә килеп җитеп, белүемчә, уникедән дә ким булмаган басмалы баскычтан залга таба хатыным белән күтәрелдем.

— Ул нинди кыяфәтсез урыс иде?

— Ә, җәен аларның авылын күчерештек. Бер дә айнык чагын күргәнем булмады. Ә бүген ясанып алган. Үзгәрә халык, үзгәрә,— дип, борчулы йөзле хатыныма җавап бирдем,— исең китмәсен. Алар барысы да шушындый.

— Миңа монда бер дә ошамый...

Шулай диясенә һич тә сәерсенми идем. Иртәме-соңмы бу сүзләрне кузгатачагын көткәнемә күрә, җавабым да әзер булып, шунда ук тынычландырыр өчен әйтеп салдым:

— Бераз сабыр итик. Эш бетүгә, кайтып китәрбез. Инде дә теләмәсәң, бер-ике көннән Казанга озатып куярмын!

— Юк инде,— диде ул, бөтенләй көтмәгәнемчә,— кияүгә чыгып та, бер генә рәхәтеңне күргәнем юк!

Мин ашханә залының ишеген ачарга өлгергән идем. Аны алга уздырып, сүзләренә кирәгенчә җавап бирә алмадым. Шулай да ул әйткәннәреннән күңелемә тынычлык иңеп, юк-бар уйларымны хәтеремнән себереп түктем. Болай булса, барысы да яхшыга таба барасы иде.

Ашханәнең татлы ризык исе күңелләрне эретеп, борыннарны кабартып җибәрде. Моңа кадәр ашалган каты-котыны майлы кайнар шулпа, итле бәрәңге, куе чәй алыштырырга тиеш иде. Мин икебезгә дә, тәлинкәләрне мөлдерәмә иттертеп, ашын-башкасын алдым, өстәл янында утырып калган хатынга китерә-ташый башладым:

— Борчылма, җаныем, барысын да үзем эшлим, көтеп, сабыр итеп кенә тор!

Аның ашыгыр җире юк иде. Инде мең сөенеч: «Өйгә кайтасым килә!»— дип борын да турсайтмады. Казанны бераз оныта бара бугай.

Эһ, мин әйтәм, эчтән генә, дөнья күрмәгән шул әле. Үземә кияүгә чыгуы да беренче тапкыр кешеләр арасына керүе белән бер булды. Кая ди инде ул Казаннан китү, яшәгән урамнарыннан арырак нәрсәләр барын да бөтенләй белми. Шәһәр күгәрчене. Үзе иркә, үзе пөхтә, үзе куркак.

— Хәзер, җаныем, чәйләрне дә китерәм дә... Сиңа нәрсә алырга, бөккәннең бәрәңгелесенме, башкарагынмы?

— Тәмлерәген!

— Баллырагын инде, алайса?

— Шулай ит!

— Хәзер, җаныем!

Кешеләрнең аз чагына туры килдек әле дә яхшы, юкса чират торып кына да төнгә калырга мөмкин булыр иде. Бераздан кереп тулачаклар инде. Тизрәк ашап өлгерергә кирәк.

Бөккәннәремне күтәреп килгәндә, минем урынга кара костюмнан таза бер ир утырган, ашымны рәхәтләнеп чөмерә иде. Каршында хатыным телсез калган, күзләре шар булган, ни әйтергә белми аптырап калган.

— Урынымны бушатыгыз! — дип үтендем.

Чәче кыска итеп алдырылган ертык чырайлы ямьсез ир күтәрелеп карады да саллы гына сүгенде һәм миңа олагырга боерды. Икенче тапкыр сүземне кабатлап, телемне әрәм итәргә исәбем юк иде. Җитмәсә, ашханәдәге һәммә кеше, безгә борылып, вакыйганың ахыры ничек бетәсен тамаша итә башладылар. «Татарин» дигән атым чыккан хәлдә, шушы шакшы урыс алдында тез буыннарымны калтыратып, артка чигенүнең хәере юк иде. Ашымны алдыннан тартып алдым да йөзенә капладым. Ни булганын чамалатырга өлгерткәнче, кайнар ботканы да башына кидердем һәм мәхлукны якалап торгыздым. Гәүдәгә шәп һәм калын икән. Әмма бөтен бар гайрәтем кузгалган, кодрәт чакмасы чагылган. Туктап тору юк. Аның кизәнгән йодрыгы ипи шүрлегемне күчерергә килеп өлгермәде, каерып алдым да баштүбән очырдым. Идәнгә килеп тә төште, өстәлдәге аш тәлинкәләре берәр карыш сикерешеп тә куйды. Тагын да бөтереп алдым да ишеккә китердем һәм, арт ягына тибүем булды, баскычтан очып-очып тәгәрәп төште. Инде дә башын күтәреп, өстемә ташланыр бу дип, һөҗүмемне дәвам итәр өчен артыннан төшә башлаган идем, сикереп тә торды, җан-фәрманга урам буйлап йөгерергә, өркеп качарга тотынды. Олагып котылуны хәерлегә санавына мин шат идем. Күземнән югалганчы, аны карап тордым да, ашханәгә кабат кердем. Ни күрим, өстәл өстенә ак ашъяулык китереп япканнар, яңа аш, ботка куйганнар. «Рәхим итегез!»— дип кенә торалар...

Бригадабыз тукталган авылга килеп җиткәндә генә хатыным, тынычланып, теленә килгән беренче сүзен әйтте:

— Мин сине... Мин сине мондый ук дип белми идем әле...

— Нинди дип?

— Усал икәнсең!

— Дөнья өйрәтә ул!..— Бүтән сүзем юк иде.

Шуннан бирле без урык-сурык, беребез анда, икенчебез монда яшәмәдек, һаман да янәшә булдык. Моңа кадәр хатыным иркәләнүне һәм үзсүзләнүне гадәте иткән булса, моннан соң һаман да «әйе»гә таяна башлады.

Ә теге оятсыз адәм төрмәдән генә чыккан, бөтен Сәнгиләйне дер селкетеп тоткан ташбаш булган икән. Аны тукмап җибәрүемне Митрофан һәркемгә сөйләп, минем авторитетны тагын да үстерде, кая барсам да, шунда казанган «ак сакалым» алдан йөрде. Үзем дә, ике сөйләшеп тормый, кемлегемне белеп яши башладым. Күренсәм, тавыш күтәреп сүз әйтергә һичкем кыймый иде.

Теге адәм дә юлыма кабат очрамады, бу тирәләрдән табанын ялтыраткан, диделәр. Тик менә акча һәм байлык кына казана алмадым. Эшләгәнем-тапканым китә-бетә барды. Бәлки, бераз иркенрәк яшәлгәндер, әллә туганнар комсызрак булганнармы? Ул хакта нигәдер исемә төшерәсем килми.

*Июль—август, 1998*

# Бар бер авыл, Чокал, диләр...

Намусны мәхәббәттән өстен, диләр. Юк сүз! Мәхәббәт намустан югары булмаган кебек, намус та мәхәббәттән өстен тора алмый ул! Һәркайсының үз урыны, хәтта күңел түрендә дә. Әмма адәм балалары үз гамәлләрендә яки намуска, яисә мәхәббәткә таянырга, икесенең берсен сайлап алып эш итәргә мөмкиннәр. Анысы аларның үзләреннән тора.

Казаннан көньяк-көнбатыш тарафта Чүпрәле дип аталган мишәр иле бар. Кара туфраклы уңдырышлы җирләрнең хуҗалары булып, су һәм урманлыклардан мәхрүм хәлдә яшәгәннәрен искә алмаганда, тормышларын җәннәт рәхәтлекләре белән чагыштырырга мөмкиндер. Аллаһының хөкеменә сөенеч итеп, тәкъдир бүләгенә шөкрана кылсалар, кем әйтмешли, күктән манный боткасы яуганын гына көтеп ятсалар, мишәр буламыни инде алар?

Мишәр дигәннән дә, мишәрнең цыкылдап торганнары, Казан татарларын, өнәми генә, «чохым» дип йөртүчеләре. Ходай Тәгалә аларның зур башларын таштан, йодрыкларын күсәктән аздырып бар кылганын

истә тоткан кавемнәр элекләрне, ни, ат тәртәләрен читкә каерып, авылларына аяк басмый гына үткәннәр. Әле хәзер дә шулай, ахрысы.

Чүпрәледән тагын да арырак китсәк, Иске һәм Яңа Чокал авыллары булып, берсендә мишәрләрнең астан кистерә торганы, икенчесендә телгә-сүзгә елгырлары яши. Әмма дә җайлары килмичә һәм дуслыкны да өзмичә гомер корып ятсалар да, бер-берсенә кыз бирмәүне, бер-берсеннән кияү-кода китертмәүне мәслихәт күрәләр икән, имештер. Хәер, хикмәт андамыни! Чүпрәледән аргы якта аллы-артлы тезелгән Үби авылларының берсендә Гөлсинә исемле кыз үсеп килә икән. Яңа Чокалдан Мансурның гайрәтле, әмма дә карт егет булып барган чаклары, имеш. Эше — руль тәгәрәтү, сөт ташу. Иртәннән юлда, кичен дә юлда дигәндәй, әле борыны егет исен сизәргә әзерләнә башлаган чибәр кызны бер күрә бу, ике, өч... Май заводыннан машинада гына шулай ук бер, ике, өч озатып куя да, дүртенчесендә тәвәккәл итеп, Чокалга алып элдертә. Кызны әнисенә күрсәтә дә:

— Базга ябып куяргадыр? Миңа барам, дисә, өч көннән чыгарырбыз, киреләнсә, тамагы ачкач, риза булыр, беркая да китмәс,— дип, алсу йөзле Гөлсинәне бәрәңге чүпләргә төшерә.

Кыз, мескен, бер көн елый, икенче көнне тынычлана, өченче көнне ризалыгын бирә, кая китсен?!

Ул вакытларда сүзе күп булгандыр, әмма хәзер, инде өч балалары тупылдап үсеп килгәндә, каракаршы зур йортлар салдырып, түшәменә күтәрелеп караганда: «Һай-һай, биек икән, сарай кадәр!»— дип уйлап куясың да, бәхетләренә көнләшеп яшәүчеләрнең дә хәленә керәсең икән шул.

Байлык җыю өчен өйләнү-нитү таләп ителми, тырыш булырга кирәк. Моны һәммәбез дә беләбез, тик кәсебенә генә керә алмыйбыз.

Хәерниса исемле бер кыз бар икән, буйга-сынга әллә ни гүзәл булмагандырмы, әллә иркә баладан микән, үзенә егетләр һич тә карамаганнар. Ә күршедә генә тормышын җайлаган, байлыгы ишелеп чыга барган, гомерен сәүдәгә сарыф итүче Гыймай яши, ди. Иртә-кич юлын базарга турылаганда, авыллары яки йокыларыннан тормаган, яисә инде түшәккә баш куярга өлгергән була икән. Сазаган кыз Хәерниса: «Шушы Гыймайны ирем итмәсәм, хәерсез аталырмын!»— дип сүз биргән, имеш. Мишәр халкын беләсез, әйткән сүзендә тормаса, кәкре каенны турайтып, имән итеп өрлеккә сала.

Гыймай булган егет, ат йөгертеп кенә йөри, күзенә агы-карасы күренми, акчадан башкага күңеле төшми. Әгәр дә учындагы алтыннар җанын җылытудан туктаса, колагында чыңы тынса, йокысын югалта, ди.

Эшләре «худлы» гына барган чак икән, Аллаһының рәхмәте. Кешегә бәхет киләсе булса, тәкъдиренең капка ачкан вакыты да була шул ул.

— Бу күрше кызы, Хәернисаны әйтәм, иртән күрәм, тәрәзә ачып, авызын иснәп кала. Кич кайтам, шул ук хәл. Акылына зәгыйфьлек килмәгәндер бит? Һаман да күңел салып йөри идем,— ди икән көннәрнең берендә Гыймай, сер алышу өчен генә кызның агасы Кәримгә.

Ә бусы аптырап калмаган. Сеңлесенең алдан кисәтеп куйганын, җиләнлек сатинга атап кул бирешүләрен исенә төшергән дә, шунда ук:

— Әллә белми идең? — дип, соравына каршы сорау ташлаган.

— Ай-һай, нинди зәхмәткә тарыды икән? — дигән Гыймай, сүзнең чыннан да үзе шикләнгәненчә баруына хәйран итеп.

— Юк ла,— дигән Кәрим,— мин уңга киттем, син сулда калдың.

— Ничек?

— Менә шулай! — Кәрим бот чапкан. Аннан имән бармагын җил уңаена куеп, сүзләрен берәмләп тезә башлаган, ахырда:— Ул, ни, бер дә дөнья малын ашамый, ахирәт ризыгы белән генә тукланып тора,— дигән.

— Ничек инде? — Гыймай сүзгә сүзен ияртергә өлгермәгән, Кәрим:

— Менә шулай, дустым! Алай да була икән ул. Һава белән тукланып тора, һава белән. Туганнан бирле. Бер кабым да капканы юк. Авызын ачып утырганы — ашаган вакыты аның, тәрәзәләрен ачып, һава гына йота. Иртәгесе белән кичкесе бик тә татлы икән, әйе!

Гыймайның исе-акылы киткән, аңына килә алмый хәйран итеп йөргән һәм:

— Менә ичмасам яхшыдан да яхшы. Ашатасы да юк икән. Күпме мал-мөлкәт янга кала. Өйләнәм. Иртәгә үк яучы җибәрәм. Хәернисаны үземнеке итәм. Нигә моңынчы белмәгәнмен! — дип, ниятен күңеленә киртләп ныгытып куйган.

Чокалны шаулатып туй иткәннәр. Бу кадәр дә пар килгән яшьләрне күреп, бөтен авыллары гына түгел, тирә-күршеләре дә сөенгән. Ничек тә Гыймайга үз кызларын ярәштерергә өметтә торучылар гына эчләрен уганнар.

Туй — китүчән, тормыш — калучан, диләрме әле? Гыймай да бер атна хатын куенында ятканнан соң, җылы түшәген таң белән калдырып, базарга чаптырткан, кич кенә кайта, сәүдәсенә бәрабәр байлыгын кабат ишәйтә башлаган. Хатын тәрбиясендә яшәүнең бар рәхәтен һәм уңайлыкларын татый икән. Әмма көн-

нәрнең берендә сәүдәсе иртәннән үк артыгы белән яхшы барып, кич җиткәнче өенә кайтып керсә, сөеклесе Хәерниса өстәл артында майдан, каздан, казылыктан һәм дә аштан, бәлештән, пәрәмәчтән назланып кына тукланып утыра икән. Бу хәлгә Гыймай хәйран калган. Атылып бәрелмәкче икән. Шулай да сабырлык җиле аның ачу канатларын сындырган.

— Син нәрсә? — дигән.

— Ә ни булган?

— Ни булсын... Сине бит дөнья малы белән тукланмый, дигән иделәр.

— Шулай идем шул,— дип, Хәерниса әйтеп тә салган,— җил капчыгымны тиштең дә, хәзер дөнья ризыгын ашарга калды!

Гыймай бай аның сүзләренә тәмам ышанган. Бергә йоклап кына харап иттем, дип, Хәернисаның тишелгән капчыгын гомере буе кызганып искә ала торган булып калган, имеш.

Әйе...

Рәис исемле бер мишәр абзагызны да Чокал халкы гына түгел, күпләр белә торгандыр әле. Күрмәгән булсалар, ишеткәннәре бардыр. Шул, шул! Үзе! Кылыч борынлы, үткен күзле, җәһәт йөрешле. Буена карамагыз, буй кемдә дә бар ул. Аңа булган кадәресе дә җиткән. Элекләрне машинада эшләп, хәзер каты борыннарның, ягъни дә дуңгызларның, хуҗасы булып алды. Ферма мөдире. Үсә абзагыз, тыныч кына, матур гына үсә, күз тимәсен!

Бервакыт шул Рәис абзагызны бөтен Чокал авылы белән генә түгел, район милициясен аякка бастырып эзләгәннәр, бөтен ил буйлап хәбәр салмакчы да булганнар, тавышыннан куркып кына тукталганнар.

Моны бер көн эзлиләр икән, ике, өч. Һаман эзенә төшә алмыйлар. Өендә малайлары-кызлары елап утыра, хатыны «суган суын сыга». Җан ачысына түзә алмаган күрше-күлән, тавык-чебеш, сыер-сарык, өйкурага кайтырга теләмичә, анда-монда чәчелеп йөри. Ә ул юк та юк.

— И яхшы да кеше иде,— дип елый ди хатыны, Рәиснең усаллыкларын һәм салгалаштыргалап йөрүләрен тәмам онытып.

— И эшкә афәрин дә иде инде: ни тотса, шуны башкарды, нигә ябышты, шуны булдырды,— дип сөйли икән күмхуҗ рәисе, зурдан кубып, әмма дә Рәиснең кәҗәләнгән чакларын исеннән чыгарып.

— И батыр да кеше иде инде,— дип искәрә икән участок милиционеры Гатауллин, Рәиснең кыйнашыптукмашып йөрүләренә түзә алмас хәлгә җиткән чакларында төзергә җыенган беркетмәләрен ертып ташлап.

Аның саен уллары-кызлары инде миләштәй кызарырга өлгергән күзләреннән бәрәңге кадәр түгәрәк яшь бөртекләрен сыга икән, аның саен күрше-күләннең бәгыре көя, җаны киселә, ди.

— И, Рәис кебек кеше безнең авылда элек тә тумады, моннан соң да булмас. Бер яртыга йөге белән күмхуҗ печәнен ишегалдыма кайтарып аудара торган иде, бәгырькәем,— дип елый ди Хисбикамал түти.

— Аның кемлеген әйт әле! Ул елгыр күз, ул кылыч борын, ул сеңердән генә торган беләк-кул,— дип кушылып китә ди җилдән бала иярткән Гөләндәм, кара чәч толымнарын йолкып, болай да зур күзләрен кабакландырып.

— Эһ, миңа бирәсе биш тәңкә акчасы калды, баш төзәтергә генә алып торган иде, хатыны да кайтармас инде,— дип ачыргалана икән Шәйхетдин абзый, ачуын баса алмыйча, Чокалны иңгә-буйга ун әйләнеп.

Аның саен Рәиснең хатыны үкси, балалары бетеренә, ди. Күмхуҗ идарәсенең ишек башына эләр өчен, матәм тактасын да әзерләп куйганнар. Тик кайгыдан берсе дә кадак-чүкеч тотарлык хәлдә түгел икән.

— Үле гәүдәсен генә булса да тапмабызмы? — дип, абзар-кура, басу-кырны мең кат тикшереп, ерак Алатыр урманына ис сизүче усал этләр җибәреп эзләткәннәр. Ә Рәиснең ни үзе, ни сөяге юк. Эзенә төшә генә алмыйлар. Аптырагач, су төбендә ятмыймы дип, буа һәм күлләрне җибәреп бетергәннәр. Коеларны, тикшермә келәп, болай да ачы суын күз яшьләре белән тозландыра-тозландыра түккәннәр. Ә ул юк та юк.

— Ярар! — дип хәл иткән күмхуҗ идарәсе.— Булмады бу, кара тактаны элик тә матәм игълан итик! Яхшы кеше иде...

— Нишләмәк кирәк! — дип, карар астына сырлап кулын куйган район милициясенең башлыгы Габдуллин.

— Югарыда беленсә, авторитетка суга инде,— дип, теләмәсә дә килешергә мәҗбүр булган хакимият башлыгы.

— Җир тишегеннән булса да табыгыз! — дип каршы төшкән Рәиснең хатыны.

Мәсьәләнең кара такта белән хәл ителүенә бер кешенең каршы икәнлеген һәм күпчелекнең килешүен теркәп, беркетмәне тутырганнар да, мулладан җеназа укытырга тиештер дигән фикергә килеп җиткәннәр генә, кемдер ишек каккан. Ачсалар, ни күрсеннәр, өч көн эзләп тә табылмаган Рәис басып тора. Тик моңа кадәр ерып йөргән авызы салынып төшкән дә, күз төпләре чокырланып калган.

— Бәгырем,— дип, аның кочагына хатыны атылган, муенына асылынган.

— Ни булды? — дип, аларны сырып алган идарә халкы.

Ул арада өере белән бөтен Чокал җыелырга өлгергән. Барысы да куанышып:

— Табылган, табылган, Аллага шөкер! — дип, бер-берсен котлашканнар.

Инде кавышу минутларының кайнарлыгы суына төшкән. Шунда участок милиционеры Гатауллин сыер кебек мөгердәп куйган:

— Ни булды, кая югалып йөрдең?

— Тукта әле син,— дип, аны бүлдергән район милициясе башлыгы Габдуллин,— мин барында, алга чыгарга ни хакың бар?.. Кем, Рәис, әйе, килегез әле бирерәк, сөйләгез барысын да, яшермәгез!

Инде өч көн һәм өч төн Чокалны гына түгел, районны да утлы табада биетергә өлгергәнен белеп алган Рәис, бу гаугаларның һәммәсе дә хатынының этлегеннән икәнлеген яхшы төшенеп, аңа-моңа күз кырые белән генә карап алган да елап ук җибәргән.

— Коткарыгыз, егетләр, берүк харап итмәгез, өч мең доллар таләп итәләр!..

— Выкуп, җәмәгать, выкуп! — дип, тагын алга чыккан участок милиционеры Гатауллин, өч көнлек махмырыннан һаман да арына алмыйча сабырсызланып.

— Өч мең доллар? — дип егылып китә язган күмхуҗ идарәсе.

— Өч мең доллар? — дип аңлаша алмый торган хакимият башлыгы.

— Өч мең доллар шул! — дип елый биргән Рәис, зәңгәр күзләреннән саранланмый сыккан күз яшеннән идарә эчен күл ясап. Әмма бераз шикләнеп тә куйган: «Арттырып җибәрмәдемме?»

— Өч мең доллар? — дип хәйран калган хатыны, моның нәрсә икәнлеген тәгаен гына аңламыйча, әмма зур кешеләрнең гаҗәпләнүеннән бик олы борчу икәнлеген сизенеп.

Бер кайгыны икенчесе алыштырган. Чәчләр үрә торган. Беркетмә ачарга өлгергән Гатауллин гына Рәиснең ата-бабасын сораштыра башлаган. Бу юлы аны һичкем бүлдермәгән. Әмма ул да:

— Ни булды? — дигән соравын ничәнче тапкыр кабатларга мәҗбүр булган.— Бәйнә-бәйнә сөйләп бир әле! Йә-йә, сыктама шулкадәр, үзеңне кулга ал инде!

«Кулга ал» сүзләрен ишеткәч:

— Бирмим, нинди кулга алу ул! — дип, Рәиснең хатыны уртага очып кергән.

Тезләнеп үксегән Рәис исә, әйтелгән сүзнең мәгънәсен аңлап, бераз җыела төшеп, аякларына баскан. Боларга карап тора башлаган. Әмма теленә сүз кертүгә, тагын елап җибәргән һәм тезләренә кабат сыгылып төшкән. Ә үзе такмаклый икән:

— И-и, әннә генәм! Харап кына булдым, егетләр! Харап кынай-й-й... Үтерәләр... Билләһи, үтерәләр... Сау бул, гомер иткән хатыным, изгелекләреңне мәңге онытмам... Сау булыгыз, иптәш Габдуллин, кешегә — кешечә, хайванга хайванча карадың, әмма кеше белән хайванны аермадың. Барыбызны да тигез, тиң күрдең, рәхмәт сиңа, бәхил бул! — дигәч, гомеренә дә мондый яхшы сүзләрне ишеткәне булмаган район милициясе башлыгы түзмәгән, Рәиснең муенына барып асылынган да үксеп-үксеп елап җибәргән:

— Рәхмәт, туган...

Аңа хакимият һәм идарә башлыклары кушылган. Участок милиционеры Гатауллин гына нык калган:

— Сөйлә, ни булды?

Аның таләбеннән өркенеп, идарә бинасы нигезендә биеп куйган. Инде генә җавап бирим дип авызын ачкан Рәис тагын да катырак балавыз сыгарга тотынган. Барчасы чарасыз калып, акыл шөрепләрен ни-нәрсә белән дә тыгызлап өлгерергә җай тапмаганнар. Арендага алып, каты борын дуңгызлар симертүче икенче берәү, ягъни Кулак кушаматлы Рәис, фураж китертергә боерык юнәтеп булмасмы дип, шунда килеп кермәсенме? Бу кадәр җыелган халыкны күмхуҗ идарәсендә гомерендә дә күргәне булмаганлыктан, болай да сак күңеле бөтенләй дә ишелеп киткән. Ул да, участок милиционеры кебек:

— Ни булды? — дип сораудан узмаган.

Аңа:

— Үзең тыңлап бак,— дигәннәр, үзләренең дә әлегә һични төшенә алмаганлыкларын искәртеп.

— Ни булды? — Каты борыннар Рәисенең акылы җитми кабатлап соравын бу юлы берсе дә игътибарга алмаган.

Югалып табылган Рәис сөйли икән:

— Эштән кайтып барам, килеп туктадылар калын-калын адәмнәр. Өч «мерседес»та. Йөзләренә оек тартканнар, күзләренә кара күзлекләр кигәннәр, кулларында «көпшәләр».

— Син Рәисме? — диләр.

— Рәис,— мин әйтәм.

— Утыр алайса,— диләр, күкрәгемә алтатар терәп,— юкса көпшәдән пошкыртып суытабыз, әйе...

— Сез нәрсә, егетләр?..— мин әйтәм.— Утырам-утырам... Күзне-авызны бәйләделәр дә алып киттеләр. Шактый бардык. Тәмам шабыр тиргә батып беттем... Туктаттылар, каядыр кертеп яптылар. Шулай да:

«Качмыйм»,— дип сүз биргәч, күзне-кулны чиштеләр. Алдыма әллә ни төрле сыйлар куйдылар. Ашавын да яхшы ашаттылар. Әмма кара кайгыдан тамагыма гына үтмәде. Өч мең доллар акчаны бүген агачлык алдына, кара сумка белән китерергә куштылар...

Сөйләп бетерүенә Рәис уң-сулына карап алган да:

— Каян алыйм ди мин аны, «суыталар» инде, «суыталар»... Башларым харап булды...— дип кабат елап җибәргән.

Җыелган халык:

— Әннекәй генәм! — дип, җиргә сеңгән.

Аның саен Рәис бөгелә төшкән, ә бераздан халык тагын да:

— Ай Ходаем, ай Ходаем...— дип, аһ-интизарлык кыла башлагач, бөтенләй дә идәнгә капланып үксергә тотынган.

— Каян алыйм ди мин ул кадәр акчаны? — Йодрыгы белән идәнне төя, ди.

Шунда район милициясе башлыгы сорап куймасынмы:

— Ә нигә дип именно сине алганнар әле алар, башка кешене түгел?

Аның болай дип үлчәми әйтүе шунда халыкны диварга сылап куйган.

— Әстәгъфируллаһ, әстәгъфируллаһ! — дигәннәр кайсылары.

— Чыннан да, ни өчен мине соң әле, нишләп сине түгел? Минем ни гаебем бар? — дип, милиция башлыгына карап, капланган җиреннән күтәрелеп, өстәл артындагыларга якынлашкан Рәис.

— Берәр гөнаһың бардыр? — дигән милиция башлыгы, шунда ук үз гаепләрен дә ярым-йорты хәтере аша уздырып һәм: «Алла сакласын, бу бәндә, минем белән чагыштырганда, сабый күз яше төсле пакь һәм саф!»— дип уйлап куйган. Шулай да башы эшләп алган да (казаны зур шул), йомшаграк итеп: — Бәлки, дим, син — шофер кеше, берәрсен ялгыш бәрдереп үткәнсеңдер, ни, яки башкадыр? — дигән.

— Алла сакласын! Моңа кадәр дә саклады, моннан соң да бер үзенә генә сыенам!.. Иптәш начальник! Кая ди ул, авыл эчендә генә йөрим мин! Алла сакласын...

Рәиснең тагын да үксеп җибәрүеннән курыккан район милициясе башлыгы:

— Мин болай, аптырагач кына,— дип әйтергә мәҗбүр булган.— Берәрсенең юлына аркылы төшмәдеңме?

— Юк инде, сез нәрсә?

— Ә нигә именно сездән сорыйлар?

— Белмим...

Милиция башлыгы башын кашырга мәҗбүр булган. Барысы да аңа карап торалар икән. Шунда фикер казаны тагын да кайнарланып алган Габдуллин тагын бер сорау ыргыткан:

— Бәлки, берәрсе белән бутаганнардыр?

— Монысы булырга мөмкин! — дигән Рәис, аның сүзләрен шунда ук эләктереп алып, җыелган халыкка каранып.

— Монда тагын кайсыгыз Рәис? — дигән милиция башлыгы, кем Рәис, шуны атарга җыенган кебек ачу белән.

— М-м-м-мин...— дип чыгып баскан арендатор Кулак Рәис, кулындагы боерык кәгазьләренә кадәр дөбер-шатыр калтыранып.

— Тагын кем? — дигән милиция башлыгы, халыкны чүктерерлек итеп карап куеп.

— Бүтән юк! — дигән ышанычлы тавыш белән күмхуҗ рәисе. Бу рәисне «персидәтел» дип кенә белгән авыл халкының аны шик астына куярга башына да килмәгән, билгеле.

— Алайса, синең ни гаебең бар? — дип, арендатор Рәиснең күзенә кадалган милиция башлыгы Габдуллин.

— Бе-бе-белмим,— дигән арендатор, мескен,— мин көне-төне дуңгызлар карыйм. Беркая чыккан, һичкемне күргән юк. Эштә мин, көне-төне эштә. Юньләп ял да күргән түгел!

— Һе,— дигән бик тә мәгънә белән башлык,— һе, алай икән... Арендатор икән... Дуңгызлар карый икән... Һе... Ни күрисең?..

— Тизәк күрим, дуңгыз тизәге, иптәш ни-кем,— дигән арендатор Рәис.

— Тизәк күрим? — дип көлгән башлык, барчасына да ачу беләк карап куеп.— Акча күрим, диген, акча!

— Акча? — дигән аптыраулы арендатор.

— Акча! — дип бармак төрткән аңа халык.— Акча күри, акча!

— Гаепле! — дигән, озын-юан бармагын аңа гүяки үтәли төртеп башлык,— Гатауллин, кулга алырга!

— Тыңлыйм, иптәш Габдуллин! — дип, участок милиционеры шунда ук арендатор Рәиснең кулларын, артка каерып, богаулап куйган.

— Сез нәрсә? — дип сикереп торган хакимият башлыгы.— Сез нәрсә, иптәш Габдуллин? Нинди гаеп? Нинди кулга алу?

— Дуңгызларны кем карый? — дигән сикереп торып күмхуҗ рәисе.

— Гаебе нидә? — дигән халык.

— Боларны бутаганнар! — дип, зур мәгънә белән сүз башлаган Габдуллин, аларга төртеп-төртеп күрсәтеп: — Ул Рәис дип белеп, бу Рәисне алганнар!

Барысы да шым булганнар. Шунда гына эшнең асылын аңлап өлгергән арендатор Рәис:

— Йа Аллам,— дип, идәнгә сыгылып төшкән.

— Ычкындыр аны, богау салу артыграк булган! — дип әмер биргән Гатауллинга Габдуллин.— Беркая да кача алмаячак болай да!..

Азат ителүдән генә арендатор Рәиснең хәле яхшырмаган. Ул угаланган да угаланган, бетеренепме-бетеренгән. Бер Рәисне икенчесе алыштырган.

— Нишлибез? — дип сораган күмхуҗ рәисе, үзенең дә рәис булуын әлегә искәрмичә, халыктагыча үзен бары тик «персидәтел» генә дип белеп.

— Белмибез,— дигәннәр барысы да бердәм.

Мондый вакытта һәркемнең күзе хуҗаларга таба юнәлә. Алар ни әйтер? Чөнки дә олы, зур кешеләр! Ни дисәләр дә, бары тик алар гына, алар гына хаклы!

— Өч мең доллар? — дип, башын кашыган күмхуҗ рәисе.

— Түләргәме? — дигән Гатауллин.

— Нинди түләү! Ни в коем случай! — дияргә кодрәте җиткән хакимият башлыгының.

— Түләү юк! — дип, аны җөпләп, сүзен белдергән күмхуҗ рәисе.

— Ничек инде? — дигән арендатор Рәис.— Акчагыз бар бит!

— Үзеңнекен? Мин каршы түгел,— дигән күмхуҗ рәисе.

— Әле генә акчабыз юк шул,— дигән баш бухгалтер, экономистка карап куеп.

— Доллар белән шул,— дип сүз кыстырган бәланең үзеннән узып барганлыгына тынычланып калган шофер Рәис.

— Түләмибез, бетте-китте! — дип кырт кискән күмхуҗ рәисе, баш бухгалтерның сүзләрен йөрәге аша уздырып.

— Миңа нишләргә? Башымны бетерәләр, харап булам! Инде алар мине эзләячәкләр! — дигән, «мине» сүзенә йөрәк яргыч басым ясап, акылы югалып калган арендатор Рәис, акча хакында түгел, үзе турында хәсрәтләнеп.

Шунда чарасызлык йөгәне кигән хөкемдарлар тынып калган. Халык:

— Йа Ходаем, йа Аллам! — дип иңрәгән.

Көтелмәгән җиргә чакырылмаган кеше килеп керүчән шул ул. Хат ташучы, соңгы елларда бигрәк тә юкарып калган биштәрен җилкәсендә генә очыртып, халыкны ера-ера, ишектән түргә таба узган.

— Безгә яисә Рәискә берәр хат юкмы? Мондый вакытта куркыту, угроза белән алар язучан булалар! — дип, аңа кулын сузып эндәшкән милиция башлыгы Габдуллин.

— Юк иде шул,— дигән хат ташучы, биштәрен тиз-тиз актаргалаган. Онытып калынмасын диярәк эзләнеп маташкан.— Гәзитләрдән гайре һич ни күренми.

Күмхуҗ рәисе каршысына китереп салынган вакытыннан бик тә артка калып алга баручы вакытлы матбугатны хакимият башлыгы актаргаларга тотынган. Әмма дә, хәрефләрдән сүзләр җыя алмыйча, шактый озак казынган, чокынган. Ахырда, күз-борынын кат-кат сөрткәч кенә, бераз тынычланып, үзалдына укып киткән:

— «Цильна» күмхуҗы рәисе...

Аны ишетергә өлгергән Габдуллин шунда ук гәзиттәге шул язмага капланган. Барысы да өстәл тирәсен сырып алганнар.

— Күмхуҗ рәисе? — дип сузып кабатлаган хаким.

— Күмхуҗ рәисе? — дигән аңа ияреп күмхуҗ рәисе.

— Күмхуҗ рәисе! — дигәнгә, сөенеченнән авызын ерган арендатор Рәис.

— Күмхуҗ рәисе? — дип пышылдашкан халык.

— Күмхуҗ рәисе — колхозның персидәтеле инде ул! — дигән Гатауллин, сүзнең мәгънәсенә яңа гына төшенеп.

— Йа Аллам! — дип иңрәгән күмхуҗ рәисе.— Кеше өчен кайгырып торам икән, ә монда бәла минем башны эзләп йөри!.. Йа Хода! Миңа нишләргә? Харап итәләр бит!

Өстәл артыннан чыккан күмхуҗ рәисе халык ураган бүлмәне бер әйләнеп узган да, әле Габдуллин, әле хакимнең муенына асылынып:

— Нишлим? Кая качыйм, иптәшләр?..— дип сыгылып төшкән.— Харап иттермәгез! Коткарыгыз! Минем үләсем килми! Балаларым бар!..

— Кассада акчаң күпме? — дигән Гатауллин, җаен тапкандай.— Долларга алыштырыйк!

— Чит илдә шул, чит илдә! — дип җавап биргән кумхуҗ рәисе, серен чишәргә мәҗбүрлектән.— Ышанычлы булсын дип, Швейцариягә үк илтеп салган идем...

— Ничек, синеке дә шундамыни? — дигән аптыраган хаким.

— Сездән күреп инде, сездән күреп,— дип акланган рәис.

— Юләрләр,— дигән ачу белән Габдуллин.— Атна-ун көнсез аннан алып кайтып җиткереп буламы соң аны? Мин менә ахмак булмадым, Төркиягә генә илтеп салдым! Мокытлар!

— Ярдәм итегез, туганнар! — дип, халыкка рәис учларын сузган.

— Ярар,— дигән бераздан хаким, аны тынычландырырга теләп.— Ни дә булса уйлап табарбыз! Районның ятим-ябаганы яклау һәм саклау бүлегендә бар иде бугай...— Шунда ук телефон тәгәрмәчен боргалый башлаган, әмма котмәгәндә Гатауллин телгә килгән дә шофер Рәистән сорап куйган:

— Алар синең белән кайсы телдә сөйләштеләр? Ялгышма, исеңә төшер! Бу бик тә важно!

— Кайсы, дип инде...— Рәис бераз каушап калган. «Татардан андый кеше талаучылар чыкмый, була калса да, урысча сөйләшә инде»,— дип уйлап алган да: — Урысча инде, урысча! — дигән.

— Йә, ничек әйттеләр инде? — дип төпченгән Гатауллин, гаҗәеп оста шымчыларны телевизордан күреп, алардан һәртөрле сәер хәрәкәтләрне өйрәнеп калганынча һәм кыяфәтен китереп.

— «Ты Раис шту ли?» дип сорадылар.— Рәис яшереп тормаган.

— Әһә, «Раис» дип сорадылар, әйеме?

Аның ни әйтергә теләгәнен әлегә төшенеп җитмәгән, әмма аңлаган кебек кыланган хөкемдар һәм хөкемдарлар әле Гатауллинга, әле Рәискә таба борылып караганнар. Шунда гына участок милиционеры дәвам иткән:

— Ишетегез! «Раис» дип әйткәннәр, «персидәтел» дип түгел! Аның әле без дә «персидәтел»не рәис икәнлеген гәзиттән генә чамалап беләбез. Ну ул журналистларны! — Ахыргы җөмләсендә күккә чөелгән йодрыгын, хуҗалар алдында яхшы түгел дип, өстәлгә китереп сугудан чак тыелып калган.

— Әһә! Минем гаеп юк икән! Минем катнашым кирәкми! — дип кычкырып сөенгән кумхуҗ рәисе, бәладән котылуына чиксез куанып һәм графиннан берьюлы өч стакан суны авызына бушатып.

Барысы да җиңел сулап куйганнар. Телефон тәгәрмәчен боргачлаудан инде туктаган хаким трубканы урынына аткан. Бөтен гаепне арендатор Рәискә йөкләгәннәр дә, Казандагы генералга хәбәр биргәннәр. Эшне ул шунда ук үз кулына алган. Өч вертолет, бер дивизия милиция җибәргән. Тиздән үзе дә бу гаскәр белән идарә итү өчен килеп җиткән.

Агачлык башына, капкынның җиме буларак, кара сумкага өч мең доллар тутырып, зур сак астында илтеп куйганнар да, танклар белән әйләндереп алганнар. Һәр куак төбенә бер милицияне баштанаяк кораллаңдырып салганнар. Ул арада, бәладән башаяк дип, арендатор Рәис, дуңгызларын ташлап, эш хакын да дәгъвалап тормастан, кара төндә адәм күзе күрмәгән якка китеп барган. Эзе дә калмаган, барлыгын-юклыгын да онытканнар.

Кара сумканы бер көн, ике көн, өч көн... кырык көн һәм төннәр буе саклаганнар. Әмма килүче дә, алучы да күренмәгән. Вертолетлар һәм танклар әллә нинди утларын яндырып, бер дивизия милиция ике күзен биш итеп сакта торуын дәвам итсә дә, мәгънә чыкмаган. Ахырда, арендатор Рәиснең симерткән дуңгызлары ашалып беткәч, Чокалның гына түгел, хәтта Чүпрәле районы кумхуҗларының келәтләрендә кырып-себерерлек бер юлпыч та ашлыгы-бодае-оны калмагач, әмер ирешеп, акчаны үзләренә алып, генералы-ние Казанга кайтып киткән.

Бераз вакытлар үткәч, дуслары теге шофер Рәиснең үзеннән җай гына сорыйлар икән:

— Шулай да дөресе ничек булды соң?

Әүвәле һичкемгә серен чишмәгән, ахырда, мактаныпмы, әллә намусы кузгалыпмы, барысын сөйләп бирергә мәҗбүр булган ул:

— Салган баштан җиңгәчәйгә кергәнмен. Йокланылган. Ике көн рәттән уятучы булмаган. Җитмәсә, минем югалуым хакында сүз ул арада таралып, дөнья кубарылган. Аптырагач, юри генә уйлап чыгарган идем, һәммәсе дә ышандылар тагын. Аннан соң үзем дә шул ялганыма ияреп киткәнмен,— дигән.

*Август, 1998*

# Коелган мәхәббәт таҗы

Вакыйга 1979 елның 31 декабрендә — Яңа ел кичәсендә чишелеш тапты. Әмма аңынчы ул мине туйганчы изде, елатты, түбәнсетте. «Күргәнемне бүтән һичкем күрмәсен!»— дисәм, беренче мәхәббәт хислә-

реннән бүтәннәрне мәхрүм калдырырга теләгәнем кебек аңлашылыр йә. Шуңа күрә дә: «Сез дә ишетегез, сез дә белегез!»— дим, бәлки, хатадан хали булырсыз.

Вакыйганың чишелеш табу датасын төгәл атадым инде, сәгатен дә, әгәр кирәк дисәгез, әйтә алам. Әйе, төгәл унбер сәгать тә кырык биш минутта иде. Яңа елны каршылар алдыннан гына. Ә аңынчы... Ә аңа кадәр мин самими һәм беркатлы авыл малайларының берсе идем.

Әлегедәй хәтеремдә, иярле атны уйнатып чабып барган җиремдә, миңа ул эндәште. Моңа кадәр аны бары тик бар һәм һичкем түгел дип кенә йөри идем. Шаяртып кына әйткән сүзе йөрәгем чакмасына бәрелеп китте дә дөрләгән ялкын эчемне-тышымны биләде. Хәтта гарәби елгыр атым да аякларын саташтырды, абынып китте, кешнәп куйды.

— Мине дә утырт әле!

Аның бу сүзләре әмер дә, үтенеч тә, еракка-биеккә ашкынган хисләренең канатланырга теләү билгесе дә иде...

Юк, исемен дә яшереп тормыйм. Ул сер түгел. Бөтен авыл белгәнне яшереп торуда ни мәгънә?

Гөлия!.. Әйе, үзе!..

Ул таганда атына, очып-очып китә, кара күзләрендә ахирәт көн сихрилеге балкый. Сап-сары чәчләрендә җәйнең йомшак җиле уйный.

— Гөлия?.. Сәлам!.. Нишлисең?..

— Күрмисеңмени, атынам... Сиңа рәхәт, ат өстендә очасың гына... Мине дә утырт инде?

Аның үпкәләгән кыяфәт чыгаруына исем дә китмәде. Ул әлегә минем өчен, чыннан да, беркем дә түгел иде. Бармы — бар, бетте-китте, вәссәлам...

— Утырт инде?

— Ярар, бүтән юлысы һичшиксез!

Бу җавабыма Гөлия көлеп җибәрде. Шаярткан гына икән шул. Таганы аны күкләргә чөйде. Чакма чагылды, ут кабынды, йөрәк ялкынга күмелде. Гөлия! Ул инде бармы — бар гына түгел, ул инде, һичшиксез, булырга тиеш, аннан башка дөньялык та була алмый, яшәүнең дә мәгънәсе юк! Гөлия!..

Мин шулай гомеремдә беренче тапкыр мәхәббәт сихеренә бирелдем. Моңа кадәр бөтенләй юк кебек булганмын икән шул. Бу хисләр үз барлыгымны танырга мәҗбүр итә башладылар. Яшәү яме тәнемә дә, җаныма да ургылып-ургылып тулды да тулды.

Ул вакытларда безнең авылның нәкъ уртасында олы, озын, зур агач мәктәп бар иде. Аның ишегалды яшел хәтфә үлән белән күмелгән. Анда, физкультура дәресләре өчен дип, махсус эшләнелгән турник, бөҗра һәм башка җайланмалар корылган. Биек аралага озын колгалар эленгән. Шуларның берсе ташбаш малайлар тарафыннан күккә чөелүче таганга әверелдерелгән. Гөлия оча-оча шунда атына иде.

Атның тезгенен җибәрдем. Тагын уйнаклап һәм ярсып чаба башлады. Ә мин исә Гөлияне гүяки әллә кайчаннан бирле үлеп-үлеп яраткан булуым хакында уйладым. Бу минем беренче сихри һәм назлы әкиятем иде. Дөньям һәм эшләрем онытылды. Күңелемдә әллә кайчаннан чәчелеп яткан шигырь орлыклары шытып чыктылар. Элеккеге авыл малае инде юк иде. Әмма берничә көннән ак каеннарны кочып, әкиятемнең дәвамыннан үксеп-үксеп елаячагымны башыма да китерә алмаганмын. Гашыйк булдым.

Бу мәхәббәт илаһи иде. Гөлия булмаса, аны сайлап, менә бары тик ул гына җаныма якын, дип, үз-үземне ышандырмасам, шушы илаһи бүләккә, бәлки, лаеклы табылмас та идем. Минем уемча, бу сөю җавапсыз калырга, шул хәлгә җаным сыкрап еларга, шигырьләр язарга тиешмен. Бүтәнчә һич тә мөмкин түгел. Күңел күзе сукыраеп калсын, дөньяның яме үзгәрсен. Миңа бары тик шундый мәхәббәт кенә кирәк, Аллаһыдан бирелгән, үземнең никадәр бәхетсез, ямьсез, сөйкемсез һәм сөексез икәнлегемне аңларга мәҗбүр итүче мәхәббәт кенә кирәк. Һәм ул үзе килде, үзе җанымны яулап алды. Юкса әүвәле үземнән кимендә алты яшькә өлкәнрәк булган мөгаллимәм күңел сараенда урын алырга өлгерде, аннан сыйныфташым, күп кенә сабакташларымның башын үзе дә белми әйләндергән Нәзиләгә дә кол калырга әзер идем. Барысы да ялган, мәгънәсез бер кызыгу, җанның илаһи хис таләп итүеннән генә булган икән. Моның өчен мөгаллимәм бер дә кулай түгел, чөнки ул һәр көн диярлек үз предметыннан дәрес уздыра, сөйли һәм, иң күңелсезе, өй эшләрен сорый. Җавап тотарга һәрвакыт әзер булсам да, чит тел — күңелсез фән.

Әйе, мин ул вакытта — гади авыл малае, туган-үскән якларымнан беркая да, беркайчан да, бер генә тапкыр да китәсе түгел идем. Шул хәрби хезмәткә генә барып кайтам да, үземне күмхуҗ эшенә багышлыйм дип белә идем. Һәр адымым, яшәр көнем билгеле булып, җәен печән һәм утын әзерләп, кышларын мал ашатып, эшкә йөреп гомерем үтәчәк. Менә шул сәбәптән предметы кирәксез дип уйланылган мөгаллимәмә гыйшык тотуым уңайсыз, мәгънәсез, икейөзлелек булыр иде кебек тоелды. Боларны гына бик яхшы аңладым. Илаһи азык таләп иткән җанымның ишекләрен мөгаллимәм өчен шапылдатып бикләп куйдым. «Чөйне чөй чыгара!» дигәндәй, бушап калган урынга Нәзиләбез, Хәзифәбез, Җәмиләбез һәм дә тагын әллә ничәүләр килеп кермәсеннәрме! Сабакташ башлары белән нишлиләр алар минем күңел түрем-

дә? Аларны болай да көн саен күрәм, ни дәрестә, ни тәнәфестә тынгылык бирмиләр, башымны катыралар, шаярталар. Артларыннан ничә егетләребезнең күзләре «Ильич лампасы»дай гөлтләп калалар. Ә алар, юктыр, бәлки, Нәзиләсе генәдер, мине дә үзенә колы итмәкче! Бирешмәм, булмас! Чибәрлек белән генә түгел шул әле... Сере дә булмагач, нинди мәхәббәт ди инде ул. Шулай түгелме?

Кыскасы, илаһи мәхәббәт өчен Гөлия генә кулай икән, дигән фикергә килдем. Минем алай уйлавым аның горурлыгына тиярга тиеш түгел иде. Җитмәсә, ул үзе миңа беренче булып эндәште түгелме соң? Күрше сыйныфта укуы сәбәпле, көнгә бер яки ике генә күренәчәкмен. Теңкәмне дә катырмаячак. Мәхәббәтемне тоеп йөрсә — шул җиткән!

Әмма шушы мәхәббәтем аны кимсетер дип башыма да китерә алмый идем. Уңны-сулны җиде кат үлчәсәм дә, акылым бар якны да бәяләп җиткерергә өлгермәгәнлеген белмәдем. Ишетүемчә, күрше малае, аның агай-энесе сөйләде, имеш, Гөлия укуда алдынгылардан исәпләнсә дә, бик алай ук булганнардан түгел икән, әнисе укытучы, шул исәптән генә билгеләрнең яхшысын яклап куялар, ди. Җитмәсә, өйләрендә дә корыдан гына тоталар.

Бу сүзләргә ачуым кабарды. Кеше өстеннән кешенең гайбәт сөйләргә, хәтта туганы булсын, ни хакы бар? Нигә Гөлияне кимсетәләр? Моңа юл куярга ярамый! Яклаучысы булуым зарур!

Мин шулай дип уйладым.

Әмма Гөлиягә минем кирәгем чыкмады. Аны бер күреп калуым белән генә чикләнсәм, борын асларына юка һәм бала йонлы мыек җибәргән бүтәннәр хәтта сөеклемнең капка баганасына сагыз кебек ябышырга әзер иделәр. Җәй буе күмхуҗ эшендә җигелүем сәбәпле, күп кенә яңалыкларны белми, вакыйгаларны күрми калганмын. Чөнки мин эштән кайтып, атымны тугарып, тиз генә өстемне алыштырып, клубка чыкканымда инде аның зур ишегенә олы-калын йозак эләргә өлгерәләр. Гөлияләрнең капка төпләренә килсәм, анда бүтән егетләр сайрашып утыралар. Урамны гына урап кайтырга мәҗбүр булам.

Шулай итеп, мәхәббәтем тагын да илаһирак төс ала барды. Җәй узды, мәшәкатьләре белән көзнең дә беткәнлеге сизелмичә калды. Яратканымны Гөлия, мөгаен, үзе дә белми иде. Ничек тә сиздерергә, әйтергә кирәк, дип уйладым. Чөнки болай ук, ялгызым гына утта яну дөрес булмый кебек.

Ул вакытта хисләремнең тәэсире аркасында шактый гына шигырьләр язылган идеме, әллә алар нәсер катнашмы, ничек бар — шулай, дидем дә, бер дәфтәрчек ясап күчереп, аларны үзенә тапшырдым. Иптәш кызлары белән бергә ул аулак өйдә иде. Сөйләшүебезне ишек артында тыңлап тордылар. Аның җавабы нәкъ көткәнемчә булды:

— Юк, яратмыйм мин сине!

— Яшерми турысын әйткәнең өчен рәхмәт!

Нәрсә дия ала идем? Ул уйга калды. Ә бераздан кереп китте, ә мин, башымны түбән салындырып, сагыш хөкеменә бирелгән хәлемдә, кар ерып каядыр киттем дә киттем. Аннан соң тукталдым. Юлымны ачыкладым һәм өйгә таба атладым. Адашмадым, буталып йөрмәдем. Илаһи мәхәббәтем мәрхәмәтсез утында җанымны көйдерде. Кабат Гөлиягә якын да килмәдем. Ялгызым гына көйдем дә көйдем. Күңел түремдә саф һәм гүзәл сурәте балкыды. Күңелемдәге Гөлия белән тормыштагы Гөлиянең икесенең ике кеше икәнлеген белмәвем һәм белергә дә теләмәвем мине гыйшык шәрабы белән исертте. Ләйлә дип үләр хәлләргә җиткән Мәҗнүн сыйфатлырак идем. Бу халәт акылыма айнырга ирек бирмәде, хәтта авылымнан алып чыгып китте. Унынчы сыйныфны бетерүгә, Казанга юл алдым, университетка барып кердем. Ул да шушы ук шәһәрдә, әмма бүтән уку йортында иде.

Беләм, авылдашларымның, бигрәк тә аның, барып хәлен белешмәү — яхшы түгел. Шулай дөрес була дип, бала чагымнан ук өйрәтеп үстерделәр. Һәммә таныш-белеш тиешлеләргә баргалыйм. Анда-санда Гөлиянең дә ишек төбенә киләм. Тулай торакларын усал апа саклый. Эчкә уздырмый. Ә Гөлия төшми. Сәгатьләр уза, кич җитә, кайтып китәргә туры килә, ә кайвакыт, мөгаен, бу ямьсезлеге өчен берәрсе ачулангачтыр, иптәш кызларыннан кемне дә булса ияртеп, тугыз катлы торакларының үзе яшәгән икенче катыннан чыгып, күренеп китә. Хәлен сорашам һәм кайтырга чыгам. Ә миңа шул җиткән. Яратмавын да беләм. Мыскылланам. Әмма рәнҗергә хакым юк. Ул вакытларда мин елаган кадәрле һичкем еламагандыр... Ә илаһи мәхәббәтнең, вакыт-вакыт май тамызсаң, уты сүнә, имеш.

Шулай гомер агышы минем тормышым корабын үз җаена куа бирде. Кыштан җәйгә чыгам. Әмма чөйне чөй бәреп чыгара алмый газаплый. Бу кагыйдә илаһи мәхәббәт өчен канун түгел икән шул. Ул үзлегеннән пыскып сүнәргә тиешле.

1979 елның ахыргы көннәрендә хастаханәгә керергә мәҗбүр булдым. Студентның бердәнбер артык әйберсе булган сукыр эчәгесе шартлады. Тукланырмын дип алган кефирым бозык булган, ахрысы.

Ә нәкъ Яңа елга сигез сәгать кала сихәтләнгәнемне дәлилләп, мул рәхмәтләремә сөенеп, хастаханәдән чыгарып та җибәрделәр. Кайтышлый, юл уңаенда дусларымның берсенә кердем. Ә ул мине Яңа ел бәйрә-

менә чакырылган җиренә бергә барырга өндәде, авылдашлары янына. Нигәдер уңайсыз кебек иде, яратмасларын алдан ук тойдым һәм шулай булып та чыкты.

Әмма дә аңа ияреп киттем. Барып кердек. Ә аларда — сыгылып торган мул өстәл. Мин андыйны күргәнмени?!

Безгә дә урын табылды. Ә монда, мине хәйран итеп, Гөлия дә түрдә, егет кочагында утыра. Гүяки аларның туйлары диярсең. Әллә кайчаннан бирле яратышып йөрешәләр икән. Белмәгәнмен шул, белмәгәнмен... Белсәм ди, шуннан?.. Хәерсез, ахмак, ике гөл уртасында үсеп чыккан тигәнәк булганмын икән шул мин!.. Йа Ходаем, ярлыкый күр, бир мидәт!..

Бу хәл мине шулкадәр оятка калдырды ки, авырлыгыннан җаным әрнеде. Гөлия белән егете миннән дә, башкалардан да һич яшермичә кочыштылар, үбештеләр. Гүяки Яңа ел кичәсендә түгелбез, искәрткәнемчә, туйларында утыра идем. Бергә укыган, бала чакларыннан дус булып йөргән иптәш кызлары да янында иделәр. Аларның миңа өнәмичә карап-карап куюлары, нишләп утырасың, синең урын монда түгел, кит, дип әйтергә теләүләре бәгыремне телде, һәммәсе бердәм мине чокырга төртеп төшергәндәй тоелдылар. Моңа кадәр аларны якын итсәм, хөрмәтем белән бар булган яхшы мөнәсәбәтемне күрсәтсәм, хәзер суынып, кимсенеп, хәтта авыраеп калдым. Моңа кадәр күңелгә дәрт биргән, акылны камап торган илаһи мәхәббәтем эреп юкка чыкты. Үземне канатсыз кош кебек тойдым. Шигырьнең, әдәби иҗатның тәме һәм назы бетте. Атылдым-бәргәләндем. Кая барырга, нишләргә, нинди утларга керергә белмәдем.

Бу — хушлашу тәэсире дә иде, чын мәхәббәт белән хушлашу тәэсире. Хис һәм тойгы мөлдерәмә тутырып торган күңелем бушап калу аркасында акылым да төпсез чиләктәй иде. Нишли ала идем соң, нишли ала? Кайларга китим?

Һәркайда Яңа ел тантанасы, бәйрәм...

Әйе, бәйрәм... Җырладым да, биедем дә, көлдем һәм елмайдым да. Әмма җаным елый иде. Моңа кадәр белмәгән-тоймаган авырлык бәгыремне басып тотты. Һичкемгә ышанычым булмады. Бер генә чибәр кыз да ярдәм итә алмады, минем хисләремне яңартмады. Күзләремнең пәрәнҗәләре ачылды, әмма күңелем буш иде. Аның бүлмәсенә һичкем очраклы гына килеп кермәячәк иде инде. Мин тәмугның үзендә идем.

Яңа елның тәүге киче буранлы булды. Бәйрәм табыннарыннан халык урамнарга агылды. Кайсылары тау шудылар, юләр саттылар, уйнадылар, шаярдылар. Гөлия белән егете аеруча бәхетлеләр иде. Уеннарына катнашмау өчен сәбәбем булганлыктан — хәер, алар мине катнаштырмас та иделәр — читтән генә боларның җәннәтәгедәй шаярышып-көлешүләренә, олы бәхетләренә, көнләшеп түгел, инде сокланып карап тордым да төнге буш, озын һәм ятим Казан урамы буйлап үзем яшәгән тулай торактагы шыксыз бүлмәмә кайтып киттем. Күз яшьләремне болгатып, әрсез, салкын, куе буран уйнады. Кайтып кергән чагымда инде офык яктырып килә иде. Әмма бәйрәм бетмәгән икән. Залда ике-өч кыз һәм берничә парлы ярлар назланып бии иделәр. Мине күреп алып, үзләре янына дәштеләр. Беразга читтәрәк кыенсынып тордым да... Бу дөнья йөзендә миннән дә ялгыз һәм ятим кеше юк иде төсле. Аларга кушылдым. Шыксыз урамда буран котырды. Ә монда, яңа дусларым янында, җылы да, җырлы да иде.

*Ноябрь, 1998*

# Сөю-сәгадәт алмасы

Галиәхмәтнең кыл да сыйдырмаслык вакытында Мөнирәнең шалтыратуы гына җитмәгән иде. Нәфесе кузгалып, тагын да кабалана башлады. Сүзләренә ярым-йорты кәлимә кисәкләре ялганып, бәхете камиллек дәрәҗәсенә ирешә язды.

— Мин теге юлы ялгышканмын,— диде Мөнирә, Галиәхмәтнең теләк казанына утынның корысын өстәп,— үпкәләгән идеңме әллә? Шалтыратканың да юк...

— Әйе, ни, алай...— дип, юк-бар кәлимәләре белән Галиәхмәт мөгердәп утыра бирде, эшенең тыгызлыгы, җитмәсә, яшерен нәфесенең кузгалуы, моңа өстәп тагын да Мөнирәнең гафу сорагандай үртәве аны тәмам бетереп ташлады. Уҗымга бәйләнелгән бозау хәлендә бар дөньясын онытты...

Мөнирә — чибәр ханым. Ялгызы бер кыз бала үстереп, табиб ирен әллә кайчан куып чыгарган, гомерен шанлы бер агентлыкта вак-төяк хәбәрләр язып уздыруда иде. Аның кара озын чәчләренең һәр бөртегенә берәр ир ябышырга, кызыл якут иреннәренең тәме өчен, бер кичкә булса да, үз һәм җәмгыяви кануннарына хилаф итәргә әзер. Хәер, Мөнирә вакытын һич кенә әрәм уздырмый, әле чәчтарашханәдә, әле бизәнү көзгесе артында сәгатьләр буена утыра, һаман да ир-атлар арасында була, кырыкмаса кырыгы белән таныша, яшьлеген дә, чибәрлеген дә, хәтта хатыннарда гына файдага ярый торган беркатлылыгын да эшкә җигә. Аның иң яраткан урыны — кәшәкә тамашасы, ягъни хоккей. Таза-таза ирләрнең тиргә батып бердәнбер алка артыннан куышып йөрүләре — үзе бер ләззәт, уен күрергә теләүчеләрнең, ачылып китеп,

ара-тирә Мөнирәне дә күзләп: «Аһ, чибәр!»— дип онытылулары — икенче бер рәхәтлек. Болар арасында иң килбәтсез хатын-кыз да тутый кошына гына Ходай тарафыннан бирелгән күркәмлек сыйфатына керә, күзләренә дөнья бәһасе торырлык гүзәлкәйдәй күренә башлый инде. Базарда гына ул, нинди матур кош булмасын, әгәр дә сәгатьләр буена сатлык товарын алучыга сылау хәсрәте белән басып тора-тора, ахырда йолкыш тавык кыяфәтенә керә.

Мөнирәнең чибәрлегенә шулай да Галиәхмәт биһуш кешеләрдән түгел иде. Әмма дә тәэсирсез-җансыз ир-атлар хисабында да булмады. Бодайны җил җилгәрә, адәмне — мәхәббәт дигәндәй, аның бер тузынып, югалып алу уенда бар, әмма кулыннан гына килми. Моның сәбәбе акчасызлык һәм хәйлә ятьмәсен хатыннарның тыштан тын күренгән күңел күлләренең төбенә сала белмәвеннән түгел, бәлки күптән инде егетлек яшеннән узып барганлыгын төшенмәвеннән иде. Гомернең шәп чаклары да була икән ул, алары да уза икән. Егет чагыннан тормышка чумып, ир уртасы чорына ирешү белән генә дә шул итагать аталган йөкне җилкәдән селкеп ташлау мөмкин түгел шул.

— Очрашырга иде...— Галиәхмәтнең бу тәкъдиме авызыннан үз теләкләре белән, мантыйкый сәбәп илә чыкканлыктан, Мөнирә дә элеп кенә алды:

— Кайда, кайчан?..

Ялындырырга исәбе юк икәнлеген юри сиздерде ул. Кармагына Галиәхмәтнең күңел күле төбендәге хыял шыртлакасын каптыруга, аны суырып та чыгарырга өлгерде:

— Бәлки, театрдадыр?

Мондый ук әрсезлек Галиәхмәтнең планына керми иде. Ярты Казанны җыя торган «Бәйрәм концерты»на йөрергә бер дә исәбе юк аның. Әмма аның хыял шыртлакасы Мөнирәнең табан астында бәргәләнә иде инде. Телефонның ике башындагы ике як та авыр итеп тын алыштылар. Әгәр дә телефон челтәрен исәпкә алмасак, авызга авыз куешып сөйләшкән кебек иделәр алар.

— Ә үзең килеп чыксаң?

Галиәхмәтнең тәкъдимен Мөнирә шунда ук кабул итте. Әмма ялындырырга булдымы, мутланырга маташкан ирнең әлеге дә баягы хыял шыртлакасын киредән күңеле төбенә ташлады. Мескен, урын таба алмыйча, кысылып калган күңеленең ярыннан ярына ташланды.

— Бүген хезмәттәшем Хәйфиянең туган көне иде. Аннан соң, ни, элеккесе кебек бәйләнеп интектермәсәң генә!.. Сүз бирәсеңме?

— Сүз бирәм! — диде Галиәхмәт, һәрхәлдә, чынга ялганны катыштырып һәм бу вакытта Мәҗнүн кебек дивана хәлендә калганлыгын тавышының йомшаклыгы белән раслап.

— Ярый, алай булса килермен! — диде Мөнирә, тантана итеп.

— Көтәрмен!..— Галиәхмәт бөтен барлыгы һәм юклыгы белән тулысынча Мөнирәнең ятьмәсенә уралды. Телефонын куйганында инде тәмам хәлсез иде. Имза алдырыргамы дип, бу вакытта кәгазьләр күтәреп кергән урынбасары Сәкинә Хәкимовна, гөл йөзен сулдырып, тәүфыйклы күзләрен акайтып, хәйран калган хәлендә аңа карап тора иде.

Галиәхмәтнең ни хакында озаклап сөйләшүен төшенмәгәнлектән, аның ачуы килдеме, әллә бутәнме, күзләре усал караш белән төбәлгән иделәр. Бу битәрләү иде. Ризасызлык. Хатын-кызлар шулай инде алар, балалар кебек, үз кул астында эшләгән ир-атларны сөйкемсез уенчыклары урынына, хуҗаларын — ирләре, хәтта уллары мәртәбәсендә күрәләр.

— Нәрсә бар иде, Сәкинә Хәкимовна? — Телефон трубкасын ашыкмый гына урынына куйганнан соң, ханымның усал күзләре белән очрашкан Галиәхмәт үз урынбасарына өстенлек һәм кызгану хисе катыш тәвәккәллеген яшермичә карап куйды. Дөньяның бөтен ямен җыеп, ирләр коллективында чәчәк атып йөргән Сәкинә Хәкимовнаның бу рәвешле сулып төшкән хәлен ул әлегә беренче тапкыр күрә иде. Җавабын да ишеткәч:

— Телефоннан бик озак сөйләштегез...— Галиәхмәт акланырга мәҗбүр булды:

— Баш катыралар инде, кирәк кешем иде...

Ялганлады. Мөнирәне бер кочаклап йоклау хыялы аның күңеленә кереп ояларга өлгергән инде. Алар элегрәк үк телефоннан гына танышкан иделәр, менә якынлаша да баралар. Дөресен әйткәндә, Мөнирә, агентлык хезмәткәре буларак яңалыклар җыйнаган чагында, аның телефонына туры килде. Матбугат сәхифәләрендә үз исемен укып куаначагын күзаллап һәм хыялына беркетеп өлгергән Галиәхмәтнең башы күккә тиде, күңеле сөенеч нуры белән тулды. Мөнирәгә кирәген дә, кирәкмәсен дә сөйләп бирде. Шул вакыйгадан соң Мөнирә аңа, исенә төшкән саен, һаман да шалтырата торган булып китте.

Галиәхмәтнең исеме телгә алынмаса да, эшләре хакында хәбәрләр матбугат битләрендә күренгәләде. Әмма ни өчендер аларда әле даталар, әле вакыйгалар буталып, булмаганны булды дип, булганны булмады дип тә белдергәләделәр. Галиәхмәт аларны үзенең иркен холкын сабырлык чишмәсе белән сугарып торган күңеленә бикләп куя барды. Гаугалары чыкмагач, матбугаттагы ул хаталар да онытылдылар. Гәзи-

ттә кем нәрсә язмас, әнә «Вечерняя Казань» белән «Татарстан яшьләре» алдаудан туктамыйлар, ә үзләрен укуы кызык, кемнең генә сөяген юмыйлар. Халык гайбәт ярата инде ул, дөресенә кызык өчен су куша, борчакны шыттырыбрак җибәрә. Баксаң, ялганы да дөрескә чыга.

Сәкинә Хәкимовна аннан тагын да сүз көткәнгә күрә генә Галиәхмәт бүгенгә нинди кичектергесез эшләр барлыгы белән кызыксынды. Имеш, онытып җибәрмәдеме икән?

Аннан соң ике-өч кәгазьгә имзасын салды да өстәлендәге бүтән язмаларында актарына башлады. Сәкинә Хәкимовна бу вакытта чыгып китәргә тиеш иде. Әмма һаман урынында калды. Галиәхмәт аңа шунда гына, нәрсә торасың инде, бар, эшеңдә бул дигәндәй карап алды.

— Бүген тагын төнгә кадәр эшлисезме? — дип сорады Сәкинә Хәкимовна.

— Әйе,— диде Галиәхмәт,— эшләрем күп...

— Иртәрәк китәргә иде...

— Рөхсәт!..

Әмма Сәкинә Хәкимовна бу сүзләре белән Галиәхмәтнең дә эштә соңармавын үтенгән иде дә, аңлатып кына җиткерә алмады. Аларның арасында дустанә якынлык юк иде югыйсә. Үпкәләде булырга кирәк, кисәк кенә борылды да чыгып китте. Бүлмәсендә иркен бушлык тоеп, Галиәхмәт киерелеп куйды. Игътибар үзәгендә булу аның күңелендәге рәхәтлек тойгыларын уята иде...

Ә беркөнне Мөнирә аңа үзе килде. Эшнең тыгыз вакытында, инде аның чакырылып та күренмәве сәбәбеннән, берәр яры йөгерткәннәрдер әле, дип көтүдән туктаган чагында өрфия күлмәктән, ясалган чәч һәм бит белән ишегеннән узды. Галиәхмәт аны бу кадәр чибәр дип күз алдына китерми иде. Урындыгыннан егылып төшә язды. Мөнирәнең шул гүзәллеген, бизәнеп-ясанган хәлендә килүен үзенә аталган дип кабул итте. Әмма аларның бәхете барып чыкмады. Көтелмәгән җирдән Галиәхмәтнең тагын да бүтән дуслары килеп, алар белән мәҗлескә китәргә мәҗбүр ителде. Үзләре белән Мөнирәне дә алмакчылар иде, ул нигәдер ялындырырга уйлады. Ә юк, дөресен генә әйткәндә, бер кибеттән икенчесенә тукталганда, Мөнирәне онытып калдырдылар. Галиәхмәтнең дусларына аның кирәге юк иде, ә үзе игътибарсыз булды. Төнлә, рәхәт йокысыннан уянып, дөнья барышы хакында уйланып ятканда хәтере яңарып, ул мәнсезлеге белән Мөнирәне ничек кимсеткәнлеген аңлап алды. Бәгыре киселде. Аның чибәрлеген уйлап, махсус үзенә аталганлыгын хыял итеп, гүзәллектә тиңе булмаган үз хатынына аркасын куйды. Бусы — үзенеке, әллә кайда качмаячак, ә менә Мөнирә — башка, асылынсаң да, асылын агачның асылына!

Галиәхмәт хыял эчендә йөзде. Мөнирә аңа фәрештәдәй тоелды. Ул аның кибеттә махсус юкка чыгуын да, дуслары арасында бу болын күбәләген бик яхшы белүчеләрнең дә барлыгын белми, башына да китерә алмый иде.

Шунда хатыны кайнар кулын Галиәхмәтнең күкрәгенә куйды. Вакытсызрак иде. Галиәхмәтнең күңел бүлмәсендә Мөнирәнең сурәте бизәнеп утырганлыктан, бер кашык су белән йотарлык хатыны нәфес учагына ут сала алмады. Ул, шулай назлы кочакта Мөнирә хакында хыялланып, йокысын дәвам иттерде. Эшкә килүгә, аңа шалтыратты. Гафу үтенде. Бераз үпкәләгән дә икән, рәхмәт яугыры:

— Сезнең вакытыгыз юк иде шул, хәлегезне аңладым. Үзем соңармасам, икенче төрле булыр иде,— дип тә әйтүенә, Галиәхмәтнең куырылырга әзерләнгән хыял бөреләре кабат чәчәккә күмелде.— Очрашуны, бәлки, кабатларбыз?

— Нәрсәгә?

Галиәхмәт коелып төште. Үзен Мөнирәнең ошатмаганлыгына шиге юк иде. Әмма бу фикере белән килешергә теләмәде. Өендәге чибәр хатынын онытып, бу тавис кошын ничек тә кулына төшерергә уйлап, тиз арада планнар корырга өлгерде:

— Бүген миңа һичкем килмәячәк. Бәйрәм алды. Бераз сөйләшеп утырырбыз...

— Ә аннан соң? — Мөнирәнең алай әйтергә әлегә хакы юк иде.

Үпкәләү төсмерен Галиәхмәт тавышына чыгарды:

— «Аннан соң» дигәнен, бәлки, әйтмәскә кирәк булгандыр?

— Сез шулай уйлыйсызмы?

— Әйе, шулай уйлыйм! — Галиәхмәт алдый иде. Теләге бөтенләй башкача булганлыктан, ничек тә тел төбен яшерергә омтылды.

— Сүз дә бирәсезме?

— Әйе!

— Нәрсәгә? — Мөнирәнең тел төбен Галиәхмәт аңламый калды, сүзләрен кабат тәгәрәтте. Сөйләшү икенче тапкырда да шул ук үзәннән акты. Сүзләр яңгырының ахырында бу юлы кояш чыгарып, Мөнирә, әгәр дә бер-бер эше килеп чыкмаса, очрашу, һичшиксез, мөмкин булачагына вәгъдә бирде. Көн ахырында үзе шалтыратып белдерәчәген дә әйткәч, Галиәхмәтнең күге түгәрәкләнде. Үз дигәненә ирешкән бала кебек куанды, көне буе кәефле булды. Тавис кошын читлегенә бикләр өчен, мең әмәлен барлады.

Мөнирә аны алдамады. Сүзендә торды, ярты сәгатьтән килеп җитәчәген белдереп шалтыратты. Бүген ул артыгы белән чибәр, һәрьяктан мактап туймаслык, бәхет кугәрчене кебек гөр-гөр генә килеп торучан иде. Җиңел шәрабның шаукымы болай да саташкан күңелен бәйрәмли башлауга, Галиәхмәт, җаен табып, Мөнирәгә таба үрелде. Монысы киреләнгәндәй итте. Үртәлгән ирнең каны кайнарланды, күңеленнән бәреп чыккан хисләренең сабырлык чишмәсе, тыныч кына аккан үзәнендә болганып, нәфес ташкынына әверелде. Иреннәргә ирен балы ябышуы гына аңа аз кебек тоелды, кочакка кочак кына да тар кебек иде. Әмма Мөнирә әйтеп куйды:

— Ә сез сүз биргән идегез!

Галиәхмәтнең бозавы үкерде, хисләр ташкынын боз каплады. Ул артка чигенде. Шулай да әйтеп куйды:

— Иреннәрең татлы икән!

Мөнирә аңа кушылды:

— Сингә кучүебез яхшырак!

Шуннан сүзгә-сүз ялганды. Әмма уртак темаларының диңгезе ике-өч кәлимә алышу белән саекты да калды. Аларның икесенә дә бер үк ләззәт кирәк булса да, биргән антын Галиәхмәт әлегә боза алмады, хисләр бозавы инде тоз ялау белән мәшгуль иде. Мөнирә һаман да үрти торды. Затлы кигәннәрен төзәткәндәй итте, ирләрне эт халкына тиңләп, нотык боткасын тугылады, коелырга өлгергән кершән һәм иннекләрен яңартты.

Инде вакыт соң иде. Тавис кошын читлек янына китереп тә бикли алмаган Галиәхмәт, Мөнирәнең ирен читен үбүдән генә канәгатьлек табып, барча ирләрнең дә хатын-кызга кызыгудан, аларны үзләренеке итү теләгеннән ерак китә алмаулары хакында үгет-нәсихәтләрен тыңлап, бу сөйләшүдән тәмам арып һәм йончылып, үзенең кемлеген онытып, һәм өметен сүзләр бозы астында калдырып, тизрәк бу очрашуны туктатырга, һәм өенә кайтып китәргә ашыкты. Мөнирәне, бәласеннән башаяк дип, таксига утыртып, юл акчасын кулына тоттырып җибәрде. Шушы ханымның мәгънәсез нотыгы, аның ирләр хакында әйткәннәренең һәммәсен дә хатын-кыз турында, дип тә билгеләргә мөмкин иде.

Галиәхмәтне үз өендә чибәрләрнең чибәре, асыл кошлардан да асылрак күркәм хатыны көтә иде. Кайтып, аның мәхәббәт кояшында җанын җылытты. Әмма үзенең никадәр зур ахмаклык эшләми калуын әлегә төшенеп җитмәгән иде...

Инде менә Мөнирә аңа кабат үзе шалтыратты, элекке очрашуда сөйләгән сүзләре өчен гафу үтенде һәм, һичшиксез, килеп чыгачагын белдерде. Галиәхмәтнең хисләре камилләнеп, җаны җиде кат күктәге җәннәт бакчасының чәчәкләрен өзә иде. Сәкинә Хәкимовна гына, оҗмах сакчысы Ризван кебек, аны аннан сөреп чыгарды:

— Аллага шөкер, ярый әле үз хатыным мондыйлар рәтеннән түгел! — дип, Галиәхмәт үзалдына сөйләнеп маташты, Сәкинә Хәкимовна килеп керә күрмәсен дигәндәй, ишеккә карап куйды. Бу юлы ул ачылмады. Галиәхмәтнең күңеленә рәхәт тынлык иңеп, эш вакытының ахырына җиткәнен көтте. Минутлары артыннан сәгатьләренең дә ничек узганлыгы сизелми калмады. Көн кичкә авышканда, Мөнирә аңа кабат «кояшын чыгарды». Гүяки дөньялыкның бөтен нурларын үзе белән бергә балкытып алып керде, Галиәхмәт күз алларының әлҗе-мөлҗе килүеннән аңсыз иде. Үбешү һәм кочышу ниятендә Мөнирәгә сузылды, әмма бернинди дә каршылык тоймады. Бу хәл аңа бик тә гаҗәп кебек тоелды.

Инде дә Галиәхмәт комсызланмакчы иде, Мөнирә җай гына сүз кузгатты:

— Машиналарыгыз яхшы сатыламы?..

Аның болай сөйләве һәм соравы Галиәхмәткә яңадан җан кертте. Ул, тагын да кукраеп, кемлеген белгән хәлдә мактанып та куйды:

— Әле конкурс игълан иткән идек.

— Хәбәрдармын,— диде Мөнирә, кыенсынгандай итеп өстәп тә куйды: — Анда мин дә катнаштым, машина otarга өметләнгән идем...

— Ә-ә, шулаймыни? — Галиәхмәт тагын Мөнирәгә үрелде, бит очыннан үбеп алды. Каршылык күренмәде. Шушы чибәр кочакта мәгәрем эриячәген уйлаган ирнең тәне кайнарланды, күзләренә шайтан чарының очкыннары төште.

— Ничегрәк булыр икән?

Мөнирәнең бу соравын Галиәхмәт аңлап җиткермәде. Сукыр үгез кебек мөгердәнеп, ханымның чәчләрен иснәде. Акылы шашынып өлгергәнче, Мөнирә тагын да өстәп әйтеп куйды:

— Минем дә машинам юк иде...

— Ничек? — Галиәхмәткә бу хәл бик тә сәер кебек тоелды.— Бүгенге көндә машинасыз кешеләр дә бармыни?

Мөнирәгә оятрак булып китте. Барлык серләрен дә чишәсе килми иде аның. Галиәхмәт исәрләнеп ашкынды, кабалануы сәбәпле, маңгаена тир бәреп чыкты. Сәкинә Хәкимовна калдырган кәгазьләр арасыннан конкурс йомгаклары язылган белдерүне эзләп тапты һәм:

— «ВАЗ» машинасы ярыйдырмы? «Жигули»? — дип, Мөнирә ханымга күтәрелеп карады.

— Соңгы моделен... «Универсал»!..

Бу җавапны ишеткән Галиәхмәт, шунда ук язып-сызып, таныклык сузды:

— Алыгыз! Бүгеннән сез дә машиналы, тәбрик итәм! — дип, зур канәгатьлек белән авызын ерды. Хәзер генә түгел, якындагы берничә ел буена аның борчагы яхшы пешәчәк иде.

Ә Мөнирә исә:

— Әллә ничек инде,— диде, киреләнгән сыман. Әмма таныклыкны алды, укыды.

— Формаль якларын теркәү бүлегендә тутырырсыз!..

Галиәхмәт бу сүзләрен әйтеп тә бетермәде, ишектән бер кыз бала иярткән төссез ир заты күренде. Керә-керешкә әйтеп тә салды:

— Хатын, күпме көтәргә була?

— Ә, Гариф, кер-кер, кер әле... Менә Галиәхмәт әфәнде белән таныш. Дөнья дусларсыз бармый ул! — дип, Мөнирә сикереп торды, ире дигәненә хуҗаларча урын тәкъдим итте.

Галәмнең күрке булган кояш болытлар артына кереп качтымыни, тутый кош читлек янында койрыгын гына болгады да очып китте. Галиәхмәт урындыгына сеңеп калды. Үзенең юләргә чыгуын төшенгән, әмма акылыннан яза баруын тоймаган хәлендә һәм бер ноктага төбәлгән сурәттә бик озак утырды. Мөнирәләрдән соң аңа бу көндә керүче дә, чыгучы да булмады.

*Май, 1999*

# Күз яше сере

Әсәретдин абый сөлек кебек кыз үстерде. Аның гүзәллеге җырларда җырланачак, шагыйрьләр һәм язучылар теленә керәчәк, егетләрнең төн йокыларын алачак иде. Әмма авыл халкы эш ярата, чибәрлекнең түйда гына кирәк булачагын белеп яши. Шуңадыр үлеп гыйшык тотарга бик алай җайлары да калмый. Ә менә Әсәретдин абый, мәсәлән, үз хатынын үлеп-үлеп, юк-барга да көнләшә-көнләшә, үз шик-шөбһәләреннән мыскыллана-таушала ярата, җаны өзелеп, бәгыре өзгәләнеп сөя белде. Бу мәхәббәтенең үзенә Аллаһы Тәгалә тарафыннан бүләк ителеп бирелгән бәхет икәнлеген төшенеп үк тә бетерми иде. Киресенчә, бу хисләре аңа авыр, санын изүче газап кебек тоела, чөнки хатыны тойгыга — хиссият, шатлыкка — куаныч, бәхеткә сәгадәт белән җавап бирә белүчеләрдән түгел шул. Ә монысын, әйтмәсәләр дә, Әсәретдин абый үзе дә бик яхшы белә иде. Шунлыктан кызына һаман да бәхетләр генә теләде. Бу баласы бигрәкләр дә кытай пыяласы шул! Икенче кызы өчен алай ук борчылмый, анысының корылыгы әллә нинди диңгездәй ташыган хисләреңне корытыр. Ә улы, ягъни соңгы өченче баласы, әлегә сабый иде.

Олы кызы, ягъни чибәрләрнең дә чибәре булып үсеп җиткән Бәриясе артыннан егетләр борын төпләре кибеп җитмәстән йөгерә башладылар. Тик берсен дә саф мәхәббәт хисләре белән тулы кыз колач җәеп көтеп тормаган булып чыкты. Бәрия килде-киттегә һич сер бирмәде. Егетләрне итәге тирәсендә генә әйләндерә дә, башларын хыял боламыгында тәмам болгатып, юкка чыга. Чәчәкләр арасында сайланып очкан күбәләктәй, ул да эзләнә, лаеклы тиң ярының һичшиксез табылачагына ышана, янында меңнәр булса да, нәкъ шуны, бердәнберен көтә. Әмма аның әлегә кайдадыр адашып йөрүенә ачуы да килә иде. Шунлыктан ул аны үзе эзләп китәргә булды. Әсәретдин абыйның исә моңа рөхсәте юк иде.

Ә Бәриясе Казанга китеп барды. Аның артыннан авыз суларын корытып йөргән егетләре дә олактылар, ягъни дә мәсәлән, уҗым бозаулары кебек иярешеп, калага таба юл алдылар. Анда — демократия, анда иркенлек иде. Авыл үзенең кысынкылыгы, мөмкинлекләренең тарлыгы белән һәр баласын исән-сау йөрегез, дип озатып калды, кайтмасланмы дигән өметтә төннәрен гүяки саташудан уянып китә дә, сагынуларын кая куярга белмичә елый иде булырга кирәк, ахрысы. Әмма шәһәр иркенлекләре һәм чуарлыклары, төзеклекләре һәм ялтыравыклары белән үз кысаларына бөтереп алган иде инде аларны, һәм тулысынча буйсындырды. Сөлек кебек кыз Бәриягә кала гына түгел, инде бөтен дөнья кызыга иде, дисәк тә, ялгыш булмас.

Аның янына хәл белештерү сәбәбе белән килеп чыгучылар да аз түгел. Үзләрен иркенрәк тотарга өйрәнеп алган авыл егетләре шәһәрчә кылану гынамы соң, арттырыбрак та җибәргәлиләр: кайсылары мәхәббәтләрен яшермичә белдерергә батырчылык итсәләр, кайберләре Бәриянең чибәрлегеннән телсез кала, йөрәкләре яраланган хәлдә гыйшык дәрьясында гарык була бара. Чөнки кыз үзе генә һаман сер бирми, әле анысы белән, әле монысы белән бераз шаяргалый да, беришләренә кочагын да ача һәм, иреннәрен-

нән дәрт шәрабын эчертеп, аларны шунда ук сәрхуш хәлләрендә калдыргалый, һәм дә мәхәббәт бакчасында үз акылын җуймый гына гизә иде.

Кешеләр шундый инде алар: сүз сөйләшми тора белмиләр. Бәриянең күңелен яулап алу кулларыннан да, акылларыннан да, буй-кыяфәтләреннән дә килмәгән егетләр:

— Мин аның белән кич кундым!.. Кочагының рәхәтен татыдым... Тыштан гына гөнаһысыз икән,— дип, юк-бар сүзләр чыгарып, бөтәннәрнең күңелен аннан суытырга, шулай кызны үзләренеке итәргә тырышып, болганчык гайбәт елгаларын күп агыздылар.

Тел машинасы болар өчен сафсата онын тарта түгел, хакыйкать балын сыга идеме, белгән юк, әмма ләкин бер колаклыларын икенче колаклылары алдый торгач, үз ялганнарына ышанып та беттеләр. Гайбәт авылга да килеп ирешми калмаячак иде.

Бәрия исә һаман да кызларның солтаны булды. Шунлыктан арада бер-бер ханзадәнең барлыгына һәм үзенә насыйп ителәчәгенә өметен өзмәде. Дөрес, андый егетнең ханлык тәхетен тотуы шарт ителмәсә дә, әмма дә йөрәк тәхетенә менүе һичшиксез сорала иде.

Кемнәрнең күңелендә нәрсәләр барлыгын кайлардан белеп бетерәсең? Монда әле үз-үзеңне аңлап җиткереп булмый. Ә Бәриянең күңеле олы мәхәббәт көтә иде. Бу «олы мәхәббәт» дигәне пеләш башлы да, аксак-туксак та, чулак та, сукыр да, саңгырау да булырга тиеш түгел. Дус кызлары инде кайсы кияүле, кайсысы егетле генә булса да була тордылар. Бәрия артыннан черки-чебен кебек гөжләшеп асылданасыл, гайрәтледән-гайрәтле, чибәрдән-чибәр генә яшь-җилкенчәкләр җилкә киереп йөрсә дә, озакламый алары да тарала башладылар.

Әнисе генә:

— И кызым, баштарак солтан кирәк була ул, аннары олтан да ярый башлый... Үзеңә тиңеңне сайлап ал инде,— диде, ничә тапкырлар кызы өчен хәсрәтләнеп, хатларында үгет-нәсихәтләр бирә-бирә.

Аның өчен Бәриянең башлы-күзле булуы, гаилә корып, ярты хәсрәтеннән ата-анасын азат итүе кирәк иде. Кызының исән-саулыгына, бәхет-шатлык насыйбына никадәр догалар укытты әнисе, яхшы иргә тәтүен теләде. Юк кына!

— Әллә, Ходаем, Бәриямнең күңеле чуар инде? — дип, әнисе хәсрәт чигә башлаган иде инде, җәйге ялда авылларында яткан кадерлесенең шулай ук Казанда укыган җиреннән кайткан бер егет белән сөйләшеп торганлыгы хакында ишеткәч, йөрәгә жу итеп куйды: — Бу бит теге Хәбибҗан малае түгелме соң? Ничә кызның башын әйләндерде! Йөри генә башлый да ташлый, йөри генә башлый да ташлый, хәерсез!

Ананың хәсрәте хак иде. Ишетелгәннәр буенча, чыннан да, Хәбибҗан абзыйның бу улы телгә галәмәт тә оста, әмма күңелгә артыгы белән чуар булып, бер кичтә ике-өч кызны озатып, ярты авылны талаштырып, яртысын үпкәләтеп бетерде. Ә кызлар, аңа да карамастан, шушы бер кашык сусыз да йотарлык Зарифка сагыз кебек ябыша, иреннәреннән бал өзәргә җан аталар, имеш. Әй, булсалар да булырлар икән! Һай бәхетсезләр, һай буш өметлеләр! Хәбибҗан малае алар насыйбынамы соң? Бәриянең кискән тырнагына да тормыйлар алар!

Ана әле тиргә батты, әле туңды. Бәриясе капка төбеннән таң алдында гына керде. Урынына мыштым гына барып ятты. Йокы күрмәгән анасы аның дәртле итеп еш-еш сулыш алуларын колак тотып тыңлаштырды. Бәриясенең йөрәгә ут булып яна. Һәр сулышы саен мәхәббәт төтеннәре чыга, тәнен генә түгел, бар дөньялыкны чолгый бара иде. Ана бу юлы сүз әйтергә кыймады. Бәхетен киметермен дип уйлады. Һай шунда ачуланган булса иде. Вакытында ул утны сүндерерлек кенә сүзләр табар иде. Юк шул, теле әйләнмәде. Насыйбыдыр инде, насыйбыдыр!

Һәм шулай булды да. Бәриянең күзгә күренеп үзгәрүе, Зариф, дип саташуы көннән-көнгә арта барды. Ананың бу хәлләргә әле сөенгән, әле көенгән чаклары иде...

— Нәрсә, әнкәй?

— Юк, болай гына!..

Бәрия йөрәк серен яшерергә тырышты, анасы да белмәмешкә сабышты. Кызы белән Зарифның гыйшкы телгә алып сөйләнерлек дәрәҗәдә хак иде югыйсә.

Кибеткә яңа товар кайткач, аларны тамаша кылырга һәм алырга ярты авыл җыела торган заманнар бу. Бәриянең әнисе шунда бармый кала аламы соң?

— Хәбибҗанның улы Зариф белән кызым Миләүшә көзгә өйләнешерләр, ахрысы!..— Югары оч Камиләнең бу рәвешле сөйләнеп торуын ишетүгә, ул егыла язды.

— Ничек?

— Менә шулай, Фәгыйлә, менә шулай!..

Әмма бу сүзләр чатан Хафизның кечкенә Фәгыйләсенең колагына дип әйтелмәгән иделәр. Бәриянең анасы юләр түгел, үзенә аталган икәнлекне бик тиз аңлады һәм үзеннән мыскыллы ачы көлү буларак ка-

бул итте. Шунда Хәбибҗанның хатыны Суфия килеп керде. Һәммә кеше аны зурлап, үз итеп каршы алды. Зарифын өйләндерергә җыенуы хакында халык арасында сүзләр йөргәнлеге яшерелми әйтелүгә, ул:

— Нинди сүз бу тагын? — дип аптырады да калды.— Кайдан чыкты?

— Әнә, Камилә бытырдый! — Бәриянең әнисе ачу белән әйтте, әмма Суфия шунда ук үзен кулына алды, бер дә гаҗәпләнмәгән кыяфәт чыгарды. Ул, тынычланырга өлгергән күңел белән:

— Минем Зарифым синең кызың белән йөри түгелме әллә? — дип сорады.

Бәриянең әнисенә җитә калды, Камилә каршында борынын чөйде.

Кибеткә җыелган хатыннарда әлегә товар кайгысы юк иде.

— Миләүшәгә Зариф карыймы соң...— диючеләренә бүтәннәр кушылып:

— Бәрия белән тиңнәр! — диделәр.

Сүзгә кибетче аксак Мортаза кушылды:

— Егет әле утырып җитмәгән, тиз генә өйләнмәс,— дип, үзенең яшьлегендә бер авылдан икенчесенә яшь хатыннар артыннан чабып, исереклеге аркасында салкын буранда йоклап калып, аягын өшетүен исенә алып сөйләмәкче иде. Кырыкмаса-кырык чәйнәлгән мәсьәлә буларак, аңа колак куючы табылмады.

Һәм китте сүз, китте сүз. Диңгез булса, ул да кайнап чыгар иде. Әмма авыл хатыннары бирешә торганнардан түгелләр. Инде алтынчы «круг»ка җитеп, бишенче тапкыр гына кызып килә иделәр. Шунда бәхәсне Суфия чиште:

— Минем малай кайсыгызның кызына карарга үзе белер!

Кибет эчендәгеләр бу кадәр төгәл әйтелгән сүзләрнең тәэсиреннән гүяки егылышып калдылар, урамдагылар аңлашып өлгермәделәр, ә үрдәк йөрешле Суфия, башын югары чөйгән хәлендә, кайтып китте. Шул көннән бирле Зариф та вакытыннан алда йокларга ята башлады. Бер генә кызны да озата алмый иде шул ул хәзер. Һәммәсе юлына киртә куйдылар. Болай яшәп булмасын аңлаган егет ике атнадан Казанга китеп барды. Авылның яшь-җилкенчәге, ул китүгә тынычлап, бәхеткә ирешге. Барысы да парлашып алып, күгәрченнәр кебек гөрләшергә тотындылар. Егетләрнең күңелендә көлке сүз булса да, күңелләрендә: «Зариф кайтып төшмәсен, йөргән җирендә рәхәт күрсен!»— дигән сагышлы һәм үтенечле дога вә өмет иде.

Бәриянең кияүгә чыгуы, туй булачагы дигән хәбәр авылны бер очтан икенчесенә кадәр көнгә кырыгар әйләнде. Ул кода-кодагыйлар, җизни-җизнәкәйләр килеп тулды. Ак келәткә пакь урын җәелде. Бәрияне үз әнисе шунда алып керде һәм, кызының елавын ишеткәнендә йөрәгенә зәхмәт сәнәге чәнчелеп, кайгыга чумды. Нәрсәләр генә дисен икән, ничекләр генә юатсын? Никләр генә шулай сыгылып төшеп елый икән?

— Кызым, ни булды?

Әмма Бәриясе серен чишмәде.

— Кияү керер алдыннан елаган киленнең бәхете мул булыр! — диде иснәнеп йөргән кодагый, келәт эченә узып.

Ул көндә яки төндә Зарифны кайтып килер дип өметләнеп һәм Ходайдан сорап, ялварып, үтенеп көткән бердәнбер кеше Бәрия иде. Ничә тапкырлар елап алды ул, качыплар китәргә дә уйлады. Яратмый иде ул куенына мөгрәп кереп килүче бу булачак ирен, аңа Зариф кирәк иде, ул бары тик Зарифны гына сөя, бары тик Зариф өчен генә туган һәм үскән, бары тик Зариф дип кенә яшәячәк иде. Шуңа да елады да елады. Әмма күз яшенең серен һичкемгә дә чишмәде.

*Июнь—июль, 1999*

# Солдат хикмәте

Авылның да төрле чагы була: эштән бушый алмаган һәм эшсез калган вакытлары да.

Хәзер әллә заманасы шундый, типсә тимер өзәрлек егетләр дә өйләнмичә генә, бала багып мәшәкать чикмичә генә үз көйләренә гомер итәргә гадәтләнеп беттеләр. Элегрәк булса, колак итләрен ашап, урамга чыгарлык йөзләрен дә калдырмас иделәр. Хәер, анысы бер хәл, аның әле сугыш күргән егетләре дә күбәеп киттеләр. Кайсысы Әфганда булган, кайбере Чечняда тау арасыннан чыкмый яткан, ә кеме Югославта итек табанын кимереп рәхәтләнгән. Безнең ил хөкүмәтенең туктаусыз:

— Ул сугышларда Татарстан катнашмады! — дип, тел чайкап күкрәк сугулары ни мантыйкка, ни хакыйкатькә хилаф икән, ягъни — сәясәт!

Ни өчен мантыйкка хилаф? Чөнки Татарстан Рәсәй кул астындагы ил, Рәсәй сугышты исә, Татарстан да читтә калмаган дигән сүз бу! Ни өчен хакыйкатькә хилаф? Чөнки авыллардагы егетләрнең нәрсәләр хакында гәпләшкәннәрен тыңлап кына карагыз! Сугыш күрмәгән кешеләр сугыш хәлләрен болар кадәр үк төгәл сөйләп бирер иделәрме икән?

Бервакыт өч-дүрт егет, бергә очрашып, хатирәләр диңгезендә акыл көймәләрен йөздереп, тәмам адашып беткәндә, аларның сүзләрен сугыш күрми үскән өлкән буын, бүгенге алтмыш-җитмеш яшьләрендәге бабайлар тыңлап утыралар икән дә:

— Һай, дөньяның куркыныч җирләре бар икән, Аллаһ сакласын, бу кадәр дә белеп сөйләмәс иделәр, үзләре күргән, хактыр ла! — дип тел шартлаталар икән.

Ә теге сугыш күргән егетләр һаман да сөйли дә сөйли, сөйли дә сөйли.

Самат Шакиры тукталган урыннан Әхмәтзәки Такташы дәвам итеп китә. Әмма аны Гыйльмулла Әсәре бүлдерә:

— Кара әле, ә син анда ничек барып эләктең соң?

Әхмәтзәкинең кырыкны тутырган буйдак улы Такташ, сүзенә дәлил итеп, аркасы аша кереп, тешеннән, янәсе, үтәли чыккан яра эзен күрсәтә:

— Әллә ышанмыйсың? Пуля! Ядрә бу!

Самат Шакиры, пычык борынын сыпырып, утыз алты яшендә һәм дә шулай ук өйләнә алмаган башына зур мәсьәләне чишү йөкләмәсен алып:

— Дөрес! Үтәли чыккан! Ядрә! — дип, яраның, чыннан да, Чечняда алынган булуын тәкрарлап куя.

Ялган — фаразга, фараз исә хакыйкатькә әверелә! Әмма үзенең тәнендә яра эзе булмау сәбәпле, әгәр дә Әфганда сугышуларын сөйли калса, ни белән ничек расларга икәнлеген дә уйлап, мәгәрем ки андый сорау чыкса, нәрсә эшләргә тиешлеген төгәл төшенә алмый авызын ачык калдыра.

Әсәр — усал егет! Яшьлеге беләнме әлегә акны-караны белеп бетерә алмый. Милиционер диярсең, артыгын төпченә:

— Нигә мине алмадылар да сине алдылар әле анда? — дип, тагын бүлдереп, Такташның бәгыренә төшә.

— Мин, энем,— ди тегесе,— пучаму, путамушту пограничник, ягъни мәсәлән, чик сакчысы, бик ышанычлы, чекист! КГБ!

Солдат хезмәтен үтеп тә, анда да көрәк белән лом гына күргән Әсәр үзенең буеннан зарланып куя:

— Син колга шул!

— Менә-менә,— дип эләктереп ала Такташ,— һәм дөрес әйттең, монысында ялгышмадың!

Озын сүз алдыннан барысы да, тынып калалар. Такташ баш артын кашый-сыпыра да, әллә ничә тапкыр кабатланган сүзне яңартып, ерактан ук китереп сөйләргә тотына:

— Ярый, егетләр, алайса тыңлагыз!

Һәммәсе аңа карап калалар, тын алырга да куркышып утыралар. Такташ күк читендәге болытлар арасыннан күз карашын уратып кайтара да, әүвәле:

— Сез ни беләсез! — дип, зар белән әйтеп куя.

Башкаларның исә бу сүзләренә ачулары килә. Үртәлеп, үпкәләшер хәлгә җитәләр:

— Үзең бик беләсең инде! — дип әйтергә өлгерсәләр дә, Такташ аларга игътибар итми, сөйли башлап, бераз уйга талып тора да дәвамына күчә:

— Безне «Кукурузник»ка төяделәр дә алып киттеләр. Тау башына туры китереп, төртеп-төртеп коя башладылар. «Юк!»— дип киреләнеп тә торырлык түгел. Күзеңне йомасың да сикерәсең...

Таудан түбәнгә тәгәрәшеп төшеп киттең, малай! Мин дә тәгәрим, мәтәлеп-мәтәлеп китәм, башкалар да шулай очып-очып бөтереләләр. Туктап калыр әмәл юк. Хәтергәләштергәләп алам: кайберәүләр, таш кыяга лап итеп кенә ябышып, коймак булып кала баралар. Ә без һаман тәгәрибез. Аларның таулар, малай! Үзләре — биек, үзләре — текә! Безнең Кибән тавы ише генә түгел. Очларында да ак бүрек — боз, кар. Төпләрендә дә шарлавыклы елгалар. Белсәгез! Менә нинди җирләр, менә нинди илләр бар!..

Такташның бүтәннәр белән бергә тәгәрәшеп төшүе бик озакка сузыла. Самат Шакиры түзми:

— Шуннан? — дип куя.

— Әйе, шуннан? — ди, авызын ачып тыңлаган Әсәр, кичәге яртының пары бүген дә башын авырттыруын хәтеренә алып, әмма түзәргә тырышып.

— Шуннан шул! — Такташ бу юлысы сүзен кыска тота: —Тәгәрәшеп төшеп киттек. Өч солдат идек. Бары алтыбыз гына калган, командирыбыз да юк!

— Нишләдегез инде? — Самат Шакиры шунда ук үз белгәннәрен өстәп куярга өлгерә.— Әфганда командирыбызны дошманнар чәкеп кенә алганнар иде. Нәрсә эшләргә дә белмәдек. Анда бит кайттым да киттем юк. Ярый әле тау-таш арасында качып калырга иттек. Бер атнадан соң гына безне килеп алдылар.

— Һи-и-и! — дип куя Такташ, сугыш мәсьәләсендә үзеннән дә зуррак белгеч юклыгын ассызыклап.— Арадан берегезне сайларга иде.

— Ал-лай-й! — Әсәр болардан чын солдат гыйлемен өйрәнеп утыра бирә.

— Менә без тәгәрәшеп төшеп тә җиттек, ә командирыбыз — юк! Тау сыртында үскән агачның ботагына эленеп калган. Ә без — белмибез, «капут» булганлыгына иманыбыз камил. Иптәшләр әйтә: «Әхмәтов, син — старший яшьтә, син бул!»— диләр. Ягъни: «Син — өлкән, синә безнең белән командирлык итәргә!»— диләр инде болар.

Кая барасың, баш тартырга ярамый. Уйлап торасы түгел! Устав кушмый. Монда гына ул ничек телисең, шулай эшлисең. Иске «глава»ны, хакимият башлыгын дигәнем, Залаковны инде, белә идегезме? Кайткач, чакыртып алды да: «Әхмәтов, син анда Чечняда командир булгансың, әйдә, монда да ал күмхуҗны үз кулыңа!»— диде.

— И-и, нигә алмадың? — Әсәрнең рәислек кылырга дәрте кечкенәдән зур булганлыктан, әле һаман да ул саташуы бетеп җитмәгән икән.

— Син нәрсә! — Такташ кызып ала: — Әллә минем башыма тай типкәнме?

— Залаковка нәрсә дидең? — Самат Шакиры тыныч һәм кызыгулык белән сорагач, Такташ үзалдына канәгатьлек мәртәбәсендә сүзен уртага егып сала:

— Монда Устав юк, булмый, иптәш Залаков, дидем!

Әмма аның бу сүзе Әсәргә тагын ошамый. Ачу һәм үкенеч белән:

— Юкка! — дип куя. Һәрхәлдә, бу сөйләшүдә, хакыйкатьтән бигрәк, шыттыру күбрәк икәнлеге башына кереп тә карамый инде.

— Нәрсәсе юкка? — Такташ зәһәр итеп төкерә дә: — Синең кебек ахмаклар өчен җавап бирергә мине дурак дип белдеңме әллә? — дип сүгенмәкче була, әмма сүзен дәвам итә:— Еламыйча кайчаннан гына ашый башладың әле? Җыен букый-сукыйга баш булып йөргәнче, үземә үзем хуҗа, үземә үзем рәис!

Шакир аның белән риза инде. Әсәрнең сүз алып китүеннән куркыпмы, әллә фикерен яшерергә теләмичәме, батырып кына раслап куймакчы:

— Һәм дөрес! Һәм хакыйкать! Җыен тузга язмаганнар техникумнарда югары белем алып кайталар да, сабаннан тырманы аера белмәгән башларына әмер биреп, фәрман кылып яткан булалар. Алар өстеннән рәислек итсәң, эшең уңа димени? Ни кушканыңны белмичә, үзләреннән боргалап һәм бордыргалап бетерәләр!

Әмма аның сүзләре озынга һәм озакка китүдән куркып, әйтелгәннәрне үз башына кабул итеп, Әсәр кирәкмәстән чәчрәнә башлый:

— Нәрсә, миңа төрттерәсеңме?.. Миңамы?.. Бар шул, бар дипломым!..

Болар Шакирга усаллану өчен җитә калалар:

— Ат печәргә дә ярамаган нинди мал духтыры инде ул? — дип, тагын да зәһәррәк итеп Әсәргә төрттерә. Дөньялык бер генә мизгелгә шым була.

Әсәр, бу мыскыллауга түзә алмыйча, шул тынлыкны бозып, чәчрәп капланырдай җәһәтлек белән сикереп тора, кайнап чыккан авыз күбекләренә тыгыла-тыгыла җикереп маташа:

— Менә, печеп биримме?.. Һаман мине мыскыллыйсың да торасың, мыскыллыйсың да торасың!..

Шул кызулыгы белән китеп үк бармакчы итә, әмма Шакир аны тагын да озатарак сүз җибәрә:

— Башы белән койрыгын бутама, яме!

— Бутамам, анысын гына бутамам! — Әсәр читкә китә, араннар һәм фермалар ягына калкулык башыннан озак кына карап тора. Җылы кояш кара бушлатлы аркасын кыздыра, әмма кискен җил якасы астыннан бар җылысын алып китеп бара. Такташ янында ышык урын булганлыктан, Әсәрнең аннан аерыласы килми. Һәм шунысы бар: тыңланасы вакыйгалар, сөйләнәсе сүзләр бетмәгән. Ул кире килеп утырганда, хикәя дә дәвам ителә инде. Мыштым гына, бүлдерми тыңларга мәҗбүр булганлыктан, көләргә дә җөрьәт итмичә, үпкәләве һәм зәһәре чыгып бетәргә өлгермәгәнгә, йомылып кала бирә...

— Мал-лай... Китте атыш, китте атыш! Тыр-тыр-тыр-тыр!.. Пах-пах-пах-пах!..— Такташ тырылдатканда, Шакир да, дәртләнеп китеп, балаларча аңа кушылгалап-кушылгалап алгалый.— Әле мина төшеп ярыла! Дахтадах! Бахтадах! Уңнан аталар бандитлар. Сулдан аталар. Яндарбиев әйтә: «Беттек, Әхмәтов!»— ди. Икенче яктан Радуев йөгереп килде: «Ярдәм ит, Әхмәтов!»— ди. Генерал Грачев та шушында. Итле түшүнкә ашап утыра. Ә үзе: «Бандитларның кирәген бир, Әхмәтов!»— ди.

Шунда ук һөҗүм юнәлешен билгеләп, һәр солдатның колагына нәрсә эшләргә тиешлеген шәхсән үзем аңлатып чыктым. Карап торалар икән чукынчык генераллар. Грачев ул вакытларда оборона министры иде, беләсез. Шул булгандыр әле, миңа: «Иптәш Әхмәтов, хәлнең торышын, сугышның барышын аңлатып бир!»— ди. Әмер итүе инде бу!

Югалып калмадым: «Иптәш, маршал,— мин әйтәм,— өстән һөҗүм итеп, астан бәреп төшерәчәкбез. Иптәш Радуев та, Яндарбиев та борчылмасыннар! Бандитлар юк ителәчәкләр!»— дим.

«Әмер бирәм, фәрман итәм! — дип кычкыра маршал Грачев.— Нәкъ шулай эшләгез, иптәш Әхмәтов, бер дә куркып тормагыз! Генерал Радуевка да җиткерегез! Нәкъ шулай булсын!»

Әйтергә генә рәхәт, тоташ яуган ракета һәм миналарны узып чыгасы, дошманнарны, ә, юк ла, бандитларны кырып саласы бар.

Ярар, тәвәккәлләдек. Беренче һөҗүмне ясадык. Ә алар безнең кайдалыкны төгәл генә белмәгәннәр икән, күреп тә алдылар, дөбер-шатыр китерә дә башладылар. Безнең хәлне белешергә, ярдәм итәргә Җоһар Дудай дигән баһадирны җибәргәннәр икән. Бусы да генерал.

— Сәлам, иптәш Әхмәтов! — дип, ике кулын мөселманча сузып күреште.

Мин дә югалып калмадым:

— Чечняның данлыклы Дудай баһадирына солдатларча кайнар сәлам!— дип, аны сәламләп, сәламен кабул итеп алдым.

— Эшләр ничегрәк? — ди бу, хәзер үк сугышка керергә, бандитларны кырып салырга әзер булып, каршысына сугыш планнарын җәеп салып.

— Нигә чигендегез? — дип, зәһәр үкереп, җан-фәрманга маршал Грачев йөгереп килмәсенме? Үзенең янына Альберт Мәкәшне дә алган бу.

Теге бәләкәй генә нәмәрсә:

— Шимбәләрнең кирәген бирергә, тамырларын корытырга! — дип бии-бии кычкыра.

Маршал Грачевны бармак тибрәтеп кенә үземә чакырып алдым:

— Бу кем бу? — мин әйтәм.

— Мәкәши! — ди.

— Нишләп монда йөри? — мин әйтәм.

— Яһүдиләрне эзли! — ди бу.

— Кемнәр ул яһүдиләр? — мин әйтәм.

— Белмим,— дип тора бит.— Мәкәшинең сүзләренә караганда — бет яки берәр корт булырга кирәк. Рәсәйне басканлыгы гына мәгълүм!

— Ярар,— мин әйтәм,— Мәскәүгә җибәрегез, Думага! Шуннан эзләсен! Казанга телеграмма белән хәбәр бирсен, тапканмы-юкмы,— дидем.

— Юк, китмим!— дип тартыша бит Мәкәши. Бәйләп, башына чүлмәк кидереп, кулына бәрәңге тоттырып, көч-хәл белән Мәскәүгә очырдык. Барып җитмәгән, чукынган.

Әйткән иде аны Җоһар:

— Булмый, ярты юлда егылып төшә бу,— дип, пәйгамбәр, әүлия икән. Нәкъ шулай булды да...

Әсәр түзми, Такташның сүзләрен бүлеп, үзенең белгәнен кыстырып куярга өлгерә:

— Җоһар Дудай үлде бит инде, һәлак булды, ник алдыйсың?!

Такташ мондый юк-бар провокацияләргә генә бирешерлек түгел инде. Теш арасыннан гына төкерек йөгертеп төкерә дә:

— Әсәр белеп әйтә,— ди, Шакирны гаҗәпкә калдырып: —Укыган кеше укыган кеше инде. Бу ат печү генә түгел. Хәреф арасында язылмаганын да аңлый белергә кирәк!

Аның нәрсә әйтергә теләгәнен беркем дә аңламый кала. Әмма үзен яклаганы өчен, Әсәр чиксез шат инде хәзер. Масайган кыяфәттә Шакирга карап, сөзеп маташкандай итенә. Такташның исә аларда эше юк, сөйләвендә була:

— Җоһар баһадир шушы сугышта ут эченә кереп китте. Әйттем мин аңа, сабыр итәргә куштым. Юк, тыңламады! Әмма дә гәүдәсен тапмадык. Исәндер ул, андый кеше үлми, андыйларны атом бомбасы да алмый! Бер дә әллә кайда булмас. Яралангандыр! Безнең районның хастаханәсендә генә ятадыр әле, барып карасаң...

Нәкъ шул вакыт тыкрык башыннан бире таба төшеп килүче Җәмилә әби күренде. Кырыгын узып баручы Такташ сикереп торды, җитмешне узып киткән әнисенең:

— Улым, өйлә җитте!.. Ашарыңа да алмагансың, капкалап кил! — дип дәшүенә, кулына сәнәген алып, өенә таба арган кыяфәттә атлады. Бераздан гына иптәшләренә таба борылып:

— Ярый, егетләр. Мин ашап килим... Сөйләп бетерермен! Тиресне түгә торыгыз! — дип, теләген җиткерде дә юлын дәвам итте. Аның ул сүзләрен ни Әсәр, ни Шакир колакларына эләрләр кебек түгел иде.

Бераздан алары да сәнәкләрен сөйрәп кайтып киттеләр. Берсе дә төштән соң киләчәк, араннар тулып, тау булып өелгән күмхуҗ тиресен кузгатып караячак һәм түгәчәк түгел иделәр анысы.

*Июль, 1999*

# Мунча парысы

Бу — мәхәббәт җыры, сөю утының кайнарлыгыннан туган булыр:

Аккош оча күл күреп,
Кыз сайлана гөл күреп,
Аккош булып күлгә төштем,
Ник килмисең үз күреп?

Мәхәббәт дигән бөек хакыйкать һәр кешенең күңел туфрагында үзенчә шыта, үсә, ныгый, чәчәк ата, алмалана һәм яфрак коя. Ә кешеләр алар төрле-төрле. Берләре — табигать баласы, икенчеләре — тәрәккыят, прогресс җимеше. Шунлыктан җәмгыять тә чуар. Табигать белән прогресс һәрдаим каршылыкта кала бирәләр.

Адәм баласы чынлыкта табигать продукты булып, аның колы хәлендә калырга теләмичә, мәйданга тәрәккыятне чыгарган. Шулай итеп, тәрәккыят, үсеш юлына керүгә, үзе үк кешене үзгәртә башлап, тормышяшәешне буйсындырырга тотынган. Адәм баласына хезмәт итәргә тиешле тәрәккыят, шулай итеп, үзе үк башчылык күрсәтергә тотына. Ә табигатьне әүвәлге көчендә калмаган, дип әйтсәк, ялгыш булыр иде. Кешеләрнең кайсылары, бигрәк тә авыл балалары, табигать тәрбиясендә формалашалар, ә шәһәрнекеләр исә тәрәккыят, ясалма тормыш вәкилләре булудан ары китә алмыйлар.

Аккош оча күл күреп...

Мин үзем дә кайчандыр чыннан да аккош идем, ягъни аккош кебек. Әмма мине үз күреп килергә тиешле ярым озын һәм озак еллар буена кайдалыгымны белә дә алмаган икән шул. Табигать белән тәрәккыят, гүяки яшәешнең ике каршылыклы полюслары сыман, берсенең биләмәсенә икенчесен кертергә ашыкмаганнар. Әмма бүген табигатьтән башка тәрәккыятне, тәрәккыяттән аерып табигатьне күз алдына китереп булмый һәм күз алдына китерергә дә ярамый, алар һәрдаим каршылыкта кала бирәләр, имеш.

Кыз сайлана гөл күреп...

Туган авылыма инде ничә еллар кунак буларак кына кайтам. Монда минем олы яшьтәге әнкәй һәм бертуган абыем яшиләр. Ә агай-эненең хисабы юк. Һәрхәлдә, шулай дип беләм.

Әнкәй дә, абый да һаман эштә, минут та утырып тора алмыйлар. Тавык-чебеш, мал-туар, йорт-җир — болар барысы да күп мәшәкать сорыйлар. Әле генә үрдәкләре су буена төшеп китәләр, ул арада казлары менеп җитәләр. Тавык-чебеш ду кубышып йөри. Болынга арканланган бозау тавыш бирә, аңа су эчертергә кирәк, ул да түгел, көтү каршылар вакыт җитә. Әле монысы, әле тегесе дигәндәй, кич җитә башлауга, әнеле-хайванат дигәннәре уңнан-сулдан йөгерешеп-чаптырып кайтырга тотына. Болар өстенә без бар — кунаклар. Гаиләм белән кайтып, хатыныма-балаларыма туган ягымның сихәтләндерүче һавасын сулатырга ниятләгән идем. Туганнарыма авырлык-борчу китерәсе килми дә, әмма хуҗалар үзләре хафага бирелми калмыйлар шул. Әле аш әзерләргә, бәлешен-башкасын пешереп, киңлек белән кунак итәргә тырышалар.

Менә абый да эшеннән кайтып җитә. Атын тугара. Арыган. Ә аны эзләп дуслары мең керделәр инде. Кырыкны узсалар да, һаман мәктәп елларын сагыналар икән үзләре. Сыйныфташлары белән тагын очрашу оештырырга булганнар. Бүген кичен икән. Мәктәпне бетергәннәренә егерме биш ел тулган.

Дөрес, тормышта бәйрәмсез яшәү килешеп бетми ул! Моны һәркем белә. Эш кенә түгел, бәйрәмнәр һәм йолалар да кешене кеше итә. Ә авылда, табигать иркендә яшәүчеләргә, бу күңел ачулар бигрәк тә кирәк.

Шул уңайдан бүген күпләр мунча яктылар. Очрашу бәйрәменә чистарынып-сафланып бару нияте белән инде, әлбәттә. Шәһәрләрдә яшәүче сыйныфташлары да кайтканнар икән.

Абыйның балачак дусты, хәзер дә күршедә генә яшәүче Сәеф кереп тә җиткән. Ак яка, кара пинжәк киеп алган. Күңеле, күренеп тора, шат. Бәйрәм куанычы мөлдерәп йөзенә чыккан.

— Абыең кайттымы әле?

Аның бу соравына баш кагып җавап биргәнемдә, әнкәй:

— Мунчага китте, юынып алыр да үзе барыр,— диде.

Сәеф бик ашыга икән.

— Мин хәзер күрше Чулманияне чакырам да бара торам! — дип саубуллашып чыгып та китте.

Кичке һаваның көндезге колак пешерерлек эсседән соң рәхәт кенә булып калган чагы. Кояш иренеп кенә баеп маташа. Авыл төнге йокыга әзерләнә. Бераздан йолдызлар чыгар, ай калкыр. Су буйларын яшьләрнең җырлашулары, баян һәм гармун моңнары күмәр. Аларга абыйларның очрашу бәйрәменнән шат авазлар килеп кушылыр.

Мин капка төбендә дөньяның рәхәтлегенә сөенеп утыра идем. Сыйныфташы Чулманиялардән дә Сәеф ялгызы чыкты.

— Ул да мунча кереп ята икән,— диде, минем яннан ашыгычлык белән узышлый.— Болар очрашуга тиз генә төшәселәр түгел икән!

Аны-моны җавап бирмәдем. Сәеф, үз капка төпләрендә көткән хатынын уңына алып, сыйныфташлары белән очрашу бәйрәменә китеп барды.

Аларны да көтеп алганнар. Очрашуга, кочаклашып, ура кубып исәнләшкәч, сорыйлар икән моннан:

— Күршеләрең кая? Чулмания кая? Гамил кая?

— Мунча кереп яталар! — дип җавап та бирергә өлгерә Сәеф.

— Чынлап тамы? — дигәннәр, аптырауларын яшерә алмыйча.

— Әйе инде менә! — дип, тагын да җавап бирә Сәеф.— Килешли кереп чыктым яннарына. Икесе дә мунча кереп яталар.

— Үзләре генәме? — диләр.

— Әйе, үзләре генә иделәр,— дип аптырап һәм шикләнеп тә тормыйча җавап бирә Сәеф.— Чулмания дә үзе генә кайткан, иреннән башка. Галимне беләсез инде, әле һаман өйләнмәде. Әллә вакыты, әллә насыйп сәгате җитми!

Әмма сыйныфташлары аның һәр әйткән сүзеннән соң көлгәннән көлә-көлә, кайсылары тәгәрәп-тәгәрәп китә башлый. Эчләре ката. Аларның көлешкәненнән яр буендагы тирәкләрдәге сайрар кошлар куркышып качып бетәләр, судагы балыклар, өркеп, төпкәрәк сеңәләр, абзарларына кайтарылып ябылган сыерлар, яткан җирләреннән торып, мөгердәшергә тотыналар. Телевизор карарга дип диванга сузылган агайлар аякланалар, ни булды икән дигәндәй, хатын-кыз кавеме урамга йөгерешеп чыга. Ярый әле тегеләр көлүләреннән туктыйлар, юкса Бакыр тавының очы бер якка кыйшаеп төшә башларга өлгергән, имеш.

Хәер, дөньялар беразга тынычланып тора да, очрашу хөрмәтенә тамак төпләрен бераз чылаткач, баян һәм гармуннарда тартып, җай гына җырлап җибәрәләр. Сандугачлар да урыннарына кайталар, сыерлар да кабат тынычлап яталар, халык телевизорга чума. Ул арада Чулмания дә, мунчадан чыгып, киенеп-ясанып, бар чибәрлеге белән балкып, су буена төшә.

Аннан:

— Гамил кая? — дип сорыйлар, хәйләкәр елмаешып.

— Нигә? — ди Чулмания, ашыгулык белән төшкәне сәбәпле бераз кызылланып, әмма оят-фәлән хакында уйлап тормастан, шулай да күлмәгендә яки битендә-йөзендә берәр гаеп тапканнармы әллә диярәк хафага калып, итәген, җилкә башларын карана-карана төзәтенеп.

— Гамил белән мунча керәсең, дигәннәр иде!

Чулмания тагын да аптырабрак кала.

— Нинди Гамил?

— Күршең, сыйныфташыбыз Гамил инде, менәтерәк! Әллә...

— Кем әйтте?

— Күршең, сыйныфташың Сәеф!

— Нәрсә диде?

— Мунча керәләр, диде!

— Керсә соң?

Ни хикмәт, теге тәгәрәүләре онытылмаган хәлдә, барысы да кабат егылышып көлешергә тотыналар. Бу юлы сайрар кошлар, сыер-сарыклар, абый-апалар гына түгел, хәтта тау башындагы зиратның агачларына кунып йокыга талган каргалары да саташып дәррәү күтәреләләр. Чулмания генә нәрсә әйтергә дә белми. Аптырап:

— Керсәм ни булган? — дип кабатлый-кабатлый, аңлатып бирүләрен үтенә.

Көлеп туйгач, сыйныфташлары аннан тагын да сорыйлар:

— Гамил кайда соң?

— Каян белим? — ди җавабында Чулмания, кабат көлешә башлауларына ни үпкәләргә, ни кушылырга белмичә.

Әмма бу юлы сыйныфташлары үзләрен иплерәк тоталар, ни каргаларны, ни сыер-сарыкларны, ни апа-агайларны урыннарыннан кузгата алмыйлар. Бакыр тавы да селкенеп маташмый. Әмма җиденче тойгысы белән эшнең нәрсә икәнлеген төшенеп тә аңларга өлгермәгән Чулмания шунда гына Сәефкә бәйләнергә тотына:

— Син ниләр сөйләдең монда килеп? Нәрсә диде? Әйтеп бирмәсәңме?.. Син ниләр сөйләдең?.. Кеше көлдереп...

Сәеф агарынып акланырга тотына:

— Мунча керәсез, дидем... Гамилләргә кергән идем, ул мунчада... Сезгә кергән идем, сез мунчада!.. Монда килгән идем, күршегездә генә яшәгәч, икегезне дә миннән таптыралар... Алар мунча кереп яталар, дидем. Дөрес түгелмени?..

Сыйныфташларының көлешә башлауларына бу юлы Чулмания дә кушыла. Кемнең кемнән көлгәнен берсе дә аңламый, әлбәттә. Әмма барысына да кызык. Сәеф үзенең сүзләрен төшенми калган сыйныфташларыннан, ә сыйныфташлары төгәл итеп сөйләп бирелеп тә, мәгънәдә ике мунчаның бергә кушылуыннан, ә Чулмания барысының да тулыр-тулмас хәлгә калуларыннан җәелеп-җәелеп көлешәләр. Тик бу юлы агачлардагы яфраклар да селкенми, хәтта үлән дә кымшанмый.

Нәкъ шул вакытта Гамил дә күренә. Килә-килешкә, боларның тәгәрәшеп ихахай-михахайлауларын күреп, кырык яшьләренә җиткәч кенә акылларына зәгыйфьлек килгәндәй, гаҗәеп хәлләрдә булуларына исләре китеп, һаман да сыйныфташлары саналган ир һәм хатыннардан сорый бу:

— Нишләдегез?..

Шул гына җитмәгән инде!

Киң болын тараеп, елга ярлары һәм калкулык-таулар әңгердә ишелеп-ишелеп киткәндәй тетрәнә башлыйлар, тагын да бүселебрәк, күзләреннән яшьләре сибелеп, аркаларын һәм сыртларын сикертә-сикертә көлешүгә күчәләр. Инде генә тынычландык дигәннәрендә аптыраштагы Гамил тагын сорап куя:

— Ни булды, егетләр? Сез нәрсә?

Әмма сыйныфташлары инде, көлүдән тукталдык дигәннәрендә, кабат пырхылдап җибәрәләр. Кырык яшьләрендәге хатыннар тагын юешләнер хәлгә җитәләр, чәчләре инде икенче кат агарыр чордан узган ирләр, тормышның тозын да, балын да татыган булуларына карамастан, инде түзәр хәлләре калмыйча, соңгы тыннары белән хихылдаган чакларында шулай да, Гамилдән үтенергә өлгерәләр:

— Сүз дәшмә, берүк!

Әмма яңабаштан каһкаһалауга, маһмаһалауга, ваһваһалауга күчәләр. Күк читендә тыныч кына баш калкытып маташкан ай кабат үз ятагына егылып төшә. Гамил, мескен, ни уйларга да белмичә, боларның көлү сәбәпләрен аңламаган хәлдә, аларга кушылып та карый, әмма кызык түгел, арыган тәне бик алай җәелеп китәргә ашыкмый. Ничарадан бичара хәлендә һәркайсына аерым-аерым әле тамаша кылып тора, әле үтенеч белән ялвармакчы итә. Сүнә башлаган учакларына, аптырагач, утын салып карый, берәр көлдергеч нәмәрсә эчмәгәннәрме икән, дип, табын яннарыннан караштырып әйләнеп уза. Сыйлар да, шешәләр дә әлегә башланганнар да шул килеш калдырылганнар.

Аның болай тикшеренеп йөргән күреп, бүтәннәр дә, бәйрәмне башланган җирендә ташламаска кирәклеген, дәвам итәргә вакыт җиткәнлеген аңлап, шушы кадәр көлүләре сәбәпле, карыннары да бушап калганлыгын тоеп, акрынлык белән генә булса да тынычланалар. Бер-бер артлы, сак кына атлап, табын артына җыелышалар. Барысы да утырышып беткәч кенә Гамил:

— Нәрсә булды соң, нигә сөйләмисез? — дип сорап куя. Әмма, яңадан да һәммәсенең бердәй көлешә башлауларыннан куркып, уңына һәм сулына каранып ала. Ни бәхет, мәҗлескә үле тынлык урнаша. Бары тик Сәеф кенә, Гамилнең үтенечен каршы:

— Эссесе ничек булды? — дип сорап куя.

— Нинди эссесе, нәрсәнеке? — ди Гамил, сүзнең ни хакында барганлыгын аңлый алмыйча, әмма бу сорауның бер-бер этлек белән бирелгәнлегенә һичбер шикләнмичә. Сәеф исә соравын башкачарак, аңлаешлырак итеп кабатлый:

— Мунча парысы, дим?

Кибеп җитмәгән чәчләрен артка ташлап, ике дә уйлап тормыйча, Гамил җавап бирергә өлгерә:

— Яхшы булды!

Әмма:

— Аркалар каты итеп ышкылдымы? — дип, Сәеф һаман да үртәү ягын каера.

— Әйе, каты итеп ышкылды! — ди Гамил, сүзнең, һичшиксез, бары тик үз аркасы хакында барырга тиешлегенә шикләнмичә.

Әгәр дә сорау-җавап алмашу шуның белән генә бетсә, мәҗлесләре инде дә башланып китәр иде. Әмма шунда арага Чулмания катыша һәм:

— Ни сөйлисең син, Гамил?! — дип, ачу белән әйтеп куя.

Бүтәннәр аның бу сүзләрен, үз теләгәннәренчә: «Ник сөйлисең?» — диярәк ишетәләр һәм тагын да пышык-пышыктан башлап көлешергә тотыналар. Кабат күтәрелеп килгән трактор тәгәрмәче кадәрле ай, шунда чак кына тәгәрәп төшеп китмичә, тау сыртына көчкә ябышып кала. Йокларга әзерләнгән авыл боларның каһкаһасыннан айнып китә, түбән очтагы Хәллүшнең әле бүген генә өеп бетергән галәмәт биек һәм зур печән чүмәләсе авып төшә, биләмәләрен карап кайту нияте белән урманнан авылга юл алучы бүре өере, аларның кинәт пырхылдап гөрселдәүләрен мылтык ату буларак кабул итеп, өннәренә кире менеп тая. Бары тик мәңге айнымас Рафинат абый гына: «Дөньяны су басса, үрдәккә яхшы!» — дип, уңыннан сулына борылып ята да йокысын дәвам итә. Чыгарга әле генә өлгергән йолдызлар тәмам коелышып бетә язалар. Ул кичен Өлфәт абыйларның ояда утырган тавыклары егерме тугызынчы көн урынына егерме җиденче-

сендә үк күп-күп итеп чебеш чыгарырга өлгерә. Бирсә дә бирә икән адәм баласына Аллаһы Тәгалә бәрәкәтне, берәүләргә күктән ут төшкәләгәндә, боларга манный боткасы ява.

...Бераздан барысы да тынычлананалар. Гамил дә, Чулмания дә, Сәеф тә, мунча турында ярты сүз дә кузгатырга куркып, авызларына чиләге белән су кабалар. Мәҗлес шунда гына тәмам җыелып, кабаттан башланып китә, шактыйлап сыйлашып һәм сыйланып алганнан соң, җыр һәм биюләргә күчәләр. Очрашу кичәсе күңелле генә дәвам итә. Һәм менә барысы да артыгы белән тынычланып калгач, Сәеф, уен-көлкегә тагын вакыт җитте дип, Гамилдән юри сорап куя:

— Чулманиянең аркасын каты итеп удыңмы, әллә йомшак кына итепме?

Гамилнең исе дә китми:

— Ә анысын инде үзеннән сора! — дип кенә җавап бирә. Имеш, хәзер нәрсә сөйләсәң дә ярый, гафу ителәәә, янәсе.

Сәеф шунда кычкырып дәшәргә тотына:

— Чулмания, Чулмания, дим! Кая әле син?

— Нәрсә булды? — дип, Чулмания биегән җиреннән тукталып сорап куя.

— Гамилнеке бик алай каты булмагандыр?

Төгәл генә нәрсә хакында сүз барганлыгын аңлап ук бетермәсә дә, Чулмания бу юлы үлчәп кенә җавап бирергә уйлый. Шунлыктан, биюен өзеп, Сәефнең янына килә, кабатлап сорый:

— Нәрсәсе каты булмаган?

— Ну, мунча инде, мунча! — ди аңа Сәеф, сүзне һаман шаярту ягына борырга теләп.

— Ул мунча әле һаман бетмәдемени? — Ачулы Чулмания шунда аптыраулы кыяфәт чыгара.— Җиткәндер инде?!

— Ну...— ди Сәеф киреләнеп.

— Нәрсәсе ну? — дия Чулмания аңа каршы.

— Катымы, дим? — Сәеф тарткалашуга борыла башлый.

— Каты, бик каты! — ди Чулмания, аны тынычландырырга теләп.

— Гамилнекеме? — Сәефнең җене котырмакчы.

Әмма шунда аның хатыны, иренең нәрсә әйтергә теләвен аңлап алып, юри төрттереп куя:

— Әнә кешеләрнеке — каты, ә синеке — мунчала!

Һәммә колаклы вә колаксызлар аның әйткәннәрен ишетеп алалар. Сүзнең бу якка борылып китәсен көтмәгән Сәефнең авызы ачылып кала. Сыйныфташлары шунда шартлап-шартлап киткәндәй көлешә башлыйлар. Аларның болай бертуктаусыз кет-кет, каһ-каһ, ха-ха, ваха-ваха, даха-даха, баха-баха килүләренә кояш та ул иртәдә бер сәгатькә иртәрәк уяныргa мәҗбүр була. Көтү дә иртәрәк кузгалып, йокылары туймыйча уянган халык, бер сәгатькә соңарган сәгатьләрен дөресләргә, эленке-салынкы гына йөренеп, тавык-чебешкә җим биргәч, калган бар эшләрен дә онытып, тагын йокларга яталар.

Мәҗлес тә тарала. Аларның төркем-төркем көлешеп кайтуларын туган-тумачалары җырлашулары дип кабул итәләр.

Вакыйга шуның белән тәмамланса да, авылда җеп очын табып булмаслык сүз тарала. Имеш, Гамил белән Чулмания бергә мунча кергәннәр икән дә, берсе икенчесенең аркасын юып ятканда, өсләренә Сәеф килеп эләккән. Һәм тагын да әллә ниләр, бик күп нәрсәләр инде шунда. Янәсе, Сәефнең үз хәлләре хөрти икән. Хатыны аны духтырга күрсәтергә алып киткән, ди.

Әмма болары барысы да ялган сүз, гайбәт арбасыннан төшеп калган алама сафсаталардан гына иде.

*Сентябрь, 1999*

# Кило ярымлы кура җиләге

«Бу вакыйганы бала вакытымнан бирле күңелемдә саклап килдем. Көннәрнең берендә менә шулай җиңел генә чишелеп китәрмен дә сөйләп бирермен дип башыма да китермәгән идем...»

Хикәямнең әүвәлге юлларын шушылай дип күңелемә ниндидер бер сихри хис һәм тойгылар сугарылган хәлемдә язып куйдым да аны берничә көн дәвам итә алмыйча йөрдем. Чөнки тасвир кылынырга тиешле вакыйгам, беренчедән, бик күптәннән, сабый чагымда ук булган, икенчедән, андагы затларның барысы да исәннәр, аларның да аңа карата үз бәяләре бардыр сыман, ә өченчедән, бер дә яшерен түгел, минем үз карашларым да еллар узган саен үзгәргән, хисләрем утырып, аларны бүтәннәре, яңараклары һәм тәэсирлерәкләре алыштырган иделәр. Шулай да, күңелем төбеннән алтын эзләгәндәй, хәтерем сандыгында казындым да казындым. Вакыйгалар әле сагышлы, әле кайгылы, әле шаян, әле көлкеле төс ал-

дылар. Чынлыкта тормыш барышы түгел, бәлки үзебезнең хисләребез, хәлләр торышына мөнәсәбәтебез вакыйгаларны яки аяныч, яисә шаян һәм көлке ясый икән шул. Ә көннәр ничек бер-берсен алыштырып килсәләр, гамәлләр дә шулай башкарыла бара һәм онытыла торалар. Кайгылы хәл — якыннарыңны югалту, кешенең үлеме ул. Әмма бусы да вакыйгага карата үзебезнең бәя генә. Әгәр дә күңелгә утыра барган комнарны чистартсак, барыбызның тормышлары, эш һәм гамәлләре бардан юк булуга гына корылган үтә дә бертөрле көлкеле хәлләрдән генә гыйбарәт икәнлеген аңларбыз кебек. Хәтта каршылыклы һәм үкендерерлек вакыйгалар да көлке, язмышның шуклыгы гына түгелме?..

Өченче сыйныфны тәмамлаган тугыз-ун яшьлек сочык вакытлар иде. Ул чорларда авылыбыз буйлап ага торган Минзәлә елгасыннан нефтьчеләр юри мыскыллапмы дегет агызганлыктан, су керергә дип, авыл башыннан гына аңа килеп кушыла торган мул һәм чишмәдәй салкын Ләшәү инешенә су керергә йөрибез. Чүгендер басуында чүлмәктәй яргаланып кызынган тәннәребезне, имеш, шулай эсселектән котылдырабыз. Дүсем авылының тирәкләре һәм болыннары кибеп, янып, корып беттеләр. Дегетнең мәрхәмәтсезлеге, көне-төне янган факел утларының кара төтененнән үк күренеп, җаннарга шом салып тора. Ә Ләшәү ягында нигәдер шул нефть дигән кара алтынны бик аз таптылар булырга кирәк, аларда әлегә басулар да, болыннар да яшел килеш калдылар. Бөтен авырлыгы безнең авыл кырларына эләкте, ахрысы. Кая карама — дегет чокыры, кайда күз салма — җирне бораулаучы каланчалар көне-төне гүләп-селкенеп утыралар. Ә без, билгеле инде, авыл балалары буларак, аякка басуыбызга — кыр эшендә, кишәрлекләрдә күмхуҗ чүбен утыйбыз, чөгендер, бәрәңге, кишер биләмәләренә эшкә куылабыз. Моңарчы да шулай булган, аннан соң да яшәеш шушылай барачак дип белеп, тәкъдиргә рәхмәт әйтеп, әмерләргә баш иеп буйсынабыз. Хезмәт тәрбиясен алабыз, үзебезне киләчәк бәхетле тормышка әзерлибез. Ә эссе көннәрдә су коенасы килә. Шунлыктан бөтен бала-чага Ләшәү елгасының тирән дип уйланылган култыкларына йөгерешә. Чума, йөзә, тәмам сөяккәчә чыланганчы һәм зәңгелә тотканчы, инештән чыкмыйча рәхәтләнә.

Ул көнне чөгендер биләмәсен тәмамлап чыккан, бәрәңге кырына кергәнче, бер-ике көн ял итеп алырга, ай ярымлык иртәдән кичкә кадәр бөгелгән билләрне турайтырга тиеш идек.

Ләшәү суында бака балалары кебек чыпырдашкач, инде иреннәргә кадәр күгәреп, тешләр тешкә бәргәләнә башлагач кына киенеп, кайтыр юлга таба атладым. Минем арттан күрше малае, кара күзле, чүмеч башлы, телгә — бистә, буйга — карыш, әмма дә ут Вазыйх иярде.

— И-и, малай, мәктәп бакчасында кура җиләге! Насыйр Ринаты ашап ята, мин сиңа әйтим. Учлап-учлап кына тутыра. Корсагы тау булган. Кып-кызыл! Теләсәң күпме ашарга рөхсәт икән! Әйдә, кереп ашап чыгабыз, рәхәтләнеп!..— дип вәсвәсә кылып, туктаусыз сөйләнеп килде.

— Юк, ярамый! — дим мин, тыңларга да теләмичә. Ә иреннән җиләк сулары әллә кайчаннан ага башлаганнар иде инде менә, яланып та куйгалыйм.

— Әйдә! Беркем берни әйтми. Туйганчы ашарга була! — ди Вазыйх, мине кодалый биреп. Бу кадәр дә сөйләүләреннән соң, йә, кем түзсен инде? — Ничек булыр икән? Ачуланырлар шул! — дим мин, киреләгем бераз сынып. «Бер-ике җиләк капсам, гөнаһысы юктыр. Әнә Насыйр Ринаты аннан чыкмый ашап ята икән!» — дип, үземне үгетли үк башлыйм.

— Әллә куркасың инде? — Вазыйхның үртәп әйтелгән бу сүзләре бөтенләй дә сынуым өчен җитә калды. Кешегә яраган миңа да хәрәм түгелдер инде ул!

— Әллә куркасың инде?

Нигә дип әле мин куркак булырга тиеш? Әмма ризалашырга, ике-өч җиләк кабып карарга ниятләнеп өлгермим, күңел төбендә нидер кузгалып, акыл көзгесенә кунарга җитешкән тузанны себереп ташлый. «Юк инде, ике-өч кура җиләге өчен гөнаһка кереп тордым түгел!» — дип, үземне ачуланырга, Вазыйхның вәсвәсәсенә ризалашуым өчен үкенергә өлгерәм. Әмма дустым:

— Анда җиләге дә тәмле икән! Чиләк-чиләк җыеп алганнар. Калганын кем тели, шуңа ашарга ярый, дигәннәр. Бөтен малайлар, хәтта кызлар да шунда! Әйдә, курыкма! Берни дә булмый! — дип сөйләнүендә иде.

Минем уйлар тагын аңа иярделәр. Бу вакытта нәкъ мәктәп бакчасының коймалары янына җиткәнбез. Ә анда, арбалы ат белән үк кереп китәрлек итеп, тишек ясап куйганнар.

— Әнә, күрәсеңме? Җиләкләр... Монда гына!

Әйе, күренеп тә торалар икән. Җиләкләр күзләрне кызыктырырлык итеп кызарганнар. Учлап-учлап җый да аша, җый да аша. Туйганчы рәхәтлән! Аллаһы Тәгаләнең нигъмәтеннән кунак бул!

Капка кебек киң итеп ачып сүтелгән койма тишегеннән Вазыйх эчкә кереп тә китте. Җиләкләрне өзепөзеп каба-чүпли дә башлады. Ах-ух килде, иреннәрен ялаштырып алды, үзе сөйләнә бирде:

— У-у-у, тәмле!.. У-у-у!.. Ням-ням!.. Кер, нишләп анда гына торасың?!

Мин инде беренче адымымны атлаган идем. Кура җиләкләре кызыллыклары белән үз араларына суырып кына алдылар.

— Бер… Ике... Өч...

— Тәмлеме?

— Әйе,— дидем. Әмма Вазыйхны чыгарга өнди дә башладым: — Җитте! Булды! Ярамас...

Мин моннан тизрәк чыгу юлына таба атладым. Әмма Вазыйх дөньясын оныткан, кура җиләкләре аны тәмам тоткын итәргә өлгергән иделәр инде. Үгетләүләремне ул ишетергә дә теләмәде. Аны ташлап чыгып китсәм, калдырдың да шылдың, рәхмәтсез, дип үпкәләр кебек. Тагын да ялынып карыйм. Ә ул һаман, тәмле тамак, җиләктән арына алмый, җитмәсә, өзеп капкан саен, мине үрти:

— У-у-у... Ням-ням!.. Ням-ням!..

— Әйдә инде, — дип, тагын да үтенәм.

Инде тәмам аптырагач:

— Алайса киттем, хуш, сау бул! — дим.

Шунда чыгып кына китсәм, нәрсә була иде инде? Бирмештән узмыш юктыр ла!

Уңыма да, сулыма да игътибар итмәгәнмен. Ул арада:

— Тукта, урыныңнан кузгалма! — дигән зәһәр, авыр һәм котны алырлык тавыш ишетелде.

Каршы ягымнан, агачлар арасыннан өстемә үткен җәпле сәнәк күтәреп йөгергән бер адәмне күреп алдым. Кая ди ул качу, баскан урынымда багана кебек катып калдым. Кулындагы сәнәген миңа төбәп ыргытырга яки китереп кадарга да мөмкин иде ул.

Бу кешенең мәктәптә хезмәт укытучысы булып эшләүче күршебез Әхмәт абый икәнлеген танып, өлкәннәр теленнән колакка кереп калган «Зәхмәт» аталуы кылт итеп исемә төште. Шушы хакта уйлап алуым мине харап итте дә инде: һәр хәрәкәтемә бик салынды, торааташ булып катып калдым. Ул, имеш, безнең мәктәпкә күчерелгәнгә кадәр Боламык авылында укытучылык иткән. Бер тыңлаусыз малайның йөзенә кыңгырау белән җибәреп, башын ярган. Аллаһ сакласын, сәнәгенә элеп алып, койма башына киптерергә элеп куймагае! Көне бик тә, кич якынлашып килүенә дә карамастан, һаман да эссе шул.

Ни уйласам, шуңа дәлил булып зәхмәтле сүзләре дә өстемә капланып яңгырап куйды:

— Кузгалган булсаң, сәнәк белән тондыра идем!

Әхмәт абыйның бу сүзләре ялган иде. Чынлыкта ул миңа төбәп сәнәген очырган, ә анысы, үткен җәпләре белән ялтырап килеп, яныма кадәр ирешеп, аяк очына бер адым гына кала җиргә зырылдап кадалырга өлгергән иде инде.

— Башкалар кая?! — Аның бу соравы тәнемә җанымны кайтарды.

Әле генә кура җиләкләрен авыз иләгенә тутырып рәхәтләнгән Вазыйх дустым ягына карадым. Ул инде анда юк иде. Ай күргән, кояш алганмы?

— Белмим...— дидем мин, һаман да урынымнан кузгала алмыйча.— Үзем генә идем! Бүтән берәү дә юк...

Хәер, үземнән гайре күземә һичкем әлегә күренми иде.

— Алдама!

Кечкенә чакларда өлкәннәр Алла урынына күренә шул ул: алар барысын да беләләр, бөтенесен дә ишетәләр, һәммәне күреп торалар кебек... Син бер-бер ялгышлык кылырга өлгермисең, кайтып кергәнеңдә, өйдәгеләр:

— Нигә алай эшләдең? — дип яки кимендә усал караш белән каршы алалар.

— Вазыйх?..— дип эндәштем дустыма.

Әмма Әхмәт абый тагын да куркынычрак итеп җикерде:

— Чыгыгыз әле монда, малайлар!

Кура җиләклегеннән калкынучылар күренмәде.

— Хәзер сәнәкне җибәрәм!

Бу юлы Әхмәт абыйның ул куркыныч сүзләре кураларны хәрәкәтләнергә мәҗбүр итте. Әмма дустым Вазыйх урынына икенче берәүнең ялтырап торган симез ак башы күренде. Мин аны да яхшы беләм, таный идем. Бу — күршебез Хәлиф, Әхмәт абыйның үз малае. Кайдан һәм ничек монда керергә өлгергән?

— Тагын кемнәр бар? — Әхмәт абый бу юлы йомшарды.— Аша, улым, аша! Бүтән беркем дә юкмы? — диде.

— Бар...— Шунда Хәлиф куралар арасына, үзеннән берничә карыш кына читтәге урынга бармагы белән төртеп күрсәтте. Сәнәген шул якка таба төбәп, Әхмәт абый аны җилкә өстендә шудыргалап алды:

— Чык, малай актыгы, юкса чәнчим хәзер!

Аның бу юлы тавышы тагын да котны очырырлык иде. Инде күз яшьләрен иреккә куярга өлгергән Вазыйх шыңшый-шыңшый күтәрелде. Учында авызына кабарга өлгермәгән кура җиләкләре иде. Ул аларны иреннәренә таба китерде. Әмма кабып җибәрә алмады. Куркуыннан иреннәре дер-дер калтырый, насыйп

ризыгыннан авызы баш тарта иде. Аның гаҗизлеге, кытыгыма тиеп, мөшкеллеккә калган хәлемне беразга җиңеләйтте. Йөземә көлке сызыклары йөгергән булырга кирәк:

— Авыз ерып торасыңмы? Менә хәзер еларсың! — дип, Әхмәт абыйның янап әйткән сүзләре колак очымны көйдереп узды.

«Берни дә булмас әле, үз малаең Хәлиф, әнә, кура җиләкләренә чумып-чумып ашап ята, битләренә кадәр кызарышып беткән! Җиләк кенә!» — дип, үземне акларга һәм якларга әзер булып, акылым уйнаклады. Инде йөрәгемә дә батырлык иңгән, тешләремдә дә үткенлек җитәрлек, чәйнәшерлегем барлыгына куанып алдым. Әмма колакларыбызны борырга тиеш булган Әхмәт абый кулын озынайтмады. Малае Хәлиф кура җиләкләренә туенып калды, ә безне ул мәктәп капкасына таба алып китте. Чыгарыр да җибәрер: «Бүтән кермәгез!» — дип үгет бирү белән генә чикләнер кебек иде.

— Кая барасыз? — Әхмәт абыйның усал тавышы безне тукталырга мәҗбүр итте.— Борылыгыз! Шушында гына торырга!

Әмма аның әмеренә колак салмыйча качарга да мөмкин иде, барыбер куып тота алмаячак. Дошманга әсир төшәр булсак, бу кадәр җанны кызганып, куркынып калмас идек әле. Ә бу — Әхмәт абый гына, күршебез, хезмәт укытучысы гына бит. Исең китеп торасы түгел! Берәр татлырак җиләк-җимеш белән сыйларгадыр исәбе? Капка янына килеп җиткәнче, усал итеп бер генә дә эндәшмәде түгелме? Һаман да елмайды гына: «Бүген яңгыр булмас, чәчәкләр күзләрен йоммый гына йокларга яттылар! — дип, төрле сынамышларын һәм күзәтмәләрен сөйләде.— Шәфәкъ та кызарып-кызарып баеды, иртәгәге көн эссегә!»

Шунда Вазыйх та әйтеп куйган иде:

— Туйганчы су коенабыз икән!

Димәк, тагын Ләшәү елгасына барачакбыз, мәктәп бакчасы яныннан узачакбыз, сүтелгән коймаларыннан эчке якка күз төшәчәк, анда керәчәкбез һәм рәхәтләнеп кура җиләге ашыйбыз дигән сүз бу! Әхмәт абый да аңламый калмагандыр, шәт! Әмма ачуланып бер генә кәлимә дә кайтармады шул. Елмаеп кына куйды.

Безне, мәктәпнең хезмәт дәресләре уздырыла торган мастерскойга кертеп, верстаклар янына утырткач, Әхмәт абый алдыбызга бер дәфтәр китереп салды һәм, кулыбызга каләм тоттырып:

— Аңлатма языгыз! — дип әмер бирде.— Бакчага кайчан, ничек, нинди максат белән кердегез, күпме ашадыгыз?

Мин шунда ук җавап бирдем:

— Өч җиләк каптым... Нәрсә дип языйм?

Әхмәт абый соравымны гына ишетте булырга кирәк:

— Килограммнар белән язарга! Килоларда! — дип кабат та әмер бирде һәм безне бикләп калдырып чыгып китте.

Вазыйх белән аптыраште үзара карашып калдык. Берни эшләп булмый, язарга дигәч язарга инде, Аллаһыга тапшырдык!

Мин, алдымдагы дәфтәрне ачып, андагы беркетмәләргә күз салдым. Бездән алдарак кына Насыйр Ринаты да Әхмәт абыйга капкан булган икән. Тагын да актара башладым. Мәктәп бакчасына керүчеләр һәм тотылганнар бер без генә түгел монда, санап һәм укып бетергесез.

Бу яңалык миңа батырлык өстәде. Яза башладым: «Мәктәп бакчасының ватык коймасыннан бүген кич, җиләк ашарга дип, Вазыйх белән кердем. Өч җиләк өзеп каптым. Чыкмакчы идем, тотылдым. Бу хата гамәлем өчен гафу үтенәм».

Әмма туктап калдым. Бүтән акланырлык сүз таба алмадым. Ахырда, шушы язганнарым белән канәгатьләнеп, кулымны куйдым. Яңадан укып чыгасы иттем. «Өч җиләк өзеп каптым» дигән урында туктадым. Вазыйх дустымнан сорарга булдым:

— Өч җиләк ничә килограмм була соң ул?

Чүмеч башының артын озак кына кашып, хисаплап бетергәннән соң гына аның җавабы ишетелде:

— Өч килограмм була!

Мине бу сүзләре бик тә гаҗәпләндерделәр. Ышанырга да, ышанмаска да белмәдем:

— Ничек?

— Шулай, төгәл өч килолап. Берсе-берсе бер кило булсалар, өчесен бергә исәпләсәк, тәмам өч килограмм инде алар!

— Бик аз түгелме соң?

Бу соравымнан соң Вазыйх мине тагын да гаҗәпләндерде:

— Тонналар белән язасыңмы әллә?

— Алай артык күп булыр ул,— дидем, бераз шикләнеп.— Әллә соң кило ярым белән исәпләп, дүрт кило да биш йөз грамм җиләк ашадым, дип языйммы?

Бу фикерем дустыма да дөрестер кебек тоелды. Бераздан, аңлатмага үзгәреш кертеп, «өч җиләк өзеп каптым» дигән сүзләр урынына: «Дүрт килограмм да биш йөз грамм җиләк ашадым»,— дип язып куйдым. Әгәр чыннан да капкан һәрбер җиләгем кило ярым авырлыкта булса, дустым Вазыйхның ашаганнары кимендә тонна ярымга тартырга тиеш иде.

Һәм менә ул да аңлатмасын язарга кереште:

— Син ничә җиләк ашадың соң? — дип сорадым аңардан.

Вазыйх, язуыннан туктап, җиләккә буялган кулларына карап торды да:

— Учлап-учлап инде! Санап тормадым, әмма дә корсак тулырга өлгермәде. Әни әйтә, синең корсакны тутырырга тонна ярым кирәк, ди. Бер-бер җиләкне кило ярымнан исәпләсәк, бер тонна да мең килограмм инде. Чама белән алганда, мең чиләгең тонна ярым булыр иде. Корсак тулып җитмәвен хисапка кертсәк, бер җиде йөз чиләк ашаганмындыр,— дип, миннән дә болайрак буталып һәм арттырып, такы-токы тезеп китте.

Ишеткәнем бар иде — бабасы кибет тоткан. Кем-кем, Вазыйх та саный белмәсә, адәм көлкесе булыр иде.

Һәм Вазыйх бер тонна кура җиләге ашавын аңлатмасына язып куйды. Шунда Әхмәт абый килеп керде. Аңлатмаларыбызны алып куйды да безне кайтарып җибәрде. Икенче көнне, йокыдан торып, урамга чыгуыма, авылыбызның антый-сантый малайлары, җыелышып, капка төбебездәге бүрәнәләр өстенә тезелешеп утырганнар, бүселеп үк китәрдәй булып көлешә иделәр. Вазыйх белән мине күреп алгач:

— Кило ярымлы җиләк!.. Карагыз әле корсакларын, капкорсаклар, берәр тонна ашаганнар,— дип, тәгәрәшеп мыскылларга тотындылар.

Бигрәк юләр чаклар булган икән ул! Без шулай ашагач, Әхмәт абый малае Хәлифнеке ничә тонна булды икән, шуны да белешмәгәнбез.

*Июль, 1999*

# «Өфет мае»

Безнең авылның янәшәсеннән генә, Минзәлә елгасының аргы ягында, басма аша Ләшәүтамак авылы башлана.

Шунысы кызык, күмхуҗ идарәсе, мәктәп, авыл советы, балалар бакчасы, почта, телеграф кебек хакимият йортлары безнең Дүсем авылына урнашкан булсалар да, алар, һәммәсе Ләшәүтамак исеме белән йөртелеп, Ләшәүтамак урта мәктәбе, Ләшәүтамак авыл советы, Ләшәүтамак почтасы буларак аталалар. Моңа инде Дүсем халкы күнегеп беткән, хәтта мәчетләрен дә «Дүсем» исеме белән йөртмичә, «Мөнәүвәрә мәчете» диләр. Хәерлегә булсын, мөгаен, заман һәм тарих минем туган авылымны телдән һәм кәгазьдән төшереп калдырырга теләгән чаклар да булгандыр инде.

Әле дә хәтеремдә, безнең авылда Дүсем әүлиясы аталган бер апа бар иде, аның хәтта төкерегенең дә шифасы бик күпләргә тигән, әллә ниткән кырык ят илләрдән һәм җирләрдән аның дога һәм төкерек шифасына дәгъва кылып килүчеләр ул елларда аз булмаган. Аннан соң Дүсем исеме, үзе Дусмөхәммәдтән кыскартылып, татар ләкабенчә ясалган, мөгаен коммунистлар өчен Мөхәммәд дигәннең «д» хәрефе дә җиңүчән бер хакыйкать кебек тоелгандыр. Ярар, монысы шаярту гына. Әмма төп сәбәбе Дүсемнәр хакында халыкта йөргән мәкальдә булгандыр. Чөнки: «Дүсем — буйга үсем, акылга — таман!» — диләр шул. Ягъни дүсемнәр буйга озын булсалар да, акыллары җитәр-җитмәс кенә, имеш. Бәлки, шулайдыр да! Мин үзем дә шундый: буйга — ун карыш, акылга — бергә дә тулмый. Ярый-ярый, көлмәгез! Аллаһының әменнән узу юк ул!

Әйе, акыл мәсьәләсендә Дүсем халкы гади һәм беркатлырак шул, юкка-барга да ышанучаннар. Ә менә ләшәүтамаклар андый түгел, хәтта кешене шаяртып кызык ясауны да бернинди гөнаһ билгесе галәмәтенә санамыйлар. Бер Төкерек Рафаэль абзагыз үзе генә дә әллә кемнәреңә тора, билләһи!

Төкерек дигәннән, Рафаэль абый сварщик, ягъни эретеп ябыштыручы булып озак еллар күмхуҗ алачыгында эшләде. Кул осталыгында алай ук санга керерлек булмаса да, телгә беткән дә инде үзе. Тимер-томырны ябыштыру хаҗәтең белән аны эзләп килсәң, көне буе янында утыртып, кичкә бер-ике җирдән ябыштыргыч белән төртеп бирә инде анысы, рәхмәт төшкере, йомышлыны алай бер дә кире какмый. Әмма ябыштырган урыны төкерек кенә сылап куюга охшаганлыктан һәм һичшиксез тиздән кубып чыгасы булганлыктан, Рафаэль абыйны халык бик тә яратып һәм олылап Төкерек кушаматы белән йөртә иде.

— Кая барасың?

— Төкерек Рафаэльгә!

Яки:

— Каян киләсең?

— Төкерек Рафаэльдән! — дип сөйләшкән малайларны да әти-әниләре ачуланмый, чөнки үзләре дә аны шулай дип атый иделәр.

Нинди генә кушамат таксалар да, Рафаэль абыйның исе дә китмәс иде. Киресенчә, бик тә уен-көлкене ярата торган кеше булып, гозер белән күренгән һичкемнең үтенечен аяк астына салып таптамый, берәр әби-мазар:

— Улым, шушы кисәү агачымның башы төшкән иде, төкертеп кенә бирсәнә?! — дисә:

— Төкерүен төкерер идем дә, төкерегем бетеп китте әле,— дип шаярткан була.

Алъяпкыч астыннан шешә төбенә салып китергәнне чыгарырга мәҗбүрсең. Дөрес, аңа дип аталган икән, эш беткәч, ягъни бер төкерткәч, калдырып кына китәрләр иде дә, оныта күрмәсеннәр, дип, махсус алдан бәяне билгеләве аның. Юкса бер рәхмәткә генә гозер тыңлап, гомерне бушка уздыруның нинди рәхәте бар?

Көннәрнең берендә Дүсемнең Пытпыт Фатыймасы Төкерек Рафаэль абыйга йомыш белән югары очтан ук велосипед, ягъни дә мәсәлән, сәпәй күтәреп төшкән. Кызу эш вакыты икән. Урак чоры. Җитмәсә, районнан вәкил тикшеренергә һәм төшерергә килгән, ә басудан бер комбайн ватылып кайткан. Купкан җирләрен ябыштырырга да кабат эшкә чыгарып җибәрергә генә. Ә вәкил һаман күзәтеп тора. Күзе очлы.

Күмхуҗның машина-трактор паркы мөдире, алыштыргысыз Хәсәнша Хәмзә абый аңа бу җитешми, тегендә бу юк, дип зарланып, вәкилнең игътибарын кирәкле мәсьәләләргә җәлеп итмәкче. Ә тегенең телендә үзенеке:

— Нигә бу комбайн һаман китми?

— Менә булды инде, хәзер кузгала, теге җитми, бу юк шул,— дип, Хәмзә абый зарлана тора.

Ә вәкилнең җыры һаман да искечә кала:

— Нишләгән ул комбайн?

Кирәк бит, Пытпыт Фатыйма апа да, шул тирәдә йөренеп, Рафаэль абый уңга чыкса, велосипед-сәпәй сөйрәгән хәлендә артыннан ияреп килә, сулга барса, анда күренә, астына ук кереп китсә, ул да шунда чума.

— Төкертеп җиткермәгән! — ди Хәмзә абый, вәкил алдында акланып.

— Әнә төкертешәләр түгелме соң? — ди тегесе, җавапның асылын аңламаган хәлдә.

— Бу юлы яхшырак төкерт, дип әйткән идем инде үзенә,— дип, Хәмзә абый хәлне аңлата.

— Әйтәм уңлы-суллы йөренәләр,— ди вәкил,— астына да кереп киттеләр. Тиз генә чыгасылар түгел, ахрысы!

— Кереп киттеләр,— дип, Хәмзә абый да баш кага. Шул вакыт комбайн астыннан сәпәй сөйрәгән Пытпыт Фатыйма апа килеп чыга да туры болар янына килә. Үзе нигәдер дулый. Яннарына җитүгә, кемнең кем икәнлеген дә карап тормастан:

— Хәмзә абый, Төкерек Рафаэлеңнең миңа калгач кына өфет мае беткән. Бир әле, — дип ялына да башлый, күзләреннән яшьләр генә килми.

Болар үзара карашып куялар. Рафаэльнең шаянлыгын белгән Хәмзә абый вәкил янында Фатыйма апага бу хакта ничек кенә әйтергә дә белми аптырап тора да:

— Сеңлем, яхшылабрак сорамагансыңдыр? Карап тордым, әле беркемгә дә әрәм-шәрәм итмәде,— ди.— Менә, комбайнны җибәрсен дә, тагын үтенеп карарсың, ашыкмый тор...

Әмма:

— Ничек инде ашыкмаска, минекенә бер генә төртеп-тидереп алса да җитә, күп кирәкми...— дип, Фатыйма апа туктаусыз пыт-пыт килә.

— Төртер-төртер, тидереп тә алыр,— дия-дия, Хәмзә абый аны вакытында тынычландырырга тырыша.

Әмма Фатыйма апа һаман да баш бирми:

— Ул бит алай димәде. Өфет маем бетте... Бар, Хәмзә абыйдан сорап алып кил, диде.

Боларны тыңлап торган вәкил, бу сүзләрнең мәгънәләрен аңлап җиткерә алмыйчадыр, үз колаклары белән ишеткәннәреннән чыгып, бөтенләй дә әллә нинди вә әллә ниткән этлекләр хакында уйлап бетерә. Әле көлмәкче була, әле ачуланырга уйлый:

— Кызу эш барышында уйнак-муйнак итеп йөрергә...— дип мыгырдана.

Ә Хәмзә абый нәрсә әйтергә дә белми. Югыйсә: «Ярар, бирермен!» — диясе генә шунда. Юк, һаман да сүзнеерактан ук әйләндереп китерә-китерә аңлатырга тырыша. Үзе кирәксә-кирәкмәсә дә кабатлый:

— Нигә миңа җибәрә ул? Ни, нәрсә...

Әмма дә:

— И Хәмзә абый,— ди аңа да карамастан Пытпыт Фатыйма, тулып пешкән беләкләренә төшкән җиңнәрен сызганып, калачтай күпергән күкрәкләрен төзәтеп.— Миңа калгач кына юри бирмисең инде, бeләм. Кайларга барыйм, кемнәргә ялыныйм икән?..

Тыңлап торган вәкилнең күзләре маңгаена менә. Булса да булыр икән, имеш, тәнгә-җанга, сүзгә-телгә дәртле хатыннар.

Ә Хәмзә абый һаман да киреләнә:

— Бар, Рафаэльнең үзенә бар... Монда, көпә-көндез кеше алдында йөземне кызартып...— дип үгетләп тә әйтеп карый.

Әмма:

— Нинди кеше?.. Ул — кеше, мин кеше түгелмени? — Пытпыт Фатыйма да бирешми, үзенә кирәген дәгъвалый.

Ахырда Хәмзә абый:

— Ярар, Рафаэль янына бара тор, Фатыйма сеңлем, мин хәзер,— дияргә мәҗбүр була.

Ул китеп баруга, вәкил:

— Һай сездә хатыннар шаулы икән,— дип, бер мәзәк сөйләп ала: — Иреннән бер хатын «давай да давай» диярәк дәгъвалый икән. Әйдә инде, имеш. Ә тегенең вакыты юк. «Менә утынны ярып бетерәм дә!» — ди, имеш. Хатыны ризалаша, нәрсә эшләсен. Каенның муртайганы туры килгән, ахрысы. Ире эшли торгач, кичкә кадәр тукталмый маташкан. Карыны ачып, өенә керсә, хатыны камыр изеп маташа. Ире: «Кая, тамак ачты, китер ашарга!»— диюгә, хатыны: «Хәзер, камырны изеп бетерим, мичкә ягыйм, ипине пешерим, аннан соң өстәлгә утырырбыз!» — дип белдерә...

Бу өчле-тугызлы мәзәгеннән соң вәкил рәхәтләнеп авыз чөеп көлә. Хәмзә абый да итагать йөзеннән аңа куштанланып иярергә мәҗбүр була. Ул арада Рафаэль абый комбайнның аерылган җирләрен яхшылап ябыштырып, яңадан кырга чыгарып җибәрә. Фатыйма апа да, сәпәенә «төкертеп», үз юлы белән кайтып китә. Артыннан вәкил:

— Булдырткан бу! — дип, тереләтә ашардай хәлдә күзләре белән ябырылып озатып кала.

Тик Хәмзә абый гына Төкерек Рафаэльгә барып:

— Район кешесе алдында мине хур итмәсәң,— дип, якалап алырдай булып ачулана.

— Әйбәтләп төкерттем инде, җиренә җиткереп эшләдем,— ди Рафаэль абый, акланырга җай эзләп.

— Ничек җитешәсең, афәрин,— дип мактый сүз арасында яннарына килеп катышкан вәкил.— Әллә төнлә дә эшлисең инде?

— Туры килә инде, туры килә,— ди Рафаэль абый, моның күзенә төтен җибәреп.— Урак өсте шул!

Вәкил бу юлы да, зур канәгатьлек белән, мул гына итеп итен-маен, балын-каймагын төянеп китеп бара. Җыелышларда Төкерек Рафаэль абыйны мактап телгә ала, район гәзитеннән фотохәбәрче килеп, аны сурәткә дә төшереп китә. Күп тә үтми, Сарман районының «Ленинчы» гәзитендә мул елмайган какча Рафаэль абыйның фотосы басыла. Астына «Кумхуҗ эшен үзенең шәхси бурычларыннан өстен куйган, көнетөне алны-ялны белмичә хезмәт куючы данлыклы сварщик...» дигән сүзләр язылганнар.

Озакламый Рафаэль абыйны коммунист та иттеләр. Шулай дәрәҗәсе көннән-көнгә артып, мактау такталарына да менеп иреште, рәхмәт яугыры!..

Ләшәүтамак дигәннән, бу авылның исеме Ләшәү дигән инешнең Минзәлә аталган елгага койган төшендә урнашканлыктан, ике суның бергә агып киткән урынын тамак дигәннәре өчен, Ләшәү Тамагы аталып йөртелгән җирдән Ләшәүтамак булып әверелгән. Хәзер исә аны, тагын да кыскартып, Ләштамак дип кенә сөйләшәләр. Тиздән Ләштмак яисә Ләшмак булып китәргә тора. Элекләрне бу авыл халкын «Ләшәүтамак — ач тамак, бака тулган коштабак» дип үртәгәннәр. «Коштабак» дигәннәре Сарман якларында зур һәм тирән, тагарактан аз гына кечерәк табакны аңлата инде ул. Әле аның «бадъян» дигәне дә бар. Ә, ярый, ул хакта сүз тәлинкәсен әйләндерүне икенче юлыга калдырып торыйк. «Коштабак» дигәннәренә кире кайтсак, анысы аның, белеп алырга өлгергәнегезчә, зур табакны җирле сөйләмчә белдерү, атап йөртү генә инде. Ул, дөресрәге, кувеш табагы булган, ягъни шул табакта кувеш комганнан су салып тора-тора юынганнар. «Кувеш» сүзе урыска «ковш» һәм «кувшин» сүзләре булып кереп киткән, хәзерге көндә чын славян кавеме кәлимәсе дип аңлатыла. Хәер, татар халкы бу кувешнең үзләренеке икәнлеген күптән оныткан, шулай да ул «коштабак»та сакланып калган.

Хикмәт анда гына да түгел, Ләшәүтамак авылыннан тыш, Ләшәүбашы һәм Түбәнләшәү авыллары да бар. Аның Ләшәүбашы урысныкы булып, күптән таралып беткән. Бер-ике йорты әле дә калмадымы икән?.. Ә менә Түбәнләшәүнең исеме Ләшәү дип кенә йөртелә башлады. Ләшәүтамак авылы халкы белән шул ләшәүлеләр арасында бер-берсенә исемдә генә түгел, кыяфәт һәм гадәт-гадәтсезлектә дә охшашлыклар күп. Алар икесе дә элекләрдә лашман авыллары булыпмы, падишаһ хәзрәтләренә олы көймәләр төзү өчен калын-калын урманнарны кисеп, юан-юан имәннәрне су күтәрелгән-ташыган вакытларда Чулман ел-

гасынача сал итеп озатканнар. Минзәлә инешен ул заманнарда, имеш, Ык кебек үк мул сулы булган, дип сөйләгәннәрен ишеткәнем бар, укыганым гына юк. Хәер, моңа ышанырга да туры килә, чөнки бу якларның калын урманнары киселгәч, елгаларының сулары да кимеми, инешләре дә корымый калмаганлыгы аңлашылып тора.

Ярар, боларын шушында калдырыйк. Ә менә көннәрнең берендә чуар күңелле Ләшәүнең Мөлих абый исемле агае, ат чаптырып, Төкерек Рафаэль абыйга төшкән — монысына тукталмый булмый.

Ябыштыручы бит инде, Рафаэль абыйны әйтәм. Бүтән кемгә барасың?

Элекләрен комган төбен яматасы булса да, самавырың акса да, урак тешәтергә, сабан төрәнен чүкетергә, тырма тешләрен очлайтырга кирәксә дә, тимерчегә йөгергәннәр. Хәзер — заман башка, сварщикка ялынырга кирәк. Тереклек тоткасы ул, диләр!

— Кара әле, энем Рафаэль, менә шушыны гына ябыштырып бир әле, катырак итеп, — дип үтенгән Мөлих абый, бер атна элек кенә «төкертеп» алып киткән, әмма таралып төшкән тәгәрмәч коршавына сөйли-сөйли күрсәтеп һәм аны Төкерек алдына китереп куеп.

Ә Рафаэль абыйның, хәтергә яман кеше буларак, үзенең дә ул тәгәрмәч коршавын күптән түгел шәләйвәләй генә ябыштырып җибәргәне исендә икән. Белеп тора, тагын таралып төшмәгәе. Яхшырак итеп эшләргә кирәк. Ә моның өчен вакыт кирәк, бер-ике генә төртәсе түгел. Шуңа күрә:

— Бу тагын купмас микән? — дип борчылып, тиз генә сөйләнеп тә алган.

— И энем,— дигән Мөлих абый,— купмаслык булсын инде! Йөк белән килгәнемдә таралып китеп, хараплар итте. Катырак итеп эшлә инде!

— Катырак итеп? — дигән Рафаэль абый, махмырдан тирләгән маңгаен сул кулы белән сөртеп, култык астында саклык битлеген, уң кулында электродын һәм ут чыбыгы башын тоткан хәлендә.— Катыра торган ташым бетеп китте шул, бик тә катырак итеп эшләр идем!

Ул арада ут чыбыгының башын тимергә төртеп, очкынлатып алган:

— Менә, күр инде моны, чәчелә дә китә, чәчелә дә китә...

Шунда Мөлих абыйның күңеленә тагын да борчу төшә. Нияте тиз генә «төкертергә» дә китәргә икән югыйсә, ә монда — эшләр харап, сварщикның катыра торган ташы беткән.

— Энем, ул нәмәрсә кайда бар икән соң? Кемнән сорарга? — дип, Мөлих абый аңа гозерле һәм мескен карашы белән төбәлгән.

— Сезнең Ләшәү кибетендә, Банат апада бар инде ул... Әгәр бирсә...— дигән Төкерек Рафаэль, йөзен бик тә җитди тотып.

— Шулай дисеңме?

— Калса, анда гына калгандыр! Дүсем кибетеннән дә, Ләшәүтамакныкыннан да кичә соңгыларын алып килделәр. Кайткан да беткән...

— Ал-лай...

Шул сүзе белән Мөлих абый тугарылган атына атланган да, артыгын сораштырып тормыйча, Ләшәүгә чаптырган. Кибетче Банат апа, чибәрлектә патша хатыннарыннан ким түгел, акылга, уен-көлкегә бай ханым, төшке ялга кайтырга әзерләнеп, магазинның калын тимер ишегенә авыр йозаклар элеп маташа икән. Тузан туздырып, атын ак күбеккә батырып, Мөлих абый җан-фәрманга чаптырып килеп туктаган:

— Тыр-р-р...

— Нәрсә кубарып йөрисең? — ди икән Банат апа, кулыннан ачкычлары төшеп китеп, аларны күтәрергә иелеп.

— Бикләдең инде әллә? — дип кабаланып сорый Мөлих абый.

— Төшкелеккә! — ди җавабында Банат апа, ачкычларын күтәреп алып.

— Катыра торган таш кирәк иде,— ди икән Мөлих абый, бик үтенеп,— бирсәңчәли?..

— Үзеңәме? — дип, аңа аптыраулы һәм шаян караш ташлый Банат апа, бөтенләй дә бүтән нәрсәләр хакында хыялланып.

— Юк, Төкерек Рафаэль сораган иде шул...— ди Мөлих абый.

Банат апа эшнең нәрсәдә икәнлеген шунда ук аңлап алган, җитмәсә:

— Катыра алмый башлаганмы әллә? — дип сорау биргән.

Мөлих абый яшермичә җавап та ирештергән:

— Чәчелә дә китә, куба да төшә, ди...

Банат апа да аптырап калмаган, аңа:

— И-и, алай икән... Ул катыра торган ташны, Мөлих, барып, син ирем Имаметдиннән сора. Кибетнеке генә ярамас, аныкы яхшырак,— дип, эсселәтми-суытмый өйрәтеп тә җибәргән...

Мөлих абый аларның капка төпләренә килеп туктый. Ә Имаметдин абзый печәнгә киткән. Ике дә уйлап тормыйча, шунда чаптыра бу. Атын бик каты кугандыр инде, ул ирешеп килеп туктауга, янгын-мазармы әллә дип, болындагы халык җыелырга өлгерә. Ә Мөлих абый:

— Кара әле, Имаметдин, синеке яхшырак, диде Банат... Бир әле, — дип үтенергә тотына.— Кибетен төшкелеккә ябып куйды. Ә минем Ләштамакка барып җитәсем дә бар... Аптыратма инде, бакчый!..

Ә Имаметдин абзый моның сүзләреннән һични аңламый. Кабатлап сорый:

— Нәрсә кирәк иде соң, Мөлих?

— Катыра торган таш!

— Нәрсә?..

— Катыра торган таш!

— Кем әйтте?

— Банат...

Имаметдин абзый начар якка уйлый. Шулай да, хатыны юри, күңел өчен уен-уймак кылырга җыенган икән дип, үзен борчыйсы килми. «Бәлки, аңлап җиткермәгәндер бу Мөлих, буталып сорыйдыр?» — диярәк уйланып алганнан соң, тагын бер сорау бирә:

— Нәрсәгә?

— Катырырга!

Бу җавапны ишеткән халык та аптырап кала. «Ниткән галәмәт, ниткән сүз бу?» имеш. Имаметдин абзый исә тагын да сорап куя:

— Кемгә?

— Төкерек Рафаэльгә!.. Тәгәрмәч күгәнен, ни, боҗрасын, әйе, ни, коршавын ябыштырасы бар иде. Катыра торган ташы беткән. Алып килергә җибәрде,— дип, Мөлих абый сөйләп бирә. Аннан мондый ахмак сүзләрне ишеткәч кенә Имаметдин абзый эшнең асылы нәрсәдә икәнлеген аңлап ала. Ә җыелышкан халык тәгәрәшеп көлә бирә. Бала-чагага кадәр һәммәсе тыела алмый бүселәләр. Нәрсә эшләргә белмәгән, әле яңа гына үзенең нинди мыскыллы хәлгә калганын аңлаган Мөлих абыйны бердәнбер Имаметдин абзый гына юатырлык сүз таба:

— Син бер дә борчылма. Менә катыра торган таш алып килдем, дип, кәгазьгә төр дә мунча ташын илтеп бир!

Аның киңәшен тыңлап бетергәч, инде килешкәч кенә, Мөлих абый тагын кирегә сукалап маташа икән:

— Ул әле унбиш тиен акча да биреп җибәргән иде. Шул хак кына тора, дигән иде...

Халык бу юлы тәмам чәчелеп һәм тәгәрәшеп үк көлә башлый. Имаметдин абзый һаман да акрынлык белән акыл өйрәтә бирә:

— Мөлих, ул акчасын син аның үзеңдә калдыр. Кәгазьгә төрелгән мунча ташын кулына тоттыр. Аны-моны аңларга өлгермәсен, атыңны җигеп, тизрәк китү җаен кара!

— Тәгәрмәчне калдырыргамы?

— Юк инде,— дип, һаман да акыл бирә Имаметдин абзый,— аны эшләп куйгандыр, әллә кайчан әзердер. Син бары тик сер генә бирә күрмә!

Мөлих абый нәкъ өйрәтелгәнчә эшли...

Атын Ләшәүтамак алачыгында калдырган арбасына җигеп, тәгәрмәчен кидертеп, тагын да дөнья җимертеп чаптырып, эңгер эленгәндә генә Ләшәүгә кайтып төшә. Тагын да халык җыела, сорыйлар:

— Ничек булды?

— Нәрсә ничек?

— Ташны бирдеңме?

— Юк...

— Ничек инде юк? — диләр.

— Өйләренә кертеп калдырдым, эштә юк иде инде ул!

— Анда нәрсә диделәр?

— Хатыны өендә иде. Файдасы тисә, бик яхшы булыр, дип сөенеп алып калды.

Шушы җаваптан канәгатьлек табып, халык бер-берсенә карашып куя. «Әллә Имаметдин абзый чынлыкта дөрес әйткән инде?» — дип таралышып, берничә кич рәттән, йокы алдыннан инде, мунча ташын ялап-ялап караучылар булган, имеш, алары ук дөрес сүз түгелдер.

Ә Дүсем бүген дә менә шушы Ләшәү белән Ләшәүтамак исемле ике авыл арасында, таулар куенына сыенып, боларның мәш килүләренә хәйран итеп, тыныч кына яшәп ята булыр.

*Июль, 1999*

# Мөдәмир, яки «Тәрәзә төбең үрмә гөл!..»

Максатчан кешеләр бала чактан үзләренең кем буласыларын белеп үсәләр. Мөдәмир исә:

— Мин Зәки абый кебек балта остасы булам! — дип, бөтен кешене, абый-энеләрне генә түгел, хәтта әти-әнисен дә шаккатырган иде.

Әле яңа икегә берне кушарга өйрәнеп килүе, бары әлифбаны гына уздылар, ә ул инде гомерлек юлын сайларга да өлгергән.

—Дөрес,— диде атасы Зәбир, улының сүзләрен куәтләп,— син чыннан да балта остасы булырсың!

— Сөйләдең инде юк-барны! — дип ачуланды әтисен әнисе.— Балага киңәш бирәсе урында, әйткәннәрен куәтләп утырган буласың тагын! Каян килеп балта остасы ди инде улың? Каләм тотып, линейка салып, туры сызык сыза алмаган малаеңнан каян чыксын андый кеше? Балта остасы, имеш! Тел бистәсе, диген! Менә шул!

— Бүген — тел бистәсе, иртәгә – балта остасы! — Мөдәмирнең әтисе улының бу юлны сайлавына риза-бәхил иде.— Авызы балда-майда булыр, ичмасам! Кулында — эше, кесәсендә — акчасы! Менә шул!

Әмма Мөдәмирнең әнисе болай җиңел генә бирешмәде:

— И-и, сөйләнеп утырган буласың! Зәки абыйны кара, нәрсә инде! Эшләгәнен аракыга аударып бара. Кайсы балта остасының эчмәгәне бар? Бал-май, имеш! Һәр кеше булдыра ала торган эш икән, бөтен адәм дә, балта тотып, оста исемендә генә йөрер иде!..

— Менә-менә... һәм дөрес!

— Кая менә? Кая менә? — Хатын-кызның бер кыза башласа, сүздән туктыйсы, тынычланасы юк инде аның! — Менми генә торсын әле! Иртәгә Зәки абыйның кәчәкләр утыртырга киләсе бар, камырымны онытып җибәргәнмен! — Ул шунда ук мич башыннан камыр күәсен кузгатты.— Яңа йортка быел күчәбезме инде, юкмы?

— Кәчәкләрне утыртыйк та...

— Утыртыйк та... Утыртыйк та...— Хатынының болай үчекләп кабатлануына ире чыдый алмады, чыгып китәргә итте. Әмма тукталырга мәҗбүр иде. — Кая барасың әле анда?

Мөдәмирнең әтисе берсүзсез кире борылды, юктан гына чыккан тавышны җаны күтәрә алмаса да, сабыр итәргә булды. Хатыны исә аның ярасына тоз сала торды:

— Утыртыйк та, дип сөйләшкәнеңне әйтәм, бигрәкләр әллә кемгә куясың инде үзеңне! Зәки абый утыртып бирсен дә, дисәң ни була?..— Үзе сөйли торды, үзе камыр изәргә тотынды. Беләгенең матурлыгы иренең күзләрен очлайтып җибәрде.— Ни карап каттың? Утын керт!

Зәбир абзый буйсынырга тиеш иде. Менә хәзер мичкә ягып җибәрерләр. Быел сүтелергә тиешле булган шушы бәлале мичнең әллә кайсы җирләреннән сасы төтен исе чыга башлар. Тагын хатыны такмаклап тавыш чыгарыр: «Ир кеше була алмадың инде!» — дип орышыр.

Мөдәмир шунда әтисен кызганып куйды. Дәрес хәзерләп утырган җиреннән сикереп торды:

— Кая, үзем кертәм!

— Утыр, укы! — дип, әнисе аны кабат өстәленә кадаклады.— Надан кеше балта остасы була алмый, икелегә-өчлегә укыган кешедән тракторчы гына чыга!

Бу вакытта Мөдәмир бүрегенә барып ябышырга өлгергән, әмма аны башына капларга, барып ишек тоткасына ябышырга җитешми калган иде. Бер чыгып китсә, тиз генә әйләнеп керергә дә исәбе юк аның.

— Утыр, укы!

Әмернең икенчесе генә иде! Өченче тапкыр кабатланганында уклау белән бергә башына төшәсенә Мөдәмирнең шиге юк анысы. Чыннан да, әнисе мич арасындагы шүрлек ягын карый башлады. Анда, табак-савытлар арасында, ипи калайлары артында, озын юан уклау иде. Әтисе салгалап кайткалаганда, башына да менеп төшкәләп, ныклыгы сыналган шома, туры таяк.

Мөдәмир артка чигенергә мәҗбүр булды. Тизрәк өстәл янына утырды, бүреген элгеч ягына ыргытты. Идәнгә тәгәрәсә дә, аны алып куймады. Барыбер анда әтисенең бушлаты һәм башка җылы киемнәре ята иделәр. Эшкә кия торганнары. Аларга элгечтә урын юк. Гомергә шулай идәндә генә яттылар инде. Ә менә яңа өйләренә күченсәләр, ул — зур, иркен, олы. Һәркайсының аерым яхшы элгечләре булыр. Хәтта эш киемнәренә дә!..

Икенче көнне Мөдәмир уянганда, балта остасы Зәки абый аларга килгән һәм яңа өйләренең түрдәге өч тәрәзә уемына яңа кәчәкләрне утырткан, ясап алып килгән тәрәзә кысаларына пыяла салып маташа иде. Малай, мәктәпкә барырга тиешлеген дә онытып, аның тирәсендә чуала башлады. Какча йөзле, сөяктән һәм сеңердән генә торган тыгыз беләкле, озын буйлы Зәки абый яңа тәрәзә кысасын өстәлгә сала,

аның өстенә пыяла куя, үлчи, тигезли, аннан соң шырт кына итә. Мөдәмиргә карап торулары рәхәт. Пыяла тип-тигез булып, нәкъ өлгесенә ярашлы ителеп киселә икән ул!

— Зәки абый, ничек бармак белән генә кисәсез шул каты пыяланы? — Мөдәмир кызыксынуын яшерә алмый.

— Нигә алай әйтәсең, энем? — Зәки абый үз эшендә, күтәрелеп карамыйча гына сорап куя.

— Әнә бит,— ди Мөдәмир, күреп торуын белдереп,— баш бармагыгыз белән генә сыпырдыгыз, ә пыяла — киселде...

— Ничек?..

— Менә болай! — Зәбир пыяла өстеннән сыпырып күрсәтә.— Ә минеке — киселмәде!

— Юк шул, энем, киселмәде! — дип, Зәки абый аңа елмая.— Минеке дә бармак белән сыпырганга гына киселми. Пыяла — каты ул! Аңа тырнакның да көче җитми. Алмаз кирәк. Ә менә ул аны кисә. Кыеп кына ала.

Һәм Мөдәмиргә үзенең кулындагы шул тылсымлы коралын күрсәтә. Ул кечкенә генә нәмәрсә хикмәтле алмаз икән.

— Ә тимерне кисәме, Зәки абый?

— Юк, энем,— ди аңа оста һәм бераздан аңлатып бирә:— Тимер, таш ише әйберләр пыяланы ваталар.

— Туп та! — дип, Зәбир аңа кушыла.

— Әйе, әллә күргәнең бармы?

— Әй лә, булды инде! Малайлар белән уйный идек... Мин тупка типтем, ә ул мәктәп тәрәзәсеннән кереп китте... Капкага бәрәсе урынга!

— Нәрсә әйттеләр соң?

— Ачуландылар!..

— Тагын нәрсә...

— Әтине чакырттылар...

— Ә ул бардымы соң?

— Әйтмәдем...

— Нигә?

— Колакны бора ул аннары йә каеш белән тукмый.

— Ә болай тимиме?

— Белмәгәч, юк инде!..

— Ә белсә?..

— Кайдан?

— Пыяласыз тормас инде ул тәрәзә! Барыбер куйдыртырлар...

— Торыр әле, берни дә булмас!

— Белмим... Әтиеңне күрдеңме соң?

— Юк, эштәдер! Ул иртүк китә!

— Ә минемчә, ул мәктәпкә бара иде.

— Ничек?

— Белмим... Чакырттылар, дисең түгелме соң?

— Әйе!.. Ә мин аңа әйтмәдем бит!..

— Димәк, бүтән эш белән киткән.

Мөдәмир шунда курка калды, бераз уйланып торды да:

— Ярый, мин дә киттем! — дип, букчасын яшереп куйган җиреннән эзләп алды, чыга башлады.

— Бар, энем, бар, бишле алып кайт! — дип, Зәки абый хушлашып калды.

Ишегалдында Мөдәмир:

— Мин дә балта остасы булам, Зәки абый кебек! — дип хыяллана-хыяллана, капкага таба атлады.— Менә яхшы булыр иде. Туп типкәндә, тәрәзә ватылса, пыяланы кисәсең дә куясың. Әти дә колакны бормый, укытучылар да ачуланмыйлар...

Авыл — үзе бер дөнья. Гадәтләре, йолалары, буыннан буынга тапшырылып киленә торган хис-тойгылары, эчке мөнәсәбәтләре белән хәтта бер-берсенә терәлешеп торган авыллар да үзләренә күрә аерым бер илне хәтерләтәләр. Монда аның үз хөкүмәте, үз идарәсе, үз тәртипләре, үз икътисади хәрәкәте, гаугалы сәясәте. Бер авылда кибетне товар кайткан көнендә үк буш калдыралар, ә икенчесендә ишеген дә ачып карамыйлар.

Һәр авылның урамындагы этләренең дә үз холыклары бар. Арбаларның гына аермалары юк кебек. Әмма, игътибар белән карап торганда, алардагы үзенчәлекле хикмәтләрне дә шәйләп өлгерәсең. Кайсылары авыр йөрешле була, ә кайсысы җиңел генә уза да китә, сизми дә каласың. Хәер, гомер дә шулай ин-

де: мескен генә авыллар да бар, ә аларда яшәүчеләр тормыш юлын җиңел генә үтәләр дә китәләр, балалары да ялт кына үсә, картлары да тынычлык белән картаялар. Ул йөзьеллык имәннәре елдан елга мәгърурлана, колач җитмәслек кәүсәләре, бүрәнә-бүрәнә ботаклары белән котны алып, җил-давылдан курыкмыйча, һаман үсәләр дә үсәләр, ныгыйлар да ныгыйлар. Ә бар шундый авыллар, казанганнары казна түгел, тапканнары яшәүләренә җитми. Бер караңгыдан икенчесенә кадәр тырмашып, якты көнне күрми-белми дә калалар. Аларның урамнарында йә бакчаларында ник бер агач, ник бер куак үссен...

Ә гомер дигәннәре, чыннан да, уза торган нәрсә икән ул. Балалар үсә, өлкәннәр олыгая... Мөдәмирнең чыннан балта остасы булып китүе сөенерлек хәл иде югыйсә. Үз дигәнен итте шул. Кайдан һәм кемнәрдән өйрәнеп алган диген? Йомычканы балтасы йә ышкысы белән каерып кына ташлый. Ул агач юнуларын карап торсаң, йа Ходаем, мидәт бир бәндәңә, диярсең. Ул бураларны бурап, йорт-мунчаларны чутлап салып куя инде, мин сиңа әйтим, умарта оясы кебек итеп, эзенә эзен, җебенә җебен китереп. Ул тәрәзә кысаларын, кәчәкләрен, өлгеләрен ясап җибәрә, йөзлегенә йөзлеге, ыргысына ырымы, чәчәгенә чугы пар килеп тора. Ул ишекләрен, баскыч төпләрен, капка һәм коймаларын әйткән дә юк! Булса да булыр икән! Уңса да уңа икән адәм баласы эшкә оста кулларыннан.

Авыл халкы Зәки абыйны сагышларга өлгермәде, Мөдәмир үзенең осталыгын мәйданга чыгарды. Дөрес, әүвәле аның булганлыгына шикләнеп карадылар. Юктыр ла, дип кенә сөйләнделәр. Әмма каралтыкураны төзәттергәләп тормасаң, тарала башлый икән ул. Анда терәү салырга кирәк, монда тарткы куярга, тегендә этке ясарга. Зәки абыйның кулы тияргә өлгермәгән мунча һәм сарайлар ишелеп, халыкның балта тота белүчене тирә-күрше яклардан биш бәясенә яллатып китерер көннәре дә җитәр дип, элекләрне һичкем уйламаган шул. Әмма бер килмәс җире бар икән аның да — вакыт тарлыгы комачаулый. Юкса әллә нәрсәләр эшләр иде. Әйтәләр бит, ниятләгән генә җитми, боерган җитә, дип, ягъни адәм баласы әллә ниләр эшләргә тели, әмма Аллаһы Тәгаләнең әмере килми торып, һичнигә ирешә алмый. Аллаһы ташламаса, бүре ашамас!

Зәки абыйның бер хикмәтле сүзе бар иде:

— Булыр, боерган булса! — дигәне.

Бу аның, Аллаһыдан насыйп икән, эшләрмен, дип сүз бирүе инде.

Яшьлеге аркасында Мөдәмир андый мәгънәләрне санга сугып бетермәде. Килешенгәндә:

— Күпме түлисең? — дип сорамый, бәлки: — Ярар яки юк! — дигән ике сүзнең берсен генә әйтеп эшкә тотына, шуның белән илгә ярый бела. Осталык — санда түгел.

Бервакыт Мөдәмир безгә килеп керде. Төн уртасында, җәйнең рәхәт һәм йокының болай да кыска чагында. Авылга минем кайтып төшкән генә көнем иде. Күздә әлегә йокы юк. Күңел моң һәм хисләр белән тулган, хатирәләрне сөйләшеп, туган-тумачаның берәмләп диярлек хәлен өйдәгеләрдән генә белешеп, абыйның кызык итеп бәянләгән хикәяләренә мөкиббән китеп, капка төбендә дә, болдырда да озаграк утырылган. Төн уртасы җитүгә карамастан, күзгә йокы кермәгән. Йолдызларны санап алабыз.

— Бу Җидегән йолдыз казакъ халкында Җиде карак дип атала.

— Нигә икән? — дип сорап куя абый.

— Мөгаен, берәр хикәясе бардыр. Җидене аңлатуы җиңел. Саннары тәңгәл килү белән бәйле. Ә карагы — ат өстендә төне буе чабып йөргән егетләр инде аның, гаярь егетләр!

— Ә ни өчен караклар соң алар?

— Төнлә генә чыкканга!

— Ә-ә, алай икән...

— Менә тагын берсе!..— дидем килеп җитеп, капкадан керергә маташкан Мөдәмирне күрсәтеп.

— Әйдә, түрдән уз!..

Аның кулында өч литрлы банка иде. Ул минем Җиде карак хакындагы сүзләремне колагына элергә өлгергән икән. Аларны үзенчә аңладымы, әллә төшенми калган идеме: «Менә тагын берсе»,— дигәннәремне шунда ук кире какты:

— Алай димәгез инде! Мин алкаш түгел! Үзе генә, кешедән яшереп эчкән кеше генә алкаш була ул! Әйеме?.. Ә мин дуслар белән генә тотам!

Мин, тавыш чыгарырга маташуыннан шикләнеп, аны-моны әйтергә ашыкмадым, абый да, аның зәһәр кубарылып сөйләшүен яратмыйча:

— Энем, тынычлан әле!.. Арыгансың, бар, кайтып йокла! — дип, Мөдәмирне китәргә үгетли башлады.

— Алай димәгез әле!.. Менә, энекәшең дә кунакка кайткан!.. Берәрне тотыйк!

Мөдәмирнең бу сүзләрен абый кабул итәргә теләмәде:

— Җиткән инде сиңа... Салгансың... Кайтып йокла! — дип, тагын да үгетләп карады.

Әмма бу үгете дә кабул кылынмады:

— И абый, усал син! Ус-сал... Энекәшең кайткан!.. Чалт аяз утырасыз... Берәрне тотыйк!..

Төн уртасында аракы сорап кереп аптырату ул елларда авылга читтән килеп кергән, шәһәрдән кайткан вакытсыз бер гадәтсезлек иде. Әйе, калада иртәнгә кадәрле рестораннар, барлар, клублар, кибетләр, супер яисә мини маркетлар эшли. Туйганчы бәйрәм ит. Ә авылның таңнан эшкә торасы бар. Җәйге йокысы — кыска, төш күрергә дә өлгерелми.

— Юк шул, энем! — диде абый, Мөдәмирнең үз юлы белән китүен теләп.

— И-и-и,— диде төнге кунак, болдырга өч литрлы банкасын куеп, авызында сасы тәмәкесен кабызып.— Сездә булмаса, бездә бар ул! Башланмаган. Бер дигән! Өч литрлы! Менә!.. Сыйланыйк... Минем өчен пүчтәк ул! Менә шушы кулларым исән булсыннар!

Аның җилкәгә салган каты һәм көчле куллары чыннан да эшчән икәнлеген дәлилли алырлык иделәр.

— Шулай түгелме? — Шунда ул дәлил өчен бу көненең нәрсә белән үтүен сөйләргә кирәк тапты: — Иртәннән эштә булдым, егетләр. Хәмигә мунчасын бетердем. Ишеген ясадым, тәрәзәсен куйдым. Хәзер аның ләүкәсен дә остадан кордыралар бит, чарачасын да... Менә бусы — «премияли»... Кибеттән аракы таба алмаганнар. Хәер, көмешкә яхшырак та әле ул! Көмешкә, диләрме әле аны?

Ул соравына җавап көтте. Мин әйе, дияргә тиеш идем. Зәбир абзый малае чыннан да шушы сүзне генә көткән икән шул. Әйтелеп куелуга, шунда ук сүземнең койрыгына үзенекен тагып, безне бетереп кыстарга тотынды:

— Әйдә әле, абыйлар... Стакан юкмыни? Казаннан тансык ризыклар да алып кайткансыңдыр!

Аны шушы килеш кенә озатып җибәрү яхшы түгел иде. Күңел тарлыгын күрсәткән кебек тоелыр йә.

— Абый, алып чыкмыйсыңмы? — дигән генә идем, Мөдәмир кабат сүз балкышына күмелде:

— Ут күреп кердем! Мин әйтәм, бөтен авыл йоклап беткән. Ә сезнең ишегалдында — ут яна, лампа. Әһә, дим, кунак кайткан боларга! Керим, сыйлыйм әле үзләрен! Мин бит сәрхуш-алкоголик түгел, ялгызым гына өч литрны чүмереп бетерергә... Әйе!.. Яхшы булды әле керүем!

Ул арада абый стаканнар һәм кабарга ризыклар алып чыкты. Мөдәмир исә көмешкәсен бүлеп куйды:

— Әйдәгез, исәнлеккә-саулыкка! — дип, күтәрергә тәкъдим итте. Эчеп җибәргәнендә йөзе дә сытылмады. Менә хәзер фуражкасын салып иснәр кебек иде, әмма кабымлыкка ризык кисәген дә йотмады. Һава алып, җилкәсен кайтарды да: — Шәп үтте! — дип кенә куйды.— Нигә эчмисез әле?..

Соравын җавапсыз калдыруны да онытып, бераздан җыр сузды. Башы кыңгыр салынган, караңгылыкка чумган дөньяны гүяки кочаклап алыр сыман иде:

Тагылый да тагылый шушы, һай,
Чишмәләрнең салкын сулары.
Баткан җирләреннән чыкмый ла ай,
Сирәк лә була бәйрәм-туйлары...

Аңа кушылып җырлау түгел, онытылып тыңларга гына калган иде безгә. Беренчедән, бу җырның көен тәүге ишетүебез, икенчедән, ни мин, ни абый аның сүзләреннән бер генә кәлимәсен дә белмибез.

Ераклардан килгән аккошларның
Каурыйлары саен бер каләм.
Минем генә сиңа язганнарның
Сүзе саен күздән яшь алам...

Бу җырның көе гаҗәеп матур, әмма сүзләре бик үк аңлашылып җитмәгән сыманрак тоелды. Мөдәмир онытылып сулыш алганда, сорарга дип абыйга эндәшмәкче идем, ә ул, төрткән сул кулымны читкә кайтарып:

— Тыңлыйк әле, бүлдермә,— диде.

Ә Мөдәмир җырлады да җырлады:

Очып үткән кошлар каңгыл-каңгыл
Сөйләштеләр бугай үзара.
Күзләр генә килсә, һаман яңгыр,
Яшь гомерем эреп югала...

Төнге күк чалт аяз иде. Ай үзенең урак очын каршыдагы калкулыкның бәгырь төбенә кадаган. Аның болай хәнҗәр кебек өшәндереп торуы күңелдә авыр тойгылар калдыра. Ничектер җанны калтырата. Җитмәсә, Мөдәмир җырын дәвам итте:

Караплар кал, кошлар ничек үзды,
Канатлары гына талмасын.
Гомер итми йөрәк бик тиз тузды,
Бәхетләрең ялгыз булмасын...

Аның җыры артыгы белән тойгылы, артыгы белән авыр иде. Әмма туктатырга батырчылыгым җитмәде. Абый да аны йотылып тыңлый бирде. Хәзер ул аның җырына кушылып китәр сыман. Әмма Мөдәмир әллә ничекләр кайнаштырып, тавышын әле югалтып, әле адаштырып, әле шашындырып, әле тындырып җырлый бирде. Юк, ул җырлый гына түгел, үкереп-үкереп елый да иде бугай. Әмма бу елау асыл ирләрнеке, күз яшьсез, бәгырь киселүе...

Тагылый да тагылый сулар, һай,
Ермак булып агып калдылар.
Баткан җирләреннән чыкты ла ай,
Аккошкайлар түйлап алдылар...

Кем белә, бәлки, аның бу җыры тарихларга калыр?

Мөдәмир йөрәген тотып тукталды. Ялкынлы бер аһ орды. Мин аннан:

— Синең үз көеңме әллә? — дип сорамакчы идем, бу кызыксынуым ахмаклык кебек тоелды. Хикмәт кешенең җыр чыгара алуындамыни? Хикмәт һәркемнең үз җыры булуда шул! «Туган тел», «Кара урман», «Сарман», «Рамай», «Уел» — тагын әллә күпме меңләгән җырлар бар, әмма аларның арасыннан тик берсе генә яки, күп булса, өчесе-дүртесе генә синеке. Үзең чыгарганлык мәҗбүри түгел, шарт та ителми. Ә йөрәгеңә, җаныңа ул иң якыны. Авыр чакта — юата, туйларда — бәйрәм иттерә, сокландыра, елата, биетә. Шундый җырың юк икән, җаныңның кыйбласы, бәхетеңнең таҗы, сагышыңның даруы да юк дигән сүз!

Мөдәмир, өч литрлы көмешкәсен кочаклап, кайтып китәргә итте, ахрысы. Хәер, җырын тәмамлауга, күңеле дә бушанып, бераз җебебрәк төшкән иде шул. Арыган ул, бик арыган...

Кул-беләккә генә түгел, ул аяк-гәүдәгә дә нык булып чыкты.

— Кайтыйм мин, абыйлар! — диде дә кузгалды.

Бераз озата барасы иттек. Басмага җитүгә, үзләренә кыстый башлады. Вакытның соң икәнлеген аңлаткач, безнең дә йоклыйсы, ял итеп аласы барлыгын искәреп, куллар бирешеп саубуллаштык. Соң дигән вакыт инде иртәнге як иде. Таң атып килә, аяк астындагы сукмакның күзгә чалына башлаган чагы.

Тыкрыктан Мөдәмир үз урамнарына таба менеп китте. Челтерәп чишмә акканы ишетелде, инешкә кушылып, еракка-еракка ашыга иде ул. Күңелләрдә Мөдәмирнең кинәт ачылып китүеннән калган сагышлы моң иде.

Йокының кыска булуы хәерле, диләр. Көннең дә эш белән узганлыгы сизелми калды. Икенче кичтә абый белән, яшьлек урамнарын таптап, клуб якларын да бер әйләнеп кайтырга булдык. Мөдәмирне озатып калган басма аша чыгып, чишмә янына таба күтәрелә бирдек. Нигәдер җыр сузасы килеп китте. Әмма алай кычкырып җырлау гадәтебездә юклыктан, борын төбендә генә шыңшып алудан уза алмадык. Чишмәгә тукталып, су эчтек.

— Тәмле икән!

— Әйе шул, безнең авылның суы да башны төзәтә!

Бу сүзләрне әйткән кешенең тавышы таныш, ул, Мөдәмир иде. Култык астына кыстырган кичәге өч литрлы банкасының төбендә көмешкә чупыл-чупыл килә.

— Әллә берүзең эчеп бетергәнсең?

Абыйның үртәп соравын Мөдәмир яратып бетермәде, тавышын усалландырды:

— Ә минем сезнең белән эчәсем килгән иде,— диде.— Менә, энекәш белән абый авызлыкланганнар. Әнкәйгә яшерергә кушкан идем. Мал утлыгыннан табып алганнар, хәерсезләр. Йокланылган, туйганчы чөмергәннәр!

— Сыер түккәндер? — дидем, юри шаяртып һәм ачуын басарга теләп.

— Булыр...— дип, Мөдәмир сүзләремне канәгатьсезлек белән кире какты.— Моны сыер эчә димени? Адәм кебек юләр түгел лә ул!

Безнең әйтер сүз юк иде. Ни дисәк тә, Мөдәмиргә ярап булмаячак, аңлашылып тора.

— Сез кая киттегез?

— Клубка,— дидек, абый белән берьюлы.— Ә син кая?

— Сезгә!

— Нигә?

— Белмим...

Ул безне эчәргә дә кыстап карады. Әмма баш тарткач, үпкәләде, ахырда үз юлы белән китеп барды. Урам буйлап без клубка таба атладык. Юл уңаенда яңа йортлар да күзгә чалындылар.

— Боларны кем төзи? — дип сорауга, абый:

— Кем булсын, Мөдәмир! Кулы алтын аның,— дип аңлата барды.

— Алай! — дидем, сөйләгәннәрен җөпләп.

Зәки абыйга лаеклы алмаш үскән икән. Балта осталары булган авыл — бәхетле авыл ул...

Һәркемнең язмышы үзенчә һәм үзенәчә инде. Вазифам сәбәпле бик күп җирләрдә, илләрдә йөрергә туры килде. Төзек, ныклы, таза ихаталы авылларда да, җимерек, төссез, караңгы салаларда да булдым. Кайларга гына барып чыксам да, аларның балта осталары хакында белештем.

— Кулы белгән кешеләр юк инде хәзер, менә элегрәк бар иде алар,— дип зарланучыларның хәлләрен менә хәзер генә аңладым.

Йорт-җирне осталардан башка яңартып та, тәртиптә тотып та булмый шул. Өеңне сипләгәндә дә җаен белүче, йөрәге җитеп тотынучы кирәк. Кулга оста кеше кадакны да, әллә ничек итеп, җаена китереп, нәкъ урынын белеп кага ул.

Авылыма кайтып, Мөдәмирнең кул көче кергән йортларны күрсәм, теге вакыттагы төн уртасында җырлаганы исемә төшә. Ул төзегән өр-яңа йортлар да шул ук көйгә җырлыйлар сыман. Ә Зәки абыйның көе нинди иде икән? Әнә ул төзегән йортлар, алар — бүтәнчәрәк, ямьнәре дә башкачарак. Димәк, аның җыры да үзгәчәрәк булган икән!

Тукталып тыңлап алам. «Тәрәзә төбең үрмә гөл!..» дигән җыр сүзләрен ишеткәндәй булам. Ниләр хакында икән ул? Мөгаен, бәхетле тормыш турындадыр! «Кояшка көлеп карый...»

*Август, 1999*

# Буа шикәренең тәме

Зурдан кубып,ерактан алып килеп сөйләп торасы түгел, вакыйга болайрак булды, дим дә башлап китим әле. Бәлки, сүзем шулай үз җаен табып, үзәненә керер дә агып китәр.

Буа шәһәрен белмәгән кеше, мөгаен, дөньяда бер дә юктыр. Шәһәрчек кенә, дисәм, ялгыш булыр, кызлары бик чибәр аларның, үпкәләүләре бар!..

Яшь чагымда күп җирләрдә йөрелде. Юл ярагын һәм ерагын уйлап торучы түгел идем. Дөнья һаман да итекләремне иярләргә мине мәҗбүр итә торды. Юл тузаны йөзгә һәм киемнәргә генә түгел, хәтта җанымның ак сөрүенә дә сара башлаган чаклар була иде.

Бервакыт шулай, Мишәрстанны иңгә-буйга айкап, Ульянга килеп төштем. Кайда гына булсам да исем китми, телем барыбер Казанга алып кайтыр дип белә идем. Чөнки юлчыга юлны өйрәтеп җибәрүне һәркем изге гамәлдән саный, яхшылык белән йөргән кешене кайсы адәм адаштырсын инде? Хәтта җен дә, олы утырышта Хафиз исемле үзалдына саташып алган бер танышым кебек, ахмаклыкка акылын корбан итмидер лә? Хәер, нәрсә эшләмәк кирәк, Хафизны юкка гынамы Корбан дип йөртәләр. Фамилиясе дә шулай түгелме әле? Ә юк, бутыйм бугай!.. Һе, әллә чыннан да Корбановмы?

Ярар, тагын да бер Корбанны белә идем. Аны муллалары, салмыш хәлдә ялгышып, Корбангали атаган, ягъни тууына ук ул бала «бөек корбан»га әверелгән, мәсәлән, Исмәгыйль пәйгамбәр мисалында. Ул Корбангалинең дә, бу кадәрлесен искәртеп тормасак та, эше һәрдаим үзен корбан итүдән гыйбарәт икәнлеген күпләр белә иде.

Бер дә яшереп торасы түгел, минем үземнең дә бер дәү бабамның исеме Корбангали аталып, халык кына болай исемләп эндәшүне җайсызга санап, Корбангали урынына Корбый дип йөртә башлаган. Аны бик тә изге һәм акыллы зат булган, дип сөйлиләр. Авылыбызда электән Корбый чишмәсе, Корбый карамасы, Корбый тыкрыгы, Корбый аланы атамаларын йөрткән урыннар күп иде. Ул дәү бабамның изгелекләре һәм игелекләре һаман да искә алынып, хәтта бер вакыйганы күңелемә дә бикләгән иделәр. Имеш, Корбый карамасы адәм теле белән сөйләшә белгән икән. Бервакыт сыерлары кышның иң салкын көнендә бозаулаган. Ә Корбый бабамның Герман сугышында йөргән вакыты бу. Хатыны өйдә йон җегерләп утыра икән. Тәрәзәсен шакыганнар.

— Кем ул анда? — дип, дәү әбиемнең килүе булган, Корбый бабамның карамасы шыгырдый икән.

— И, бигрәк суык, агачлар да өши торганнардыр инде! — Дәү әбием шушы сүзләре белән канәгатьләнеп, тагын да орчык тәгәрәтүен дәвам иттергән.

Әмма:

— Өшермен мин сиңа, көт! — дигән карама агачы, адәм теле белән ачуланып.— Бар, абзарыңа чык, анда сыерың бозаулады, туңдырып үтерәсең үзен!

Дәү әбиемнең коты очкан. Ничек абзарга йөгереп барганын сизми дә калган. Анда, чыннан да, яшь бозау, салкыннан калтыранып, боз элпәсенә капланган хәлендә катып тора икән, әйе!..

Әллә ниләре бар бу дөньяның. Кемнеңдер моңа ышанасы да килмәс. Әмма мин үзем Корбый бабам тыкрыгыннан төшкәндә, ботакларын сузып каршы ала, башымнан сыйпап озатып кала торган ул карама агачыннан шикләнә, хәтта бераз шөлли-курка да идем. Үсә барганымда гына ул миңа якын һәм үз булып тоела башлады. Ничек шулай ниятләнгәнмендер, белмим, нигәдер шул агачка зарымны сөйлисе иттем.

Казаннан кайткач, аның янына дип барган идем, ә карама — Корбый бабамның шанлы тарихи агачы — юк! Бөтенләй дә төпләп ташлаганнар. Әнкәйдән, өйдә сүз ара сүз чыккач, сораган идем:

— Мөнир абыең кискән, шуннан соң бәлаләнде,— дип кенә җавап бирде.— Аның иясе бар, шулай ишеткәләдем. Үпкәләтергә ярамаган. Бакчасын каплап торганга яратмагандыр инде, аударган... Ходай Мөнир абыеңа саулыгын бирсен!

Корбый бабамның чишмәсе өстеннән дә зур юл узды. Асфальт. Дөрес, ул чишмәне торба белән яр читенә чыгардылар. Суы һаман да тулып ага. Шифалы, диләр. Аңа хәзер «Дүсем чишмәсе» исемен бирделәр. Юлчыларның сусавын баса. Әмма пычратучыларны казага юлыктыра, имеш. Шулай микән, әллә юкмы, анысын ук бәхәс итә алмыйм. Әмма аның агышында ниндидер йөрәк типкән тавышның барлыгын яхшы беләм. Бәндәләрнең серен аңлый бугай ул! Борынгыдан килгән хәбәрләрдә телгә алынучы Әүлия чишмәсе дигәннәре дә шул түгелме икән?

Хәер, Әүлия чишмәләре күп җирләрдә, төбәкләрдә, авылларда бар. Борынгы тарихи китапларны эзлиэзли, төрле якларга барып чыгарга туры килде үземә, дөньяда акыл белән аңлатып биреп бетереп булмый торган күп серләрне алардан өйрәндем. Хәерлегә булсын! Дөньялык үзен көяз хатын-кыз кебек тота, уңы белән дә ята, сул ягыңа да чыга, йөзеңә дә суга, хәтта калдырып китеп тә бара икән ул...

Бу Хафиз Корбанны искә алу гына да фикерне әллә кайсы якларга алып кереп китте, хатирәләремне бөтенләй катнашы булмаган вакыйгалар агышына мәҗбүри корбан иттерде, хәерлегә булсын! Дөрес, юл йөргәндә, әллә ниләр уйланыла, үткән-беткән хәлләр күңелдә яңарып, ялгышуларың өчен ачынасың, хаталанулар исә ачуны китерәләр, тәүбә өне тел очына килә башлый. Бу уйланулар да шуның бер галәмәте инде.

Ульян шәһәрендә шактый таушалып, елга портына килеп җиткәндә, Казанга китүче соңгы метеорны кул болгап озатып калучыларга очрадым. Мине көтеп тормаган икән шул.

— Аһ! — диеп өлгермәдем, шунда ук халык җыелып:

— Әллә поезд белән генә кайтасызмы? — дип, сораулы киңәшләрен биреп карадылар.

— Кичке тугызларда гына була шул,— дидем, вокзалдан килүемне әйтеп.

— Олы юлга чыксагыз, ничек булыр? Машиналар бездән Казанга йөреп кенә торалар! — диделәр, тагын да киңәш итеп.

— Белмим инде...— Икеләнүемнән алай мәшәкатьләнергә теләгем юклыгын шунда ук аңладылар булырга кирәк, беразга сүзсез калдылар.

— Сез алай итегез,— диде арадан бер чибәр ханым.— Хәзер Тәтешкә метеор китәчәк, аннан Буага барырсыз. Анда бик якын кала!

Минем йөземә шатлык билгеләре чыгуын күреп, сүзен тагын да дәвам иттерде:

— Буадан Казанга поезд йөреп кенә тора... Шәһәр яны поезды...

Башкалар да аны куәтләделәр. Һәммә киңәшләр өчен дә рәхмәтле идем.

— Тизрәк барып билет алыгыз! — дип әйдәүләре мине кассалар янына йөгертте. Чибәр ханым хаклы булып чыкты. Ярты сәгатьтән мине метеор Идел өстеннән очыртып диярлек алып китте. Укылган китапларымнан Тәтеш хакында язылганнарны исемә алып, ул шәһәрчекне хыял киңлекләрендә күзалларга тырышып карадым. Нурихан Фәттахның бер хикәясендәгечә, Иделдән Тәтешкә йөздән артык басмалы баскыч күтәрелергә тиеш иде. Һәм мин дә, тарих сәхифәләрен гүяки үз күзләрем белән күргәнемчә итеп хыялымда барларга теләп, күзләремне йомдым, шул әдибебезчә озаклап югарыга, Тәтешкә таба менәчәгемә сөенеп шөкрана кылдым, билләһи!

Бу уйлар күңелемне җылыттылар. Идел буйлап алга төбәлдем. Акчарлаклар кичке шәфәкъ нурыннан алсу төскә чумып-буянып оча, хәтта бу кыяфәтләрендә сокландыргычрак тоела иделәр. Киң һәм мәгърур елганың матурлыгы дәрьядай муллыгында гына түгел, бәлки ярларының көязлегендә дә икәнлеген моңа кадәр белми-күрми генә йөргәнмен бит. Ә Татарстан аша агып узганда, Идел нәкъ шундый бер гүзәлкәйгә әверелә ки, сөекле егетенең затлылыгы алдында үзенең буй-сынына сокланган кызны хәтерләтә. Менә тиздән таза беләкле җанашы аның биленнән кочып алыр, шаяртып сүз катар, сиздерми генә бит очына иренен тидереп узар. Сылукайны ут алгандай булыр. Әмма...

Әмма Иделне Самарада бикләгәннәр шул. Элеккеге ашкын сулы, уйнак һәм назлы Чулман елгасы урынына хәзер симез һәм җаенке гәүдәле иләмсез Чулман Иделнең өстенә ябылган ефәк җәймәсе астына, «Кая әле минем урын?» дигән сыман, йөзен сыткан хәлдә килеп ята. Иделбикә бу вакытларда нинди хисләр кичерә, нәрсәләр уйлый икән? Бер Ходай үзе генә беләдер инде!

Тәтеш миңа, чыннан да, көтелгәндәге матурлыгы белән бергә хозур да кебек тоелды. Калын һәм биек яры да озын һәм йөз басмалы баскычын текә куеп каршы алды. Килеп тукталган чагыбызда гына автобус та күренде. Минем арттан төшеп килә торган яшь егеттән:

— Бу баскычта чыннан да йөз басмамы? — дип сорадым.

Ул миңа елмаеп җавап бирде:

— Кем санаган инде аны? Бардыр-бардыр... Булыр-булыр...

— Әллә санап менәбезме?

— Кая ди ул!.. Әнә, безнең бәхеткә автобус килгән, китеп барганчы утыруыбыз хәерле!

— Миңа Буага кадәрле иде шул. Вокзалга! Ул бармый торгандыр бит?

— Шушы инде, моңа эләгеп калырга кирәк. Эшчеләрне алып китәргә килгән. Бүтәне булмаячак...

Чыннан да, ул автобуска елга буе эшчеләре төялешеп маташа иделәр. Юл өстендәге ташларга да игътибар итеп тормастан, тараканнар кебек без дә автобуска йөгерештек. Буага кадәр үк икән, рәхмәт төшкере!

Мин Тәтешне юньләп күрми дә калдым. Кызыл автобус шәфәкъ алсулыгында тагын да кызарып, асфальт юлдан ялгызы, монда гына барып килергә тиешле кебек ашыкмыйча, Буага таба юл алды.

Табигатьнең тук чоры, алма җыяр вакытлар. Автобустан авылсыз калган таш чиркәү манараларын, мәчетсез ялгызлыкта янтайган салаларны күзәтеп бардым да бардым. Мине ниндидер бер рәхәтлек һәм үземнән, дөньялыктан канәгатьлек хисе биләп алган, ә алда сөенеч һәм шатлыклар гына көтәдер сыман иде.

Хактан да шулай ул, килер көнеңдә хәсрәт һәм мәшәкать очрыйсы булса, кәефең китә, һичбер сәбәпсез күңелең бозыла, ачуың кабара. Бәхеткә таба юллангансың икән, киресенчә, җаның һәр җирдә канәгатьлек таба. Аннан соң шунысы да бар шул әле аның: ризалык һәм сөенеч тойгылары үзләре үк кешене сәгадәт юлына алып керәләр. Шуның өчен дә элек-электән әдәп һәм канәгатьлек хисен адәм баласы үзендә тәрбияләргә омтылган, комсызлыкны, үзсенүне Аллаһы Тәгалә дә үзенең Изге Китапларында кире каккан.

Әмма ул вакытта мин болар хакында уйлап тормадым. Рәхәтлек дәрьясында йөзүче диңгезче сыман татлы тойгыларны күңелгә җыйный бардым. Һич тә яшермим, хәтта шагыйрьләрнең дә мондый халәткә күтәрелгән минутлары сирәк була, алар, күбрәк үз кемлекләре хакында мәшгульлекләре аркасында, анда үк ирешә алмый калалар. Кызганыч. Хәтта аяныч. Никадәр гүзәл шигырьләр халыкка белдерелми, тәкъдим ителми, йөрәк кылларының моңына җыр булып кушылмыйча-ирешмичә калдырыла. Фәрештәләр авазын ишетәсе иде!

Буа дигәннәре, шәһәрчекләргә хас булганча, матур, тыныч һәм тәүфыйклы кыяфәтендә ашыкмый-кабаланмыйча, канәгатьлек белән яшәүче шәһәр. Ул мине шушы рәвешендә каршы алды. Автобустан төшеп, вокзалга таба җәяүләп атлаганымда озата, хәтта тыкрык һәм урамнары буйлап юл күрсәтә барды. Кичке эңгер иңеп кенә килә, төнге унбердә генә Казанга таба үтеп китәчәк поезд килергә әлегә иртә, ә шәһәр яны дизель вагоннары инде бүгенгә йөрүдән туктаган икән. Ашыгасы түгел.

Буа шәһәре үзе дә кабаландырмады. Вокзалларын монда гына, җәяү генә барышлы, дисәләр дә, урамнарының бер очларыннан икенче башларына кадәр килә-килә, аяк табаннары юкара башладылар, йортларда һәм баганаларда утлар эленде, светофорларда яшел, кызыл, сары төсләр бергә кушылдылар, бөек караңгылык һәм зәгыйфь яктырткычлар гына калды. Күк йөзенә йолдызлар түгелде, читтән генә ярымай күзен кысты.

Мин барып кергәндә, вокзал эче бөтенләй дә буш иде. Поезд килергә ярты сәгать кала гына билетларны сата башлыйлар икән.

Җай алып, эскәмиягә утырдым. Тойгыларымны артык сүз белән өзәсем килмәгәнлектән, ялгызлыкны үз иттем. Әмма бераздан кузгалырга туры килде. Ярым караңгы вокзалның икенче башыннан торып, миннән нидер сорап эндәштеләр. Ул арада бала шыңшыган тавыш та ишетелде. Ярдәмем кирәктер, дигән уй белән яннарына барсам, вакытны сорыйлар икән. Аңышмаганмын. Сүзләре, буш диварларга бәрелеп, каерылып ишетелә, ачык кына төшенеп тә булмый.

— Тугыз тулып өч минут кына узды әлегә,— дидем,— сәгатем дөрес күрсәтсә...

— Мондый егетләрнең дә сәгате дөрес күрсәтмәсә...— дип шаяртты ярым караңгылыкта да чибәрлеге күзгә төртелеп торган туташ.

Мин аңа карап тын калдым. Озын, үрелгән чем-кара чәче, гүзәллектә гүяки тиңе юк буйга сылу татар кызы.

Адәм баласы да шушы кадәр камил чибәрлек иясе була икән, дип, күңелемә дә керткәнем, уема да салып караганым әлегә юклыктан беразга каушап калдым. Юлдашы да матурлыкта бер кашык су белән йотарлык, бераз кечкенәрәк буйлы яшь ханым иде. Аның куенындагы сабые аваз салган икән. Уянган, биләвен иркенәйттереп, елмаеп ята.

Үземнең сурәт-кыяфәтем әллә ни түгел кебек тоелып, тизрәк алар янынннан китү ягын карадым. Әмма ике адым да атлый алмадым, кире бордылар:

— Бәлки, безнең белән утырырсыз, ялгыз башыгыз каңгыраганчы?..

Мин, тагын да кыенсыныбрак:

— Әгәр рөхсәт итсәгез...— дидем, икеләнүемнән чыга алмыйча.

— Казанга барасызмы?

Бу сорауны биргән туташны кайда юллавым чыннан да кызыксындыра идеме, әллә башка бер сәбәбе бармы — боларын уйлап тормадым. Шунда ук җавап катыш үзем дә соравымны бирдем:

— Сез дә шунда түгелме?

— Әйе...

Күндем, юл биштәремне алар янына күчереп куйдым. Аны-моны эндәшмәдем. Нигәдер сөйләшәсем килми иде. Тагын үземне тынлык хөкеменә бирдем. Шунда вокзал эченә бер төркем яшь-җилкенчәк килеп керде. Бераз төрткәләшеп-эткәләшеп, тәмәке тартып, көчләрен кая сарыф итәргә белмичә тордылар да безгә таба атладылар. Чибәр туташ минем янгарак килеп утырды һәм култыклап алды:

— Ярыйдыр бит?

— Рәхим итеп,— дидем, шунда гына үземнең аларга ни өчен кирәк булуымны аңлап.

Шулайдыр шул, матур әйбергә күз төшүчән була. Бигрәк тә тәртип һәм әдәп ягы шикле адәмнәр андыйларга кызыгуларын яшерә алмыйлар, яисә, урлап, үзләренеке итәргә тырышалар. Боларга андый бәйләнчекләр элгәрерәк тә очрагандыр, шунлыктан туташ миңа сыену ягын караганлыгын аңладым. Теге яшь-җилкенчәкләр безгә таба һаман да якыная бирделәр. Әгәр дә телләренә яки кулларына юл бирсәләр, ничек тә сынатмаска тиеш идем. Шунлыктан үземне иркен тоттым, йөрәктә курку әсәрен калдырмаска тырыштым. Әмма ул егетләрнең батырлыгы җитмәдеме, яныбыздан узып, икенче почмакка ирештеләр. Тезелешеп утырдылар, әшәке генә сөйләшеп алдылар. Бу вакытта мин инде торып баскан идем. Имеш, гәүдәмне күреп булса да, бәлки, тынычланырлар. Шушы өметемнән өркегән йөрәк сикеренде. Минем бәхеткә, ул яшь-җилкенчәкләр, сыйракларын сөйрәп, төкеренеп һәм тәмәкеләрен тарта-тарта чыгып киттеләр. Без аларны кызыксындырмыйбыз, янәсе.

Ул арада, форсаттан файдаланып, туташ белән яхшылабрак танышып алдым. Исеме дә матур гына икән — Гөлгенә!

— Ә үзеңнеке ничек?

— Альберт...

— Бик үк татарча түгел икән!

— Нигә?

— Болай... Яңа исем дигәнем...

— Хәзер шактый егетләрдә шушы исем!

— Шулай да саф татарча булса, матуррак инде ул...

— Алай икән... Камил, Хәмит, Мөхәммәт...

— Әйе!

— Аның алары да гарәпнеке шул! Сатыбалды, Бармакборды, Соңбала, Ирдәүкә — болары чын татарныкы.

Туташ та, ханым да рәхәтләнеп көлештеләр. Асылда, мин шаярта идем шул. Үземә дә кызык булып тоелды. Чыннан да ятрак, мәгънәләре аңлашылмый торганрак исемнәр аралашу өчен җайлырак шул. Саф татарчаны хәзер кушамат урынына гына кулланалар.

Без шулай тагын да якынрак булып танышып киттек, бераздан, күптәнге якын дуслар кебек, әле шаян сүз белән, әле җитдилеккә бирелеп сөйләшә башлаган идек инде. Урамга чыгып, йолдызларны санап кердек. Әгәр шунда иреннәр иреннәрне эзләп тапса да, һич гаҗәп тоелмас иде. Гөлгенәнең тавышы ягымлы, хәтта ниндидер серлелек белән тулып ташыган кебек тоелганлыктан, һаман да аны тыңладым. Дөрес, егет кешенең аз сүзле булуы яхшы сыйфат, әмма авызына су кабып кына йөрүе дә әйбәт түгел. Әмма тел бавым чишелергә ашыкмады. Дөресрәге, миңа тыңлап кына йөрүе рәхәт иде. Һәм менә сүзсезлек безне тыныч кына озата башлады.

— Нигә бер дә сөйләшмисез? — дип сорады туташ.

— Сөйләшәм,— дидем җавабымда,— бәлки, сөйләми генә торганмындыр.

Миңа ничектер җаннарыбыз үзара бер-берсен аңлашалар, ә телдән чыккан сүзләр коры һәм буш авазлар гына кебек тоелдылар. Һай, рәхәт иде, бик рәхәт иде миңа.

— Кем белән сөйләшәсез?

— Сезнең белән, йолдызлар белән, әнә, ай белән...

— Сәер кеше икәнсез...

— Шулай тоеламы?

— Юк... Сүзләрегездән чыгып кына әйтәм.

— Ә сезнең йолдызлар белән сөйләшкәнегез бармы?

— Ничек дип әйтим... Бар... Аны мин түгел, күңел сөйләшә...

— Менә минем дә шундыйрак халәттәге чагым.

Бераздан туташ тагын сорау бирде:

— Ә йолдызлар нәрсә диләр?

— Йолдызлармы?..— Аптырабрак калам. Ни дисәм дә, дөресе — йолдызлар телен аңламыйм. Миңа аларның бары тик барлыгын күрү, үзем белән сөйләшәләр дип белү хисен тою рәхәт. Шул гына. Бәлки, боларны, яшермичә, үзенә дә әйтергәдер? — Алармы? — Бу, уйланып, бер карарга килер өчен бирелгән соравым.

— Әйе, алар, йолдызлар!..

— Алар: «И Альберт, Таң йолдызы Зөһрәдәй чибәр кыз янәшәсендә барасың, ә үзеңнең күзләрең — бездә, безнең белән сөйләшмәкче буласың!.. Аның белән сөйләш, аны ярат!» — диләр.

Минем бу сүзләрем Гөлгенә туташның күңеленә хуш килде бугай, сулышы үзгәреп алды. Тагын да урам әйләндек. Балалы ханым аның тутам тиешле апасы икән. Әбиләрендә кунакта булганнар. Ә үзләре Казанда яшиләр, ди.

Сөйләшеп йөри-йөри, вакыт узып та китте. Бер-беребезгә карата хөрмәтебез белән бергә мәхәббәтебез дә йөрәк түрендә тамыр җәя башлады. Поезд килеп, бер вагонда урыннар алдык. Әмма халык күп булу сәбәпле, хәтта утыргычларның почмаклары да буш түгел диярлек иде. Кеше өстендә кеше. Менә, безнең бәхеткә, бер эскәмияне бушаттылар. Өчебез бергә утырырга булса да җай табылды. Поезд җиңел тибрәнүдә юлын дәвам иттерде. Төн уртасы җитеп килү сәбәпле, күңелләрне йокы сөреме биләде. Ханым, Гөлгенәнең апасы, баласын кочкан хәлендә ятарлык җай тапты. Ничек тә кысылып, аңа урынны иркенрәк иттердек. Шунда эреп барган Гөлгенә туташ башын минем җилкәмә салды. Ә бераздан иреннәр иренгә кушылдылар. Аларның таты йөрәкләрдә тамыр җибәргән мәхәббәт орлыкларына шифалы яңгыр кебек тәэсир итте. Минем бүселеп үк китәргә хакым юк иде. Безгә каршы якта утыручылар, әледән-әле күзләрен ачып-йомып, гүяки икебезне дә күреп-танып калырга тырышкан сыман игътибарлы иделәр. Әмма Гөлгенә туташ аларга карап тормады, кочагыма тагын да ныграк елышты. Аның кайнарлыгы сөякләремне эретте. Иреннәрем кабат-кабат аның иреннәре татын җыйды. Без шулай кочаклашкан килеш утырган җиребездә йокыга талганбыз. Яшермим, төне буе үземне чәчәк бакчасында гизүче итеп тойдым, төшләремдә җиденче кат күкләрдә, җәннәт сарайларында йөрдем.

Поезд тукталган саен, вагоннарга халык тула торды. Иртәгә — дүшәмбе. Мөгаен, Казанга, эш урыннарына һәммә кеше вакытында барып җитәргә ашыга торгандыр.

Бер дә талмый кочакка сыенып килгән Гөлгенәдән кулларда һәм беләкләрдә кан оеган булса да, сер бирмәдем. Күзләрем дә бу уянуымда ябылырга теләмәгән кебек иделәр. Ә бераздан туташым башын тезләремә күчерде, инде шул халәтендә тынычлап йоклап китте. Вагонның бишек кебек тибрәтүе, һавасының бозыклыгы һәм эсселеге, халыкның артыгы белән тыгызлыгы — һәммәсе дә безне кирәкмәгәнчә баласыта, бөтен җиһанда икебезнең генә ялгыз калуына ышандыра кебек иде. Тагын оедым. Йокы аралаш ни булганын белмим, әмма кырык күзнең берьюлы безгә карап торуыннан икебез дә уянып киттек. Бу мизгелдә бер-беребезне кысып кочаклаган самими гашыйклар халәтендә идек. Тәүфыйклы кешеләр төсле тәртипкә кайттык, ягъни кочакларыбыздан чыктык.

Ярты сәгать тә үтмәгәндер, поездыбыз Казан вокзалына килеп тукталды.

— Син мине озатма! — диде Гөлгенә.

Җавапка нәрсә әйтергә дә белми торганымда ике багана-багана адәм керделәр. Минем белән кайткан ханымның һәм туташның чемоданнарын алдылар, саубуллашырга да бирмичә, бергә чыгып киттеләр. Вагон тәрәзәсенә капландым. Алар платформага килеп тукталган «Волга» машинасына төялделәр дә китеп бардылар. Мин бөтен дөньяның гүли башлаганын, күкләрнең җирдән ераклашканнан ераклашуын, йолдызларның күптән сүнеп беткәнлеген, бәхетнең канат та сыпырмый узуын гына тойдым. Тагын бары тик белем артыннан гына йөгерүче мескен студент кисәгенә әверелеп калдым. Тулай торакка кайтып торасым түгел, туры университетыма барасы иттем. Трамвай шәһәр урамнарына шудырып кына алып кереп китте. Мин үземнең бу сихри төндә җәннәткә адашып кереп, шуннан саташып чыккан булуымны аңлап алдым.

*Июль—август, 1999*

# Ялгышмагыз, җәмәгать!

Гатаулланы тора салып юри яманлыкта гаеплиләр. Белмим, кайлардан чыгып, нәрсә өчен шулай әйтәләрдер? Ялгышалар, саташалар булырга кирәк!

Әнә, күршеләре, Фәтхетдиннәр килене, беркөнне нәрсә дип торган була? Имеш:

— Гатаулла ялкау ул, шәһәрдән энесе булышырга кайтмаса, печәнгә дә төшми!

«И ахмак, и юләр! Гатаулланың кимендә өч еллык печәне иләмсез зур лапасына тутырылып куелган килеш тора»,— диясе генә иде инде үзенә. Аңламас шул, ышанмас.

— Аның ике сыеры, бер кышлау үгезе, сигез сарыгы, тагын әллә никадәр мал-туары бар. Аларны ашатырга гына да ничә олау печән кирәк,— дияр.— Әнә, безнең кәҗә кадәрле танабызга, ике бөртек сарыгыбызга салам да җиткереп булмый, кая ул печән генә?..

Әйтүен әйтер, әмма ире, үзе һәм баласы белән бергә каенаталары җилкәсендә егерме биш ел буена ятуларын, ә кияүгә чыккан кызларын кайтып кермәскә мәҗбүр итүләрен, гаиләнең бүтән кешеләренә почмак та калдырмауларын теленә дә алмас. Ә Гатаулланың шыгырдап торган йорт-җире, каралты-курасы дөньяда бер. Әнисе белән икесе генә иркендә, ризыкларын һәм күңелләрен мулдан тотып, бәхет белән яшәп яталар. Менә шушыларын гына исәпкә алсалар да, кемнең ялкау, кемнең тырыш булуын ачыклавы авыр булмас. Әгәр Гатаулла ялкау икән, ул вакытта тырыш кеше, дип әйтерлек кем бар соң? Әллә шул телгә беткән мескен киленнең ире, Фәхретдин абзыйның кырыкны узып та үз нигезен кора алмаган улы Батталмы?

И ахмак, и надан, дияр идек тә ул киленгә, укытучы кешегә атап алай әйтү бер дә килешмәс, югары белемле шул. Бары тик актан караны гына аера белми икән, бичаракай.

Мин әле менә Гатаулланы якларга булдым, сукырларга иярмәскә уйладым. Хәер, ул моңа мохтаҗ да түгел, әмма дә ләкин...

Кайсыгыз белми икән, берәүләр тырышлык күрсәтеп, тормышын җайга салып, авырлыкларга һәм салкыннарга-эсселәргә дә түзеп, килер көне өчен көч түксә, ул кешене яки комсызлыкта гаеплиләр, яисә юләр, дип сөйли башлыйлар. Халык уртача һаваны, уртача холыкны һәм, гомумән, уртачаны ярата кебек. Бераз гына юмарт та, бераз гына саран да, бераз гына бай да, бераз гына ярлы да булучыларны мактый һәм бераз гына тырышучы да, бераз гына ялкауланучы да икәнсең, синнән дә шәбрәк адәм дөньяда юк кебек, телдән-телләргә йөртелеп сөйләнеләдер сыман. Әмма болар гына җитми икән әле, чөнки, чүт чалымланырлык кына булса да, сөйкемле сөягең кирәк! Ул юк икән, кеше арасына чыгарлыкмын, мактаулы телгә керермен димә!

Ә менә Гатаулланың сөйкемле сөяген сындыручылар табылды. Малай чагында да, үсеп буй җиткәч тә, сугышып-кайнашып та, аракы эчертеп мактап та, машина-трактор белән изеп узып та түгел! Көнләшүдән!..

Ул рәнҗи белми иде. Кызларның чибәрләрен генә кочты, киемнең яхшысын гына киде. Әмма көнчелек белән аны харап иттеләр.

Барыгыз да беләсез, Гатаулла яшьли, әйтер идем, бала вакытларыннан бирле тырыш булды. Әти-әнисенә, күрше-күләнгә һаман да ярдәме тия торды. Унике яшеннән комбайнчы ярдәмчесе хезмәтен башкарды. Елгыр һәм сизгер, әйтелгәнне ярты сүздән аңлаучы иде. Әмма хәйләли белмәве харап итте аны.

— Юләр бит ул, ахмак, шуңа да көчен әрәм-шәрәм итә. Утырып кына йөрисе урында да тик тора белми,— дип, аның өстеннән көлеп һәм хәкарәтләп көнчеләр сөйләгәч, нишләсен, үзен тыя төште. Аңа болай килешми иде.

Тагын да дәртләнеп эшли башлаган гына иде:

— Гатаулла аркасында безне ялкауга чыгаралар! — дип, дуслары үпкәләде, сөйләшмәс булдылар. Үзенең ялгызлыгын авыр кичереп, кыйналып һәм мыскылланып, акылга утырды ул. Бүтәннәр кыл да кыймылдатмыйлар, ә акчаны, хезмәт хакы буларак, аның кебек үк, хәтта күбрәк тә алалар икән.

Гатаулла бары шушы хаксызлыкны аңлаганнан соң гына ялкаулыкка чыкты. Дөресрәге, бүтәннәрнең дә үзен куып җиткәннәрен көтте. Моңа гына хакы бар иде. Әмма аның гына тырышуына, аның гына тир түгүенә өйрәнеп беткән иптәшләре Гатаулланың болай кинәт үзгәрүен яратмадылар. Үзләренә тагылган ялкау дигән ярлыкны аңа күчерделәр. Хакыйкатьтә Гатаулла барыбер алардан күбрәк эшли, авыррак йөкне тарта иде түгелме? Әмма ул хәзер хәйләгә өйрәнеп алган, тик җаен гына һаман да белеп бетерми. Тырышлыгы, эш сөюе комачаулый бугай шул.

Кеше — үсүчән, гомеренең бер чорыннан икенчесенә күчүчән. Малай чагында аңлашылмаган хакыйкать егет вакытың җитүгә үк җиңел төшенелә башлый, акыл чуалтырлык нәрсә булып тоелмый. Егет акылы иргә ярамый, диләрме? Нәкъ шулай! Һәм Гатаулла, малайлыгында хәйлә белмәгән килеш, егетлек чорына керүгә, үзгәрде дә куйды. Хәзер аны алдап булмый иде инде!

Юк инде, җәмәгать! Ялган сүз сөйләп йөрмәгез! Гатаулла кебек тырыш кешене әүвәле эзләп табыгыз, аннан соң телегезгә алып әйтерсез. Андагы гайрәт, андагы көч бүтән берәүдә булса, димәкче идегезме? Шулай шул! Көч булсын өчен яшьли эшләп үсәргә кирәк. Сез көне буе чокчынып ятканны Гатаулла бармак уйнатып кына башкарып ташлый! Ә-ә, беләсезмени? Әле сезне дә онытмасын, ярдәм дә итсенмени? Алай икән!..

Юк инде, анысын ук өмет итмәгез! Әнә, әүвәле миңа кушылган эшне бетерсен, аннары күз күрер! Ярар-ярар, әйтермен! Тыңлар-тыңлар! Тыңламаса — тыңлатырбыз! Кая барсын, ул бит минем энекәш! Хәзер колагын борам мин аның! Кырыкны узып бара дип тормам!

*Август, 1999*

# Эчтәлек

«ЗИС-5» ...............................
Тәүбә-тәүбә, әстәгъфируллаһ! ....................
Империалист .............................
Бар икән күрәселәр .........................
Сөйкемле сөяк ............................
Багана фалы ..............................
Яшәү сере ...............................
Әхмәтвәли гыйшкы ..........................
«Игорь кенәз» ............................
Ат урлауның ние бар… ........................
Ак Ай буендагы кич ..........................
Дөнья бәһасе .............................
Маҗаралы Гыйльметдин .......................
«Татар» ................................
Бар бер авыл, Чокал, диләр... ....................
Коелган мәхәббәт таҗы ........................
Сөю-сәгадәт алмасы .........................
Күз яше сере .............................
Солдат хикмәте ............................
Мунча парысы ............................
Кило ярымлы кура җиләге ......................
«Өфет мае» ..............................
Мөдәмир, яки «Тәрәзә төбең үрмә гөл!..» ..............
Буа шикәренең тәме ..........................
Ялгышмагыз, җәмәгать! ........................

Литературно-художественное издание

*Яхин Фарит Закизянович*

**ИЗЮМИНКА**

Рассказы

(на татарском языке)

Мөхәррире *И.Г.Ногманов*
Рәссамы *Й.М.Вәлиәхмәтов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Н.Н.Мусина*
Корректоры *Г.Г.Гарифуллина*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 8.09.2004. Форматы 84×108 $1/32$.
Офсет кәгазе. «Kudriashov» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 10,08+фор.0,21. Шартлы буяу-оттиск 11,34.
Нәшер-хисап табагы 11,44+фор.0,36. Тиражы 3000 д. Заказ Э-642.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.
**http://www.tatarstan.ru/books/**
**E-mail: tki@books.kazan.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.